Безнең МИРАС

12
декабрь 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

22 ноябрьдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, РТ президенты аппараты җитәкчесе Әсхәт Сәфәров, ТР прокуроры Илдус Нәфыйков белән бергә Иске Татар бистәсендәге истәлекле урыннарны барлап чыкты, «Шамил йорты»н (биредә Габдулла Тукай музее эшли) яңарту-төзекләндерүне күздә тотып, аның яңа проектын кичекмәстән әзерләргә күрсәтмә бирде.

Син гел истә, Иске Татар бистәсе!

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
12(47)
декабрь 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

40



6 «ХАК ХӨКМЕНӘ КОЛЛАР РИЗА БУЛУ КИРӘК...»
Алмаз Мөхәммәдиев

27 АВЫЛЫБЫЗ ТАРИХЫННАН БЕР КИСӘК.
Мөхәммәт Мәһдиев

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Тел күрсәтә... Харрас Әюп**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Төньяк төрбә.**
6 **«Хак хөкменә коллар риза булу кирәк...»** *А.Мөхәммәдиев*
12 **Бәйрәкә мәдрәсәсе турында яңа чыганаклар.** *Ә.Шәрипов*
18 **«Плин төшкән кешеләрнең эшләре бик хараптыр...»** *Р.Мәрданов*
24 **Кем ул Закир Галиев?** *Җ.Миңнуллин*
27 **Авылыбыз тарихыннан бер кисәк.** *М.Мәһдиев*
32 **Изге койма кыйссасы.** *З.Зәйнуллин*
40 **Бөтен өмет яшьләрдә.** *Ф.Баттал*

ТАТАР ГАМЕ

46 **Тәлгат Миңлебаев ядкярләре.** *И.Низамов*
53 **Тел белгән — ил гизгән.** *(Р.Җамалетдинов белән әңгәмә)*
56 **Мин утырткан агачлар шаулап үсә...** *Ф.Ислаев*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

60 **Сүз һәм сурәт.** *С.Ислаева*

ПЕДАГОГИК МИРАС

62 **Әхлак.** *К.Бикколый, Г.Госмани*
65 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре.**
66 **Тәрбия эшендә мөһим бер мәсьәлә.** *К.Туйкин*

ӘДӘБИ МИРАС

68 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
72 **Кайт әле монда, ватанга!..** *М.Вәлиев*
78 **Мәдрәсә җимеше.** *Г.Исхакый*
85 **«Гөлбакча»лы этием.** *Л.Кариева*
90 **Мөхәммәт Мәһдиев: «Егет булыйк әле бер...»** *Ә.Фәйзрахманов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

92 **Кайтаваз. «Седльце шигырьләре» эзеннән...** *Х.Бәдигый*
96 **Гаярь егет.** *А.Хәсәнов*
98 **«Шәп кешеләр белән очрашу – үзе бер бәхет».** *Ф.Яруллин*
103 **Тукай энциклопедиясе.** *Р.Харрасова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Йозаклар. Гүзәлия Җәләлева**

100 ЕЛ ЭЛЕК...

108 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның декабрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

110 **Көлке куа килә...**

113 **Мирасворд**

114 **2015 елга «Безнең мирас» журналының библиографиясе**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Декабрь*

Заказ №О-3440. Тираж – 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 01.12.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Өч ай». 1997.
Киндер, майлы буяу. *З.Гыймаев рәсеме.*

Харрас Әюп
(1946-2008)

ТЕЛ КҮРСӘТӘ...

Улым, сиңа әйтәм...
Мәкальдән

Исем китеп торам кайчак:
Минем йортмы, бу кем йорты? —
Балаларда — урыс теле,
Үз телләре — ярым-йорты.

«Бисмиллаһ әйт, — диләр иде, —
Авызыңа шайтан керер…»
Кайчан керде балаларга?
Без күрмәгәч, кемнәр күрер?!

Терсәк якын — тешләп булмый,
Җитми икән буй терсәккә.
Үз балаңның авызыннан
Явыз Иван тел күрсәтә…

БОЛГАР. ТӨНЬЯК ТӨРБӘ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Төньяк төрбә (Монастырь базы) Җамигъ мәчетенең төп фасады каршында урнашкан. XIY гасырда ак таштан төзелгән бу бина XYIII гасыр тарихи чыганакларыннан мәгълүм. Көнчыгыш төрбәдән зуррак булуы һәм кайбер детальләре белән аерылып тора: ул тәбәнәгрәк, порталының нигезе озынрак, тавыш көчәйткеч җайланмалары торба рәвешендә түгел, күләмле савытлар рәвешендә корылган.

Төрбәнең иң беренче бинасының нигезе, эчке диварлары һәм аларның тышлыгы, тавыш җайланмалары, ишек һәм тәрәзә уемнарының очлы һәм аркалы рәвешләре, нигездән сигез кырлы формага күчүнең почмаклардагы кыеклары, гөмбәзнең түгәрәк нигезе, чыгарылма порталның калдыклары сакланып калган. Төрбә археологлар тарафыннан 1964 һәм 1966 елларда тикшерелгән. Консервацияләү буенча төп эшләр XX гасырның 70 нче еллары башында үткәрелгән.

2011-2012 елларда бу ядкярнең тышкы кыяфәтен элеккеге хәленә кайтару буенча төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды. Бетоннан эшләнгән саклагыч плитә һәм металл баганалар сүтелде, гөмбәзнең тышкы кирпечләре ныгытылды. Эчке һәм тышкы диварлар, шулай ук нигез дә махсус эретмәләр белән эшкәртелде.

Төрбә эченә лапидарий *(таш һәйкәлләр, кабер ташлары һ.б., lapidus — латинча, «таш» дигән мәгънәне белдерә. —**Ред.**)* урнаштырылды, YIII-XIY гасырлардагы Болгар эпиграфикасы күргәзмәсе — «Болгар эпиграфикасы» экспозициясе оештырылды, анда мультимедиа җайланмалар кулланыла. Бирегә куелган эпитафияләр *(язулы ташлар, epitaphios — грекча, кабер ташындагы язу дигәнне аңлата. — **Ред.**)* Болгарның бөтен территориясеннән җыелган, кайбер плитәләр Успение чиркәвен реконструкцияләгәндә табылган. Эпитафияләрнең тышкы күренешләре, уртак нәфис стиле борынгы Болгардагы таш уючыларның югары осталыгы турында сөйли. Лапидарий турында материал бирегә урнаштырылган мәгълүмат терминалына кертелгән. Яктырту системасы эшләнгән. ■

«ХАК ХӨКМЕНӘ КОЛЛАР РИЗА БУЛУ КИРӘК...»*

(Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә нигезләнеп Идел болгарларының хокукый мөнәсәбәтләрен өйрәнү)

Алмаз Мөхәммәдиев,
тарих фәннәре докторы

«Кыйссаи Йосыф» әсәре Идел Болгарстанында очраган бик күп җинаятьләрне һәм җәзаларны ачыкларга ярдәм итә. Бер фасылда (бабта, өлештә) төп каһарман абыйларын *кешене үтерергә теләүдә* гаепли, араларыннан берсе каршы чыкканга гына эшнең ул кадәр күңелсез, канлы рәвештә тәмамланмавын искәртә. Йосыф аларның һәммәсен җавапка тарту белән яный, әмма бу юлы да, аерым сәбәпләр аркасында, туганнары судан коры чыга[1]. Кол Гали әсәрендә туганыңны үтерү — аерата начар гамәл исәбендә күрсәтелә.

«Кыйссаи Йосыф»та кол сатып алырга теләгән Малик сатучыларга: *«Ничә төрле гайбе булса — кылың бәян»*, — дип әйтүгә, Йосыфның туганнары: *«Колыбызның төп-төгәл өч гайбе бардыр, урлаучыдыр, ялганчыдыр, качучыдыр»*[2], — дип җавап бирә. Бу очракта без *ялганны* җинаятькә тиңли алабызмы? Анык кына әйтү авыр. (Төрки-монгол хокукы әлеге гамәлне җинаятькә керткән.) Шушы сатулашу әсәр йомгагыннан тагын бер җеп очын тартып чыгара: кем ул кол? Җинаяти-хокукый мөнәсәбәтләрдә аның статусы нинди? Идел Болгарстанында коллар җинаять субъектлары булып исәпләнгәнме? Җөмләдән, әлеге сораулар Киев кенәзлеге мәсьәләсендә дә ачык кала бирә. Кайберәүләр холоп — җинаятьче саналмаган, аның өчен хуҗа җавап тоткан, дигән фикердә[3]. Үзгә галимнәр шуның киресен раслый[4]. Ләкин Идел Болгарстанында *һәр физик зат җинаять субъекты* була алган, дигән фараз да нигезсез түгел. Һәрхәлдә, Кол Гали әсәре шуны дәлилли *(«колыбызның төп-төгәл өч гайбе бардыр...»)*.

«Кыйссаи Йосыф»та яла ягу да җинаять буларак бәһаләнә. Зөләйхә төп каһарманга төрле нахак гаеп тага, *«угълан миңа явыз ният кылды»*, дип белдерә һәм Мисыр хакимен Йосыфны җәзага тартырга чакыра. Әмма хакыйкатькә төшенгән Кыйтфир хәләл җефетен фаш итә *(«Йа Зөләйхә, сүзең ялган, шул беленде: син икәнсең гъәеп кылган»)* һәм Йосыфның әлеге вакыйганы сер итеп саклавын (ягъни, Зөләйхәнең яла ягуын да, зинага кыставын да җиде йозак астына яшерүен) үтенә *(«Ил эчендә Зөләйхәне хур итмә»*[5]*)*.

Шул ук фасылда без *мыскыл итү* кебек күренешкә дә юлыгабыз. Мөселман юриспруденциясендә бу да җинаять саналып, аның өчен җәза карала. Зөләйхәнең Йосыфны әхлаксыз төстә

* Ахыры. Башы журналыбызның 11 нче санында.

[1] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.193-195.
[2] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.57.
[3] Клеандрова В.М., Мулукаев Р.С. История государства и права России; под редакцией Ю.П.Титова. — Москва: ТК Велби, Издательство Проспект., 2005. — С.28.
[4] Исаев И.А. История государства и права России. — Москва: Юристъ, 1996. — С.21.
[5] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.120.

күрсәтергә, җәзаларга теләвен хокук бозуга тиңләргә мөмкин, чөнки ул «явызны» чын-чынлап «акылга утыртырга» тели: *«Бу угъланны яп зинданга, куркыт, яна, яхшы сабак бир син аңа... әдәпсезлек эшләмәсен!»*[6]

Әсәрдә болгар җәмгыятенә хас булган үзгә мөлкәти җинаятьләр дә очрый. Бер өзектә Йосыфка урлау гаебе тагыла. Гомумән, текстта караклык, бурлык темасына зур урын бирелә, искә төшерик: Ибнейәминне янында калдырыр өчен Йосыф үзе дә аны угрылыкта гаепли — агаларының кәрваны яхшылап тикшерелгәннән соң, югалган алтын җам Ибнейәминнең йөгендә «табыла» һәм эне *«хөкем тырнагына эләгә»*[7] һ.б.



Кол Гали.
Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме

Кайбер чыганакларга нигезләнеп фикер йөртсәң, Идел Болгарстанында идарә итүгә кагылышлы җинаятьләр һәм җәзалар да кылынган булырга тиеш. Шуларның берсе — *ришвәт*. «Кыйссаи Йосыф»та мәлик Рәййанны агулап үтерер өчен шымчы җибәрелә, ул, *«күп маллар китереп»*, сарай икмәкчесен һәм шәрабчысын үз ягына аудара[8]. Мондый төр җинаятьләрнең барлыкка килүе дәүләт-хокук мөнәсәбәтләренең алга китүен һәм, шул исәптән, түрә-караның чамадан тыш артуын күрсәтә.

Кол Гали *дәүләткә һәм тәхет биләгән нәселгә каршы гамәл* кылучыны үлем җәзасы көткәнен яза. Әйтик, ришвәт бәрабәренә шымчыга юл ачкан икмәкчене мәлик Рәййан асып үтерергә боера. (*«Син шуны бел, тиздән китәр синең башың, һичбер шиксез, Рәййан сине аса инде»*, — дип юрый аның төшен Йосыф[9].)

Халык күрсен, сабак алсын өчен мәҗүси болгарларда җинаятьчене үтергәч тә элмәктән төшермәгәннәр, мәетнең таркалып бетүен көткәннәр. Бу йола, күрәсең, ислам кергәч тә онытылмаган, чөнки «Кыйссаи Йосыф»та шундый юллар бар:

Юраудан соң үтеп китте төгәл өч көн,
Рәййан кушып, дарга асылды хәббаз[10] мескен,
Кошлар килеп чукып алды ике күзен...[11]

Икенче урында Йосыф агалары өстенә зәһәрен чәчә: *«Барчагызны муеныннан астырырмын, һәркайсыгыз газап белән үтерермен»*[12]. Агач астына бастырырга, күзләрен бәйләргә куша. Кичереп, рәхимлек күрсәтергә уйлагач кына, фикерен үзгәртә: *«барчасының кулын чишеп чыкты инде»*[13]. Димәк, бу чор Идел Болгарстанында *үлем җәзасы* гамәлдә булган һәм ул *аерата җитди җинаять* (хыянәт, үтерү һ.б.) кылучыларга карата кулла-

[6] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.118.
[7] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.183.
[8] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.125.
[9] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.126.
[10] Хәббаз — икмәкче.
[11] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.127.
[12] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.194.
[13] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.195.

«Һәммәсе дә карап торып шунда аңар, әфлисун дип бармакларын кисте инде...»

нылган. Гаҗәп, ләкин әсәрдә үлем җәзасының ничек башкарылуы үтә тәфсилләп сурәтләнгән: беренчедән, җинаятьчеләрнең, гадәттә, йә башын чапканнар, йә асканнар икән; икенчедән, дарга кешене богауланган килеш илткәннәр; өченчедән, карарын тормышка ашырыр алдыннан бичараларның күзен бәйләгәннәр.

Чираттагы җәза — *иректән мәхрүм итү*, зинданга ташлау. Монысына мөлкәти җинаять кылучылар (караклар, талаучылар) да тарыган. «Кыйссаи Йосыф»та ришвәт алган өчен шәрабчы да, икмәкче дә әүвәл зинданга эләгә, Йосыфның туганы Ибнейәмин дә «угрылык өчен» ике елга ирегеннән мәхрүм ителә, Йосыф үзе Зөләйхә аркасында унике ел таш капчыкта кыен ашый (әле аны берникадәр вакыт сандык эчендә дә бикләп тоталар)[14]. Әсәрдән күренгәнчә, төрмәдә утыручыларның, нигездә, кулларына богау да салынган.

Идел Болгарстанында *газаплау да* (кул-аякны чабу, камчылау һ.б.) еш кулланылган. Кол Гали әсәрендә Зөләйхә Кыйтфирнең Йосыфны ничек җәзалаячагы турында кызыксына: *«Зиндангамы, әллә газап, дисеңме инде?»*[15] Үзгә урында Йосыф үзе дә: *«Барчагызны муеныннан астырырмын, һәркайсыгыз газап белән үтерермен, берәр кулыгызны кистерермен»*, — ди[16].

Җинаятьләр һәм җәзалардан тыш, «Кыйссаи Йосыф»та болгарларның мәхкәмә эшен ничек алып барулары турында да кайбер детальләр очратырга мөмкин. Билгеле ки, мөселманнар өчен казый хөкеме иң гадел һәм иң кануни, дөрес яргулау булып саналган. Бу әсәрдә дә шәригать кануннарын зурлауны, олылауны күрәбез — автор төп каһарман авызыннан шундый сүзләр әйттерә:

«Шәригатьчә хөкем кылам аны тәхкыйк[17]*,*
Нәкъ ике ел ул зинданда ятсын инде»[18].

Поэма *шаһитлар һәм аларның хөкем эшендә катнашы* турында да күпмедер мәгълүмат бирә. Зөләйхә Йосыфны «әдәпсез гамәлдә», «яман эш кылуда» гаепли. Йосыф Кыйтфир алдында акланырга мәҗбүр — ул үзенең «ару» булуын, Зөләйхәнең «языклы»лыгын әйтә: *«Зөләйхәнең шаһиты юк, мин — шаһитлы»*, — ди[19]. Әмма

[14] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.124-125, 137.
[15] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.118.
[16] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.194.
[17] Тәхкыйк — чынлыкта.
[18] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.184.
[19] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.119.

шаһит — кечкенә сабый булып чыга һәм, Кыйтфирнең сүзләренчә, аның әле теле ачылмаган, димәк, ул шаһитлык итәргә дә мөмкин түгел. Вәләкин, ни гаҗәп, *«тәңре кушуы буенча»* сабый сөйләп китә һәм *«угълан»*ның гаепсезлеген икърарлый. Бу юллардан нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин соң? Бәхәскә кушыласы шаһит кемнедер куәтләр яисә каршы чыгар өчен аның бу бәхәскә катнашырлык хәл-халәттә (сәламәт акыллы, сөйләшә алырлык һ.б.) булуы шарт икән!

«Кыйссаи Йосыф»та *салым мәсьәләсе* дә (бер тапкыр алына торган салым, махсус салым) күпмедер дәрәҗәдә телгә алынып уза, аның ярдәмендә, шулай ук, кайбер нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин. Сарайга кереп, Йосыфны күрергә теләгән һәркем бер динар күләмендә акча түли, теләүчеләр гаять күп булгач, салым бәясен көн саен арттыра баралар һәм унынчы көнгә ул ун динар күләменә менеп җитә. Өстәвенә, Йосыфның сурәтенә багар өчен бәгъзеләр һич кызганмый *«малын да фида кыла»*, ягъни, салымнан тыш та нидер бирә, түли, бүләк итә[20].

Болгар сәүдәгәрләренең осталыгы, эшлеклелеге турында бик күп тикшеренүчеләр язды инде. Билгеле, теге яисә бу хакта төрлетөрле килешүләр дә шактый төзелгәндер, әмма алар, ни кызганыч, бүгенге көнгә кадәр сакланып калмаган. Янә Кол Гали каләменнән төшкән поэмага мөрәҗәгать итеп карыйк. Анда *товар алышу* процессына бәйле нечкәлекләр шактый сурәтләнә. Җөмләдән, «Кыйссаи Йосыф»тагы шундый мисалларга игътибар итеп, Р.М.Вәлиев *«Идел Болгарстанында сатып алу-сату күренеше, нигездә, килешү кәгазьләре белән ныгытылган, бу — безнең борынгы ватаныбызда акча барлыкка килгәннән соң сәүдәнең мөһим формасы булып торган»,* дигән фикерне алга сөрә[21]. Дикъкать бирсәк, әсәрдә сату-сатып алуга бәйле эшлекле сөйләшүләрне башыннан азагына кадәр җентекләп күзәтеп барырга мөмкин. Әйтик, сюжет буенча, Йосыфның туганнары Малик Дугыр сәүдәгәрне очрата һәм энеләрен аңа биреп җибәрергә уйлый:

Алар уртак бер фикерне хуш-хуп күрде:
«Моны кол дип боларга без сатыйк инде».

Малик Дугыр зирәк иде, эшне белде,
Яшерен генә күңле шатлык белән тулды,
Болар — сатар, ә ул сатып алыр булды,
Моны ишеткәч, Йосыф үксеп елый инде[22]*.*

Ике як, үзләренең ихтыяр-ниятләрен аныклагач, сатулаша башлый:

Болар әйтте: «Кол сатабыз бүген сиңа,
Шул шарт белән: ерак сатар булсаң гына,
Бәһасен дә тиешенчә куйсаң гына —
Сиңа, шиксез, сатачакбыз», — диләр инде[23]*.*

Сәүдәгәр товарны тикшерә: чыннан да, кол саталармы? Алдап, азат кешедән котылырга исәпләре юкмы? Шуны уйлап, Малик Дугыр «кол»ның нинди гөнаһ-гаепләре булуы хакында төпченә[24]. Туганнар Йосыфның качак булуын икърарлый, өстәвенә, җинаятьче ярлыгы да тагалар: «урлаучыдыр, ялган-

[20] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.80.
[21] Валеев Р.М. Волжская Булгария: торговля и денежно-весовые системы IX-начала XIII веков. — Казань: Издательство «Фест», 1995. — С.40.
[22] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.55-56.
[23] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.56.

чыдыр». Сатучыларның ихласлыгына инанганнан соң, Малик «товар»ның бәясен белешә, шул ук вакытта, үзе белән җитәрлек күләмдә акча алмавын искәртә:

«Ләкин хәзер кулымда һич алтыным юк,
Товарымда комачым һәм атласым күп,
Бераз ярмак — вак акчам бар, бәясе юк,
Ничек сәүдә кылышабыз?» — диде инде[25].

Туганнар ни комачка, ни атласка кызыкмыйча, энеләрен ярмакка — вак акчага алмаштырга ризалашалар. Аларның бу гамәле сәүдәгәрдә шактый гына борчу, шик тудыра — ул, тәгаен ышаныр өчен, Йосыфның үзеннән сорый:

Тик дөресме болай диеп сатулары? —
Чынын гына миңа ачык әйтче инде.

Йосыф, агаларының куркытуыннан соң *(«Юк!» — дип әйтсәң, үтерәбез, яхшы бел син!»): «Кол мин», —* дияргә мәҗбүр була[26]. Малик Дугыр исә «кол»ны барлык «гаеп»ләре белән бергә сатып алырга ризалаша, әмма аның бер шарты бар: *«Килешүгә бер язу да кирәк инде».* Туганнары, энеләреннән мөмкин кадәр җәтрәк котылырга кирәк булганга, моңа шактый тиз күнәләр, килешү кәгазен Йосыфның бер агасы — Шәмгун — үз куллары белән яза:

«Барыбыз да бу сатуга риза булдык,
Колыбызны сатуны без бик хуп күрдек,
Уныбыз да разый булып бөти яздык,
Колыбызны тапшырабыз сиңа инде»[27].

Алга таба туганнар ни кылганнарына үкенә дә кебек, ләкин артка юл юк — килешү төзелгән һәм аны гамәлдән чыгару мөмкин түгел, *сату-сатып алу килешүе абруйлы*, дәрәҗәле, кагылгысыз:

«Һәм сатуга үкенгән дә була идек,
Тик моңа без гарьләнәбез», — диләр инде.

Алар Йосыфка килешү язуының көче турында сөйли, аны килешүчеләрнең бер ягы теләп кенә бозып булмавын аңлата, шуңа күндерергә тырыша — аларны, янәсе, әтиләре алдында яңадан хур калудан битәр, сәүдәгәр алдында чарасыз калу ныграк борчый:

«Атабызга без ялганчы булалмыйбыз,
Сине аңа кире алып баралмыйбыз,
Бу эшкә без һичбер чара табалмыйбыз,
Бу михнәткә син түзә күр», — диләр инде[28].

Язмача төзелгән сату-сатып алу килешүендә ике якның ни-нәрсә эшләргә тиешлеге хакында бик күп маддәләр теркәлгәндер һәм ул документ озак еллар саклангандыр, дип уйларга тулы хокукыбыз бар. Болгарлар арасында төзелгән мондый язуларның куәтен, хәтта байтак гомер узганнан соң да аның эчтәлегеннән ваз кичәргә ярамаганлыгын «Кыйссаи Йосыф»ның алдагы битләрендә дә күрәбез. Төп каһарман, Мисыр тәхетенә утыргач, коллыкка сатылуы хакында килешүнең һаман исән булуын әйтә туганнарына:

Йосыф әйтте: «Сез бер угълан кол саткансыз,
Аның нәкъ өч гаебе бар, дип әйткәнсез,
Шушы хакта бу язуны сез язгансыз»[29].

Башта карышып карасалар да, мондый дәлилдән соң туганнары үз «гаепләрен» танырга, андый килешүнең, чыннан да, төзелүен икъарарларга мәҗбүр була.

[24] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.57.
[25] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.57.
[26] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.58.
[27] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.59.
[28] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.62.
[29] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. — Б.193.

«Кыйссаи Йосыф»ның бер нөсхәсе. XIX гасыр кульязмасы

«Кыйссаи Йосыф»та, бактың исә, сату-сатып алу эшенең һәр адымы җентекләп сурәтләнгән икән. Иң әлек, билгеле, бер якның нәрсәдер сатарга, икенче якның шул нәрсәнедер сатып алырга теләве кирәк. Сатучы товар тәкъдим итә. Сатып алучы товарның килеп чыгышы, сыйфаты турында кызыксына. Аннары сатулашу башлана. Сатып алучы товар өчен акчалата гына түгел, бәлки, үзгә төрле товарлата да (бартер) түли ала. Сатып алучы товарга карата туган шик-шөбһәсен шунда, урында гына белдерергә хаклы. Бәя аныклангач, язмача яисә телдән килешү төзелә. Язмача килешү йә ике якка да, йә, товарның урланмаган һәм башка канунсыз юллар белән юнәлтелмәгәнлеген раслар өчен, сатып алучыга гына бирелә.

Шәхси милек, сәүдә институтларын, килешү мөнәсәбәтләрен ныгытуда, һичшиксез, болгар халкының язулы, хәрефле булуы зур роль уйнаган. «Кыйссаи Йосыф»тан күренгәнчә, XIII гасырда Идел Болгарстанында килешүләр күбесенчә кәгазьдә төзелгән (гарәп имлясы шушы материалда язу өчен кулай). IX-X гасырда ук Урта Азиядә мамыктан кәгазь җитештергәннәр, ул тарафлар белән Идел Болгарстаны тыгыз сәүдә бәйләнешендә торган. Казылмалар арасында кызыл балчыктан һәм бронзадан эшләнгән кара савытлары табылу да алдагы фикерләрне куәтли. Г.М.Дәүләтшин күрсәткәнчә, болгарлар арасында шәхси милек, исәп-хисап, документлар системасының шактый алга киткән булуын археологик экспедицияләр вакытында табылган мөһер пломбалары, мөһер хезмәтен үтәгән кашлы йөзекләр дә раслый[30].

Шулай итеп, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре — монгол яуларына кадәрге чорыбызның бибәһа әдәби җәүһәре дә, татар тарихын өйрәнүдә кыйммәтле, кадерле чыганак та булып тора. Бу очракта поэма, аны җентекләп өйрәнү безгә Идел болгарларының хокукый характердагы мөһим мөнәсәбәтләрен ачыкларга ярдәм итте.

*Урысчадан **Миләүшә Талипова** тәрҗемәсе* ■

[30] Давлетшин Г. Булгарская письменность (раннебулгарский и домонгольский периоды)// Эхо веков. — 2008. — №1. — С.28-29.

БӘЙРӘКӘ МӘДРӘСӘСЕ ТУРЫНДА ЯҢА ЧЫГАНАКЛАР

Әнвәр Шәрипов

Хәзерге Ютазы районының Бәйрәкә авылындагы мәдрәсә Октябрь инкыйлабына кадәр халкыбызның иң мәртәбәле уку йортларының берсе булган. Аның тарихы әле тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. «Татар энциклопедиясе»нең II нче томында (Казан, 2005) Бәйрәкәдәге «Гобәйдия» мәдрәсәсе турында фәнни мәкалә бар (авторлары Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов). Соңрак Ризаэддин Фәхреддиннең 4 томлы «Асар» хезмәте басылып чыкты (Казан: Рухият, 2006-2010 еллар), Бәйрәкәдә яшәп вафат булган язучы һәм педагог Кәшиф Рәхимнең (1905-1989) «Бәйрәкә авылы» дигән кульъязма дәфтәре табылды. Бу хезмәтләрдә «Татар энциклопедиясе»ндә искә алынмаган яңа мәгълүматлар бар. Түбәндә шушы чыганакларның бер өлешен тәкъдим итәбез.

Бәйрәкәдә белем һәм мәгърифәт учагына кайчан нигез салынган? Р.Р.Салихов һәм Р.Р.Хәйретдиновлар болай яза: *«Гобәйдия», Оренбург губ. Бөгелмә өязе (хәзер ТРның Ютазы р-ны) Бәйрәкә авылындагы өченче җамигъ мәчете каршындагы мәдрәсә. Идел буендагы иң зур мөселман уку йортларының берсе. XIX йөздән мәгълүм»* [1. 131]. Ә Кәшиф Рәхимдә үзгә мәгълүмат китерелә: *«1912 нче елда Бәйрәкәдәге «Гобәйдия» мәдрәсәсенең 100 еллыгы үткәрелде. Ул юбилейда катнашу өчен Самара большевикларыннан К.М.Төхфәтуллин килә.*

Юбилей турында Төхфәтуллин аганың болай сөйләгәне бар: «Гобәйдия мәдрәсәсе төзелүгә 100 ел, гомумән, Бәйрәкәдә мәдрәсә оешуга 200 ел, дип уздырылды» [2.4]. Әгәр Кәшиф Рәхим китергән бу мәгълүматны дөрес дип алсак, Бәйрәкәдәге беренче мәдрәсәгә 1712 нче елларда нигез салынган булып чыга. Уку йортының башлангыч чоры хакында ул болай яза: *«1785 нче елга кадәр Бәйрәкәдә законлы мәчет салырга рөхсәт ителми. Югары очтагы куе каен урманы эченә мәчетне кабыклардан оештыралар да, тикшерү килә башласа, сүтеп өя торган булганнар. Шуның өчен ул мәчет урнашкан мәхәлләне «Кабык мәчет мәхәлләсе» дип йөрткәннәр. 1785 нче елны «Әби патша» татар авылларында мәчет салырга рөхсәт биреп указ чыгаргач, кабык мәчет урынына агач мәчет салына һәм беренче мәхәллә дип атала. Патша хөкүмәте мәчет салырга рөхсәт итмәсә дә, мәдрәсәләр тотуга каршы килмәгән»* [2. 4].

Шунысы куанычлы, Кәшиф Рәхим үзе белгән, үзе ишеткән хәлләрне түкми-чәчми кәгазьгә төшереп калдырган. Шуның өчен аңа зур рәхмәт! Үзенең әйтүе буенча, әлеге тарихны язган вакытта ул Шәриф Халиков, Фәхретдин Хадмиев һәм Әхмәдиша Әсәдуллиннарның язмаларын укып чыккан һәм үз хезмәтендә файдаланган. Аның бу кульязма дәфтәрендә, әлбәттә, кайбер төгәлсезлекләр дә булырга мөмкин.

К.Рәхим: *«1812 нче елга кадәр Бәйрәкә мәдрәсәсендә Мөхәммәт Шәриф ишан дигән суфи кеше җитәкчелек иткән»,* — дип яза [2. 4]. Ә Р.Фәхреддиннең «Асар» хезмәтендә 1812 елга кадәр үк Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыткан берничә имам-мөдәррис хакында мәгълүмат бар. Мәсәлән, Мөхәммәдкол бине Табай дигән кеше турында: *«Ык елгасындагы Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1786 елларда вафат булган. Гыйлем әһелләре арасында белемле вә камил дигән исеме таралган»,* — дигән мәгълүмат бирелә [3. 48]. Бу, безнеңчә, XVIII гасырда ук Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыткан, исеме тарихта

калган беренче имам һәм мөдәррис булса кирәк.

Бәйрәкә кешеләре миңа шундый бер вакыйга сөйләде. 1800-1810 еллар тирәсендә авылның хәлле кешесе Муса хәзрәт таштан ике катлы мәчет салдыра башлаган. Ә ул заманда мәчетләрне таштан салдыру өчен аерым рөхсәт кирәк икән. Муса хәзрәтнең андый рөхсәт кәгазе булмаган. Чәкән авылындагы чиркәү кешеләре, төзеләчәк мәчеттән көнләшеп: *«Муса хәзрәт рөхсәтсез ике катлы таш мәчет салдыра»,* — дип, Самара управлениесенә җиткергәннәр. Самарадан тикшерү килгән. Муса хәзрәт куркып калмаган, төзеләчәк бинаның сызымнарын күрсәтеп: *«Мин мәчет түгел, чиркәү салдырам. Менә карагыз, гөмбәзе болай булачак»,* — дип, түгәрәк гөмбәзне күрсәткән. Тикшерүчеләр каршы сүз әйтмәгәннәр, ышанып кайтып киткәннәр. Ә бина төзелеп беткәч, Муса хәзрәт гөмбәз өстенә тәре түгел, ай куйдырган. Шуңа күрә Бәйрәкә мәчете түгәрәк гөмбәзле булган икән.

«Асар»ның I нче томында Мөхәммәдкол бине Табайдан соң укыткан башка мөдәррисләр хакында да мәгълүматлар бар. Аларга таянсак, мәдрәсәгә «Гобәйдия» исеме бирелгәнче үк, Бәйрәкәдә өч мәчет (ә һәр мәчет каршында мәдрәсә) булган. Аларда Искәндәр бине Гали, Мостафа бине Әхмәр һәм Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим исемле имамнар укыткан.

Искәндәр бине Гали хакында Р.Фәхреддин болай яза: *«Искәндәр бине Гали бине Ает... Бәйрәкә авылында Мөхәммәдкол бине Табай вафат булгач имам вә мөдәррис булып, 1832 ел 17 июньдә 75 яшендә вафат булган (димәк, аның яшәгән еллары 1757-1832 булып чыга. —* ***Ә.Ш.****). Кабере Бәйрәкәдә. Бу зат беркадәр вакыт Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим белән бер мәчеттә имамлык итеп, аннан соң өченче мәчет төзелү илә Мөхәммәдшәриф анда күчә, вә бу зат үзе генә кала. Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим, Искәндәр бине Гали, Мостафа бине Әхмәр исемле өч затның мәдрәсәләре бер урында, фәкать үзләренең хөҗрә-бүлмәләре аерым-аерым биналарда булган, вә шул хәлдә шәкертләр укытканнар. Алар вафат булгач, бу мәдрәсәләрнең барчасы өченче мәчет имамы вә Мөхәммәдшәриф бине Ибраһимның улы булган Гобәйдулла бине Ибраһим тәрбиясенә калган. Ошбу мәдрәсәләр, шул көннән бу заманга кадәр гыйлем эстәүче шәкертләр өчен бер сыену урыны булып, бер-бер артлы алмашынып, олуг һәм файдалы мөдәррисләр укытканнар»* [3. 132].

Ә Мостафа бине Әхмәр турында «Асар»да: *«Мостафа бине Әхмәр бине Мансур. Бөгелмәдән төн тарафта Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1836 ел, 14 мартта 60 яшендә вакытта вафат булган (димәк, яшәгән еллары 1776-1836 булып чыга. —* ***Ә.Ш.****). Кабере Бәйрәкәдә. Мансур исемле бабасы Казан артындагы Балыклы авылыннан Бәйрәкәгә күчеп килгән... Мостафа бине Әхмәр, бу җирлектә булган остазлары хозурында гыйлем алгач, Бохарага барып, рәсми дәресләр белән мәшгуль булган вә, беркадәр еллар торгач, бу мәмләкәткә кайтып, Уфа илә Бөгелмә арасында зур почта юлы өстендә булган Япрук авылына имам булган. Ул авылда 9 ел торганнан соң, мәхәллә халкы илә дуслыгы киткәнгә, Бәйрәкә авылында булган баҗасы Фәйзулла бай бине Гали күрсәтүе һәм тырышлыгы илә Бәйрәкәдә икенче мәчет хозурына күчкән һәм дәрес әйтү илә дә мәшгуль булган. Хатыны Маһруй исемле булган»,* — диелә [3.145].

Шулай итеп, нәтиҗә ясарга мөмкин: XIX гасыр башында Бәйрәкәдә өч мәчет булып, беренче мәхәлләдә Искәндәр бине Гали бине Ает, икенчесендә Мостафа бине Әхмәр бине Мансур һәм өченчесендә Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим имамлык вә мөдәррислек иткән. Шулардан соңгысы, безнеңчә,

аеруча зур һәм күренекле шәхес булган, ахрысы. «Асар»да аның тормышы шактый тулы тасвирланган. Шул мәкаләдән кайбер мөһим өлешләрен китереп узыйк.

Бу гыйлем иясенең тулы исемен Р.Фәхреддин «Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви» дип атый һәм болай яза: *«Үргәнеч мәмләкәтендә вә Яңа Үргәнеч шәһәренә 4 чакрымда булган Чекә атлы урында ишанлык итеп, 1841 елда вафат булган. Асылы типтәр таифәсеннән булып, ни вакыттадыр Бохарага сәфәр иткән. Хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни белән аралашкан (әйтергә кирәк, күп кенә татар укымышлылары Ниязколый әт-Төрекмәнидән белем алганнар. —* **Ә.Ш.***). Бу мәмләкәткә кайткач, Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып шәкертләр укыткан вә тәрбияләгән. Шул чорда Бәйрәкәнең мәшһүр байларыннан Исхак бине Гали бине Ает... исемле кешенең Шәмсекамәр исемле кызын никахлаган. Күпмедер вакыт торганнан соң, үз теләге беләнме, шәехе ишарәсенә күрәме, балаларын Бәйрәкәдә калдырып, 1815 елда Бохарага шәех Төрекмәни хозурына киткән вә аннан югарыда аталган Үргәнечтә, Чекәдә торган»* [3. 178]. Шушы ук мәкаләдә Мөхәммәдшәрифнең монда калган балалары Әбүнәгыйм, Таҗенниса һәм Мәрьям, аларның тормыш юллары хакында да шактый тулы языла, балаларының хатлары да китерелә. Ул хатларның берсендә Р.Фәхреддин: *«Фикеребезчә, хат Мөхәммәдшәрифнең үз улы Мөхәммәдзакир әфәнде (Чекәдә өйләнгән икенче хатыныннан туган улы. —* **Ә.Ш.***) тарафыннан язылгандыр»*. Мөхәммәдшәрифнең Бәйрәкәдән күчеп китүенең сәбәбе болай аңлатыла: *«Мәгълүмдер ки, атабыз Бәйрәкә авылында Исхак бай дигән кешенең кызын алып, беркадәр вакыт әлеге бай мәдрәсәсендә мөдәррислек итеп йөргәндә, хатыны дөньядан киткән. Әлеге Исхак бай исә икенче кызын бирергә булгач, атабыз, кабул итмичә, һәммә китап, мал вә башка нәрсәләрен бер угыл вә кызына ташлап, үзе Бохараи шәрифкә килгән. Берничә еллар укыганнан соң, Харәзмгә килеп, Үргәнеч ягындагы бер мәсҗидкә имам булган вә шул мәхәлләдән өйләнгән. Биредә 30 елдан артык дин гыйлеме укытып, Аллаколый хан заманында вафат булган. Вафат вакытында өч угылы вә бер кызы, хатыны калган. Бу вакыт атабызга 56 яшь булган»* [3, 179]. Димәк, Мөхәммәдшәриф 1785 елда туган һәм 1841 елда вафат булган икән.

Шушы ук мәкаләнең икенче бер җирендә: *«Күчеп киткәннән соң, урынына үз тарафдарларыннан Гобәйдулла бине Ибраһим исемле зат калган»*, — дип күрсәтелә [3. 179]. «Асар»ның II нче томында бу фикер тагын кабатлана. Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт турында язганда, Р.Фәхреддин әлеге хәзрәтнең улы Габделгалинең: *«Дамелла Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви күчеп киткәндә үз урынына имам булу һәм шәкертләр укыту өчен әтиебезне билгеләде»*, — дигән сүзләрен китерә [4. 22]. «Татар энциклопедиясе» авторлары исә «Гобәйдия» мәдрәсәсенең тарихын бары Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәттән генә башлана, дип күрсәтәләр: *«Мәдрәсәне нигезләүче һәм мөдәррисе авылның 3 нче мәхәллә имам-хатыйбы, дин белгече, шәригать белеме буенча аңлатмалар һәм хезмәтләр авторы Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт (1785-1845) була»* [1. 131]. Биредә, безнеңчә, бер урынга төзәтмә кертергә кирәк. «Асар»дан китерелгән өзекләрдән күренгәнчә, Бәйрәкәдәге мәдрәсәне нигезләүче Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт булмый. Ул 1815 елда мәдрәсәдә имам булып эшли башлаганда мәдрәсәгә инде күптән нигез салынган була. Алда әйтелгәнчә, Мөхәммәтшәриф

хәзрәт Бәйрәкәдән 1815 елда китә. Мәдрәсәнең «Гобәйдия» дип аталуы турында Кәшиф Рәхим болай ди: *«Гобәйдулла ишан заманга карабрак эш иткән. Мәдрәсәне «Гобәйдия мәдрәсәсе» дип игълан иткән. Анда шәкертләр куныл-ятып укыганнар, чөнки анда авыл кешеләренең балалары укытылмаган. Сирәк-мирәк кенә мулла һәм эре кулак балалары гына укыган»* [2. 4].

«Татар энциклопедиясе»ндәге мәкаләдә: *«Гобәйдулла хәзрәт үлгәннән соң, «Гобәйдия»дәге традицияләрне, абруйлы мөселман уку йортларындагы кебек, аның улы, күренекле суфи шәех (ишан) Габделвәли дәвам иттерә, аның уннарча мөриде була»,* — диелә [1. 131]. Биредә Гобәйдулла хәзрәт улының исеме дөрес күрсәтелмәгән. Р.Фәхреддин: *«Балалары: Габделгали, Әхмәдгали, Улкәй»,* — дип яза [4.22]. Габделгали бине Гобәйдулла бине Ибраһимның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә аерым мәкалә багышлый [5. 265-267]. Аның яшәгән елларын «1819-1901» дип күрсәтә [5. 265]. Габделгали турында: *«Казаннан 1841дә Бәйрәкәгә кайтып, имам вә мөдәррис булды. Атасыннан калган мәдрәсәне тараттмый дәвам иттерде вә соң вакытларда мөридләрне тәрбия кылу белән шөгыльләнде»,* — ди [5. 265]. Кәшиф Рәхим дәфтәрендә дә Гобәйдулланың улы Габделгали икәнлеге әйтелә. Габделгали бине Гобәйдулла чыннан да бик диндар һәм галим кеше булган. Р.Фәхреддин аның шәригать мәсьәләләренә багышлап язган татарча бер, гарәпчә өч хезмәтен атый, аның үзүзен ничек тотуын, әхлак сыйфатларын тасвирлый. Ул хәтта йортында янгын чыгып, тиз арада өч баласы янып көлгә әйләнгән көнне дә, мәчеттә икенде намазын имам буларак укыткан [5. 266].

«XIX гасыр азакларында Бәйрәкә мәдрәсәсендә укучылар саны 700гә җиткән, — дип яза Кәшиф Рәхим. — *Әмма анда Бәйрәкә крестьяннарыннан укучылар булмаган. Булса да, берничә генә кеше — кулак, мулла яки мөрит балалары гына булган»* [2, 12].

Инде Габделгали хәзрәтнең эшен дәвам иттерүче балаларына килсәк, алар хакында Р.Фәхреддин: *«Мөхсин, Мәсгүд исемендә уллары безгә мәгълүм»,* — дип яза [5. 265]. Ә «Татар энциклопедиясе»ндә аларның исемнәре Мөксин һәм Мәсәгут дип, бик үк дөрес бирелмәгән [1. 131]. Габделгали хәзрәт вафатыннан соң (1901 ел), мөдәррис булып аның улы Мәсгүд калган. Р.Фәхреддин әлеге Мәсгүд турында зур хөрмәт белән искә ала, аны берничә урында «Мәсгүд мәхдүм» дип атый. Хәтта: *«Үзем дамелла Галимҗан хәзрәт соңында мөфти булыр өчен беренче дәрәҗәдә мөстәхикъ (лаеклы) адәм шушы Мәсгүд мәхдүм дип фикерләп йөридер идем. Аллаһы Тәгалә үзен без мөбталя (дучар) булган икъдар (авыр) вә даһия (зирәклек) гыйзамалардан (бөеклекләрдән) хәляс кылды (коткарды)»,* — дип яза [2, 267].

XX гасыр башында Мөхсин һәм Мәсгүд Гобәйдуллиннарның мәгариф өлкәсендә тоткан юнәлешләре турында Р.Р.Салихов һәм Р.Р.Хәйретдиновлар: *«Алар «Гобәйдия»дә реформалар эшчәнлеген киң җәелдерә, уку-укыту программасына география, математика, Россия тарихы, рус һәм татар телләре кебек дөньяви фәннәрне дә кертәләр»,* — дип язалар [1. 131]. Ә Кәшиф Рәхим исә моны башкача аңлата: *«Бәйрәкә мәдрәсәсенә яңалык кертүдә Гобәйдуллиннар теш-тырнаклары белән каршы торганнар. Ул заманда Бәйрәкә крестьяннары балаларына мәдрәсәдә уку өчен бик күп акча кирәк булган. Крестьян балаларыннан булган 3-4 укучы җәй көннәрендә акча эшләп кайту өчен Оренбург шәһәренә бара торган булганнар. Алар анда байларның йон юдыру эшендә, юл төзәтүдә эшләгәннәр... Тормышлары авыр булган. Акча җыйнау бик кыен булган. Шулай да алар шәһәр тормышы белән таныша алганнар. Тыш-*

тан гына булса да, рус мәктәпләре тәртибен күргәннәр. Шундыйлардан Сабит Рәхимов, Җәлалетдин Сираҗев, Яхин Ильяслар. Алар үзләре башлап яңача укуга нигез салганнар... Бу кешеләр укучыларны классларга бүлеп, грамотага өйрәтә башлаган. Үтә реакцион хәлфәләр Мөнир Вахиди, Шәмселманый Вахиди, Кара Мофаздал кебек кешеләр яңалыкчыларны кыйныйлар, аларга пычрак кушаматлар тагалар. Шулай да шәкертләр арасында яңалык тарала. Мәдрәсәгә әтисе Габделгали ишан урынына хуҗа булып килгән Мәсгүд Гобәйди — отставкадагы офицер — реакционерларга кискен каршылык күрсәтмәсә дә, яңалыкка да бик ачык каршы тормый. Шулай да мәдрәсәне алдынгы булып тәмамлаган Сабит, Җәләй, Ильясларны укытучылар итеп калдырмый. «Дегетче Җамай, пыяла күз Вәлиәхмәтләрнең халык арасында абруйлары юк», дип карый. Әмма шәкертләр, протестовать итеп тарала башлагач, ислахчыларны читтән эзләп китерергә мәҗбүр була. Сабит Рәхимов, чит илгә барып укып кайткач та, Гобәйдуллиннар аны Бәйрәкә мәдрәсәсенә укытучы итеп алуга каршы чыгалар», — дип яза [2, 13].

1910 еллар — «Гобәйдия» мәдрәсәсенең гөрләп чәчәк аткан чоры. Анда халкыбызның күренекле шәхесләре — галим Габдрахман Сәгъди, бертуган Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар укыта. Абыйлы-энеле Туйкиннар укыткан чорда мәдрәсәгә пианино кайтарыла, музыка дәресләре укытыла башлый. Яшерен рәвештә урыс теле дәресләре башлана (укытучы — Татьяна Герасимовна Алчинова укыткан). 1905-1922 елларда кызлар мәктәбе эшләгән. Бераздан рус-татар мәктәбе ачылган. *«Бәйрәкәдә рус-татар мәктәбе ачылу М.Гобәйдуллин инициативасы итеп күрсәтелә,* — дип яза Кәшиф Рәхим. — *Бу дөрес түгел. М.Гобәйди бу мәктәпне салдырмас өчен дә каты көрәш алып барган. Ата-бабаларыбыз күмелгән зират янына рус мәктәбе салу дөрес түгел, дигән фикерне таратКан»* [2, 20].

1911-1912 елларда *«Бәйрәкә мәдрәсәсендә дин генә түгел, ә фән дә укыталар»* дип, Самара управлениесенә шикаять җибәргәннәр. Шуннан соң Мәсгүд хәзрәт (мәдрәсәнең хуҗасы) шәкертләр арасындагы барлык фән китапларын җыйдыртып алып яшерткән. Самарадан тентү белән килгәннәр, әмма бернинди гаепле нәрсә тапмаганнар. Кайбер мәгълүматлар буенча, Мәсгүд хәзрәт Урта Азиядә хезмәт иткән кайсыдыр бер генералның адъютанты булган, шуңа күрә Бәйрәкә мәдрәсәсен Иж-Бубый мәдрәсәсе кебек туздыра алмаганнар, кулга алулар булмаган, бары тентүтикшерү белән генә чикләнгәннәр.

Бәйрәкә мәдрәсәсе халкыбызга күп кенә күренекле шәхесләр биргән. Алар арасында шагыйрь Сирин (1896-1969), шагыйрь һәм педагог Сәхәүетдин Миңлекәй (1895-1954), язучы Гариф Галиев (1903-1985), патриот шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй (1901-1944), язучы һәм педагог Кәшиф Рәхим (1905-1989), журналист Абдулла Вәлиев һәм башкалар бар.

«Гобәйдия»нең соңгы хуҗасы Мәсгүт хәзрәт 1921 елда тиф авыруыннан вафат булган, Бәйрәкә зиратында җирләнгән. Шуннан соң Бәйрәкә мәдрәсәсе озак яшәмәгән, 1924 елда ябылган.

Әдәбият:

1. «Гобәйдия»//Татар энциклопедиясе. II том. — Казан, 2010. — Б.131.
2. Рәхим Кәшиф. Бәйрәкә авылы. Кулъязма дәфтәр, 1-24 битләр. (Автор кулъязмасыннан 1990 елда Гайзуллина Римма Мансуровна күчереп язган.Текст 24 нче биттә өзелеп кала).
3. Фәхреддин Ризаэддин. Асар. I том. — Казан: Рухият, 2006. — Б.48.
4. Фәхреддин Ризаэддин. Асар. II том. — Казан: Рухият, 2009. — Б.22-23.
5. Фәхреддин Ризаэддин. Асар. III һәм IV томнар. — Казан:Рухият, 2010. — Б.265-267.

«ПЛИН ТӨШКӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ ЭШЛӘРЕ БИК ХАРАПТЫР...»

Раиф Мәрданов

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Герман сугышы һәм әсир бәетләренең егермегә якын төре саклана. Шундый бәетләр дәфтәренең берсен Әгерҗе районының Төрдәле мәчетендәге иске китап-язмалар арасыннан, мәчетнең имамы, язучы Габдулла ага Галиевнең рөхсәте белән, 2008 елның 21 декабрендә алган идек. Габдулла ага әлеге бәетләр дәфтәренең хуҗасы Мифтахетдин исемле картны бераз хәтерлим дип, әлеге кыйммәтле ядкярне Бану Кәримуллина тапшырганлыгын да искә алды.

Теркәлгән мәгълүматларга караганда, дәфтәр дошман әсирлеген үтеп, иясе белән бергә ватанга кайткан. Дәфтәрнең беренче кәгазендә мондый язмасы бар: «Ошбу дәфтәр иясе Төрдәле каръясенең Мифтахетдин Габделгалим угылы. Язылды 1915 нче елда, октябрьнең 10 нчы [көнендә]. Германда плиндә. Язгучы — Чөшле карь[ясенең] Мулламөхәммәд Галим... 1915 нче сәнәдә»[1]. Димәк, бу дәфтәрнең хуҗасы Мифтахетдин Габделгалим улы һәм андагы текстларның бер өлеше бүтән якташлары кулы белән дә язылган. Аларның икесе дә Чөшле авылы кешеләре: Мулламөхәммәд һәм Бәдретдин Бәһаветдин улы.

Дәфтәрдә язылган мәгълүматка караганда, Мифтахетдин Галимов 1915 елның 26 июль көнендә Варшава шәһәре янында әсирлеккә төшкән. 31 июльдә аларны Германиядәге бер шәһәргә чыгарганнар. Ул нинди шәһәр булуы төгәл әйтелмичә, «гурыт» (город, ягъни шәһәр) дип кенә аталган. Дәфтәрнең 31а кәгазендә урыс хәрефләре белән язылган «Айнс-Штимер, Кейрилис, Ревалде, Пост Ревалде Краж, Грауденс» атамаларының дөрес язылышлары шиклерәк булса да, аларның әсирлектә чагында күргән калалары икәнлеген чамаларга мөмкин. Мифтахетдин тоткынлыктан ике мәртәбә: 28 августта һәм 27 сентябрьдә туган иленә хат язып җибәргәнлеген теркәп куйган. Димәк, әсирләр өчен андый мөмкинлек тудырылган. Алман әсирлегендәге татарлар язмышын өйрәнүче тарихчы Искәндәр Гыйләҗев язуынча, *«әсирләр хокуклары турында кабул ителгән халыкара конвенцияләр нигезендә, алар туганнарыннан да хат яки посылка ала алган»*[2]. Туганнарыннан тыш, сугыш вакытында әсирләргә ярдәм итү буенча төрле хәйрия оешмалары да азык-төлек (шикәр, чәй,

[1] Татарстан Республикасының Әгерҗе районындагы, XVII гасырдан алып XX гасыр уртасына хәтле Төрдәле исеме белән аталып гомер сөргән авыл 1950 нче еллар башыннан үзенә ызандаш Кырынды авылының бер өлеше булып исәпләнә һәм хәзер дә рәсми рәвештә шул исем белән йөртелә.
Ә шушы ук дәфтәрдә күрсәтелгән Чөшле — Әгерҗе районындагы татар авылының исеме. Бу авыл халык телендә электән Чөшле (Шөшле) дип йөртелгән, ә әүвәлге һәм хәзерге рәсми атамасы — Яңа Аккуҗа.
[2] Гыйләҗев И. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре // Казан утлары. — 2014. — №3. — Б.170.

сохари, ярмалар), сабын, тәмәке кәгазе, кайчагында эчке киемнәр кебек әйберләрне посылка итеп юллап торган.



«Плиннәрнең бәете» кулъязмасы

Мифтахетдин Галимов үзләренең 1917 елда 17 июньдә Туфлерга килүләре һәм аннан соң ирекле эшкә керешүләре, өенә хатлар җибәрүе турындагы мәгълүматны теркәп куйган. Туфлер дигәне — Франциянең төньягындагы (хәзерге Нор Па-де-Кале регионындагы) шәһәр. Бу кала 1914 елда немецлар тарафыннан басып алынган. Әсирлектәге Галимовларны Туфлерга, күрәсең, ярым ирекле хәлдә эшкә җибәргән булганнардыр. Кызганычка каршы, М.Галимов ул хакта тулырак язмаган һәм аның әсирлектән тулаем азат ителеп, илгә кайчан кайтуы да билгесез. Бары тик дәфтәрендәге 1920 елның декабрендә «Нәүфилә туды» дигән язуына караганда, Мифтахетдин Галимов аңа хәтле туган авылына кайткан, дип фаразларга мөмкин. Аның әсирлектә теркәлгән язмалары арасында, «...получить Галиму Ижбулдину» рәвешендәге, этисенең адресы да бар.

Архивлардан эзләнеп ачыклавыбызча, Төрдәле авылының Габделгалим Ишбулдинның Мифтахетдин исемле улы 1888 елда туган. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында армияне тәэмин итүне көйләү өчен 1917 елда Россиядә уздырылган авыл хуҗалыгы эшчәнлеген исәпкә алу документларында М.Габделгалимов турында мәгълүмат табылды. Бу исәп алу Алабуга өязендә 1917 елның май-июнь айларында уздырылган. Мифтахетдин ул вакытта этисе хуҗалыгында язылган һәм аның мобилизация буенча 30 ай өйдә юклыгы теркәлгән. Аның 30 яшьлек хатыны һәм 2 яшьлек улы булганлыгы да язылган. Димәк, Мифтахетдин Галимов сугышка 1914 елның ахырында алынган һәм үзе киткәннән соң улы дөньяга килгән икән. 1917 елгы исәп алу документларында язылганнарга караганда, ул вакытта Төрдәле авылының 75 ир-егете мобилизация һәм набор буенча сугышта һәм хәрби хезмәттә булган[3].

Мифтахетдин Галимов дәфтәрендә исеме язылган Чөшле (Яңа Аккуҗа) авылының Бәдретдин Бәһаветдинев (1887 елда туган) 1917 елгы доку-

[3] Татарстан Республикасының Милли архивы (ТР МА). — 991 фонд, 1 тасвир, 153 саклану берәмлеге, 155-156 кәгазьләр; 991 фонд, 2 тасвир, 290 сакл. бер., 117-117об. кәгазьләр; Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле. — Казан: «Тамга» нәшр., 2011. — Б.180.

ментта мобилизация буенча 36 ай өйдә булмавы, аның 28 яшьлек хатыны барлыгы теркәлгән. Өйдә булмау вакытын исәпләп караганда, Бәдретдин сугыш башлангач та, ягъни 1914 елның җәендә үк, фронтка алынганлыгы ачыклана. Шул ук авылның архив документларында язылган Мулламөхәммәд Нәфыйков та (1887 елда туган) Мифтахетдин дәфтәрендә исеме күрсәтелгән кеше булса кирәк. Дәфтәрдә аның үз исеме тулы укылса да, әтисенең исеме «Галим...» рәвешендә генә танылa, күрәсең, аның фамилиясе Нәфыйков булгандыр, дип фаразлыйбыз. 1917 елгы исәп алу вакытында М.Нәфыйковның мобилизация буенча 24 ай дәвамында өендә юклыгы теркәлгән, аның 23 яшьлек хатыны һәм 5 яшьлек улы булган. Димәк, әлеге Мулламөхәммәд сугышка 1915 нче елның язында алынган[4]. Чөшле (Яңа Аккуҗа) авылыннан да 1917 елда сугышта һәм хәрби хезмәттә булучылар саны 75 кешене тәшкил иткән[5]. Гомумән, Төрдәле һәм Яңа Аккуҗа авыллары документлары нигезендә фикер йөрткәндә, яше буенча туры килгән һәм сәламәтлеге яраклы ир-егетләрнең күпчелеге сугышка алынган булган. Кайбер гаиләләрнең берничәшәр кешесе (атасы һәм улы яки бертуган ага-энеләр) сугышта булганлыгы күрсәтелгән. Шул ук вакытта Яңа Аккуҗаның Бәдретдин Бәһаветдинев кебекләрнең тормыш итәр өчен төп чыганагы — мал-терлекләре бөтенләй калмаган һәм чәчелгән игеннәре дә аз булганлыгы күренә. Ягъни, әлеге сугыш Россия империясендә яшәгән бөтен халыкны һәм һәрбер кала-саланы зур хәсрәткә салу белән бергә, мохтаҗлыкка төшергән.

***

Игътибарыгызга татар солдаты Мифтахетдин Габделгалим улының күләме 74 биттән торган дәфтәреннән «Плиннәрнең бәете»н тәкъдим итәбез. Әмма аңа кадәр берничә мәгълүмат биреп үтәсебез килә

«Плиннәрнең бәете»ндә яманлап, «житлар» сүзе белән телгә алынган бәндәләр бар. Билгеле булуынча, «жид» дип, гадәттә, яһүдләрне атаганнар. Ләкин әсирләргә багышланган бәеттәге «жит» сүзендә, ихтимал, немецлар әсирләр арасыннан билгеләп куйган күзәтеп эшләтүчеләр яки бүтән төр җаваплы кешеләр күздә тотылгандыр. Андый атама бәет текстында «Нимесләргә суктыралар каһәр суккан шул житлар», «Каһәр суккан шул житларны эшкә һич тә йөртмәйләр», «Каһәр суккан кара житлар безгә булды ыстарший» дигән юллар да очрый. Әсир офицерларның еш кына гади тоткыннар өстеннән күзәтче итеп куелуы һәм аларның аеруча кансыз һәм вәхшиләрчә котырынулары турында галимнәр дә яза[6].

«Плиннәрнең бәете» тәгаен әсирлек вакытында иҗат ителгәнлеге исеменнән үк күренеп тора. Текстындагы «Газиз рамазан аенда плен төшеп без яттык» дигән юлларына һәм 1915 елның июлендә әсирлеккә төшүләре турында дәфтәр иясе Мифтахетдин язып куйган мәгълүматка караганда, бу бәет тоткынлыкка эләккәннән соң, озак та үтмичә, языла башлаган, дияргә мөмкин. 1915 елның июль ае — һиҗри календарьның рамазан аена тулаем диярлек туры килгән. Шулай ук Мифтахетдин дәфтәрендәге «31 июльдә герман җиренә чыктык» дигән һәм әсирлек бәетендәге «Егерме тугызынчы агусда бәет яза башладым» дигән юлларга караганда, әлеге әсәр Германиядә вакытта иҗат ителгән булуы аңлашыла.

[4] ТР МА. — 991 фонд, 2 тасвир, 338 сакл. бер., 75, 79 кәгазьләр.
[5] ТР МА. — 991 фонд, 2 тасвир, 338, 341 саклану берәмлекләре.
[6] Абдрашитов Э. О социальной ностальгии российских военнопленных в I мировой войне // Социологические исследования. — 2006. — №4. — С.133.

ПЛИННӘРНЕҢ БӘЕТЕ*

Бисмилләһи вә билләһи,
Житте корбан гаете.
Без укыек, сез тыңлагыз,
Ошбу плин бәете…

…Бик килешсез, бик ямьсездер
Нимесләрнең атлары.
Мөселманны бик ярата
Нимеснең солдатлары.

Җизләр белән җалтыраткан
Нимесләрнең шапкасы.
Май да салмай, ит тә салмай
Плингә пешкән ашы.

Рәхәтләнеп җөреп булмай,
Плиннәргә тар ишек.
Эшкә куып алып китә
Плиннәрне памишшик.

Иртә кофе эчкәндә
Шикәре җук тешләргә.
«Памишшик яхшы ашата», — дип,
Плин китә эшләргә.

Таяк белән килеп суккач,
Плин мескен йыглайдыр.
Итексезгә итек бирмәй,
Яланаяк йөридер.

Германнар аш өләшкәндә
Бармакларын кергезә.
Һәр көндә өч-дүрт сәгать
Правилкәгә йөргезә.

Нимесләрнең фурәшкәсе —
Җалтыраган беризин.
Аю өрәткән урыс кебек,
Кулларында эризин.

Егерме тугызынчы агусда
Бәет яза башладым.
Герман плин алгачтын,
Туган илне ташладым.

Иртә торып тышка чыксам,
Агач башы шеш кебек.
Без плиндә ятамыз
Читлектәге кош кебек.

Германнар туп аталар,
Акупларны ваталар.
Кемнең газиз балалары
Плин төшеп җаталар.

Машиналар кычкыра
Чуен җулы буенда.
Плин мескен йыглап йөри
Ашка интеккән көндә.

Герман дошманның тубы
Бигрәк каты төшә икән.
Солдат мескен чыдай алмай,
Шунгар плин төшә икән.

Плин чыгып киткәчтен,
Каршы алды казаклар.
Аста җук, өстә җук —
Бу ниндәен газаплар?!

…Германнарны күргәчтен,
Төне-көне атыштык.
Газиз рамазан аенда
Плен төшеп без яттык.

Бездин калган киемнәрне
Чүдин-чүгә[1] элеңез.
Аяз көнне томан булса,
Без йыглай дип белеңез.

Плиннәрнең күз яшенә
Аккош булып очарсың.
«Плин» дигән агыр хәсрәт,
Ходай үзе коткарсын.

Плиннәрнең күз яшенә
Балык булып йөзәрсең.
Суткәсенә чирек икмәк,
Ничек итеп түзәрсең.

Казаклар күп киткәчтен,
Ятып коедан су алдык.
Кяферләрдин аергач,
Мөселманнар куандык.

*Бәет кыскартылып бирелә. Тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.
[1] Чүдин-чүгә — чөйдән-чөйгә.

Мөэминнәргә ярдәм биргел,
Җан җараткан Ходамыз.
Кичке сәгать алтыда
Павиркәгә торамыз.

Кичке сәгать бишләрдә
Ашау алып кайтамыз.
Мөселманнар җыелышып,
Шаулап тәкбир әйтәмез.

Германнар аш өләшә,
Ашларында бәрәңге.
Ашамаенча ач йөргәч,
Якты дөнья караңгы.

Безнең җаткан җиремез —
Җир астында барактыр.
Плин төшкән кешеләрнең
Эшләре бик хараптыр.

Кофе белән бәрәңге —
Безнең ашаган ашымыз.
Плиндә бик михнәт күрә
Безнең газиз башымыз.

Туганнарым исемә төшсә,
Кан-яшь белән йыглата.
Ашларында дуңгыз мае —
Күңелләрне болгата.

Безнең яткан урынымыз —
Кара туфрак эчендә.
Акупада җаткан вакытым
Куркытадыр төшемдә.

Германнар аш биргәндә
Мискәләрең тулсайде.
Күп михнәтләр күрде башлар,
Соңдин рәхәт булсайде.

Безнең турда машина,
Искән җил тик бара ул.
Безне эшкә алып барганда
Як-ягымызда каравыл.

Нимесләр сигнал кычкырткач,
Чәйгә җыелып барамыз.
Туганнарым! Сагынсаңыз,
Айга чыгып караңыз!

Чәйне алып кайткачтан,
Баракларга керәмез.
Икмәге җук, карын ач,
Шикәрсез чәй эчәмез.

Германнар аш өләшкәндә
Ашы безгә җитмәде.
Рамазан шәриф рузәләрен
Ходай насыйп итмәде.

Туган-үскән илләремезне
Безләр киттек бит ташлап.
Плиннәрнең кигәне —
Агачтин ясаган башмак.

Плиннәрнең йөзе шунгар сары —
Көне-төне эшләгәч.
Агач башмак шунгар авыр —
Бернәрсәсез эшләгәч…

…Без плингә төшкәчтен,
Нимесләр күп җыелды.
Агач башмак киеп йөреп
Аякларым суелды.

Нимес телен һич белмәймез,
«Лос[2], лос!» — диеп акыра.
Аякларны бик авырттыра,
Һич йөрмәймез такырда.

Ул башмакны кигезеп,
Җибәрәләр эшләргә.
Эштән кайткач аш бирәләр,
Икмәге җук тешләргә.

Пазитсәдә вакытта
Комда ятып җокладым.
«Плин — яман», — дигәннең
Нәсыйхәтен тотмадым.

Аю баласы кебек,
Нимесләрдә бар атлар.
Нимесләргә суктыралар
Каһәр суккан шул житлар.

Нимесләрнең бакчасына
Плиннәрне кертмәйләр.
Каһәр суккан шул житларны
Эшкә һич тә йөртмәйләр.

Плиннәрнең җук кадере —
Комда ятып йоклайдыр.

[2] Лос — los, әйдә.

Плиннәрне җәлләмәй,
Резин белән тукмайдыр.

Плиннәйдә шундай да бар —
Тегүченең остасы.
Каһәр суккан кара житлар
Безгә булды ыстарший...

Ниместә җаткан плиннәр
Илен искә төшерә.
Атнасына бер мәртәбә
Кишердән аш пешерә.

Кайда барсаң, плиннең
Хәсрәтләре артадыр.
Йөз пот төягән арбаны
Плин мескен тартадыр.

Иртә торгач, плиннәр
Ыстройга тезелә.
Үткән рәхәт искә төшсә,
Ач үзәкләр өзелә.

Нимес эшен эшләйдер
Плин көн дә, кичен дә.
Безнең яткан урынымыз —
Ат кәнүшнәй эчендә.

Плиннәрне бик кыйнайлар
Шул эшләгән эшендә.
Кайсыларымыз качып кала
Кара урман эчендә.

Безгә биргән ашлары —
Эчереп беткән бәрәңге.
Безнең җаткан кәнүшнәемез
Көндезләр дә караңгы...

...Бер Ходайдин мир сораймыз,
Кабул булмай теләкләр.
Якшәнбә көн бер аш бирә,
Өзелә безнең җөрәкләр.

Прагулкәгә җөргәндә:
«Лос, лос!» — диеп куадыр.
Таман салкын су белән
Плин күлмәк җуадыр.

Арба илән бәрәңге
Плиннәргә тарттыра.
Арба тартмаган плиннәрне
Камчы белән кыздыра.

Нимес килеп сукканда
Күзгә яшьләрем тула.
Әй, Ходаем! Рәхмәтең киң,
Хәляс кыйлсаң ни була?!

Чахаузда[3] эшләгәндә
Буяламын күмергә.
«Лос, лос!» дигән нимес тавышын
Онытмамын гомергә.

Нимесләрнең атларының
Кыска икән койрыгы.
Без плиндә булмас идек,
Бер Ходайның боерыгы.

Катып беткән, череп беткән
Ашка салган борчагы.
Симерткән симез дуңгыз кебек,
Нимесләрнең корсагы.

Плиннәрне җөргезә
Каты искән җилләрдә.
Безнең ризык калган микән
Туган-үскән илләрдә?..

Кызыл сукна бәйләгән
Пираватчик кулына.
Карай-карай күзләр талды
Русия җулына.

Сандугачның аласы
Очып куна богдайга.
Плин төшмәгән кешеләр,
Шөкер итеңез Ходайга[7]!

Нимес, дигән, усал, дигән,
Жит, әләкче, дигән.
Безнең куанычлы көннәр
Кая узып китте икән?

Безләр плиндә ятканда
Укыдык Корбан гаетен.
Ошбу җирдә тәмам кыйлдым
Сезгә плин бәетен. ■

---

[3] Чахауз — шахтадан чыгарылган күмерне эшкәртү урыны; немец телендәге schachthaus (шахтхауз) сүзеннән.
[4] Кулъязмада: Аллага. Ләкин «богдайга» сүзенә «Ходай» сүзе рифмадаш булганлыгы аңлашыла. Бу очрак бәетне дәфтәргә язучының техник хатасы гына дип исәпләнергә тиеш.

КЕМ УЛ ЗАКИР ГАЛИЕВ?

Җәүдәт Миңнуллин

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсендә: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», – дип яза. Мәгълүм ки, шагыйрь иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүче галимнәр тарафыннан бу юнәлештә шактый эш башкарылды. Әмма барысы да эшләнгән, дип әйтергә иртәрәк әле. Тукайга бәйле булган күп кенә шәхесләрне яки вакыйгаларны ачыклыйсы бар. Шагыйрьнең юмор катыш хикәяләү белән язылган «Мәкаләи махсуса» исемле юлъязмасында да бар андый ачыклыйсы урыннар. Аларның берсе Тукайның Уфадан Троицкига баруы белән бәйләнгән.

1912 елның 15 маенда кымыз эчеп дәваланырга барганда Тукай Уфадан Троицкига юлга чыга. Әмма поезд кузгалыр алдыннан гына билетның ялгыш алынганы мәгълүм була. Ягъни, Полетаевка станциясенә кадәр алынасы билет, Чиләбегә туктамый бара торган поездга алынган икән. Шуннан соң Тукайны Троицкига озатуда турыдан-туры катнашкан күренекле галим, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбарый Баттал (1880-1969) Чиләбедә сәүдәгәр Галиевләргә телеграмма белән хәбәр итәргә тәкъдим итә. Шагыйрь моны кире кага. Әмма Г.Баттал, шагыйрь рөхсәт итмәсә дә, Чиләбедәге танышы, *«могтәбәр сәүдәгәр Закир әфәнде Галиевкә»* түбәндәге телеграмманы суга: *«Челябинск, Закиру Галееву. Встречайте Тукаева шестым. Нездоров, Баттал»*[1].

Тукай Чиләбе вокзалына килеп төшүен мәкаләсендә түбәндәгечә тасвирлый: *«Чиләбе вокзалына төшсәм, өст-баш яхшы бер мөселман миңа туғъры карый вә һаман янымнан бара. Мин, сизенеп:*

— Абзый, сез мине таныйсызмы әллә?

— Сез фәлән түгелме?

— Әйе.

— Мин Галиев булам. Сезне алырга килдем».

Шуннан соң Тукай Чиләбе каласында сәүдәгәр Галиевләр йортында кунак була. Чәй эчеп ял иткәннән соң, бу «мөхтәрәм әфәнделәр» (Тукай сүзләре) шагыйрьгә иптәш тә табып, аны ат белән Троицкига озатып җибәрә.

Тукай әсәрләрен басмага әзерләүчеләр 1986 елда нәшер ителгән 5 нче томга бирелгән искәрмә һәм аңлатмаларда *«Чиләбедә Галиевләр — урта кул сәүдәгәр»* дию белән генә чикләнгән (Б.273). Бу вакыйганың эчендә кайнаган Габделбарый Баттал исә сәүдәгәр Галиевне исемләп *«могтәбәр сәүдәгәр Закир әфәнде Галиевкә»* дип яза. Сорау туа: кем соң ул Закир Галиев, уртакул сәүдәгәрме, яисә могтәбәр сәүдәгәрме?

XIX йөзнең 60 нчы елларында, ягъни Россиядә крепостнойлык тәртипләре бетерелгәч, ил кызу темплар белән индустриаль җәмгыять нигезләрен төзи башлый. Яңа завод-фабрикалар салына, тимер юллар челтәре, шәһәрләшү процессы көннән-көн үсә. Ил күләмендә барган бу катлаулы процесслардан татар халкы да читтә калмаган, әлбәттә. Җирсезлектән, ди-

[1] Баттал Г. Габдулла Тукаев (Искә төшерү) / Г.Баттал // Кояш. — 1913. — 17 апрель.

ни-милли изүдән җәфаланган меңнәрчә милләттәшебез туган якларын калдырып, бәхет эзләп Урта Азия, Казакъстан, Урал якларына агыла. **Казан губернасы һәм өязендәге Наласа авылында** 1856 елда дөньяга аваз салган Закир Гали улы Галиев тә шулар арасында була[2]. Язмыш аны Чиләбе якларына китерә. XIX йөз ахырларында тиз темплар белән үскән Чиләбе шәһәрендә татарларның үз заманы өчен шактый ишле төркеме оеша. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда шәһәрдәге 897 мөселманның 700ен (78%) татарлар тәшкил иткән[3].

Тора-бара татарлар сан ягыннан

[2] Боже В.С. Галеев Закир Галеевич // Челябинск: Энциклопедия /Сост. В.С.Боже, В.А.Черноземцев. — Челябинск: Каменный пояс, 2001. — С.174; Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Челябинского края (XVIII — начало XX в.). — М., 2011. — С.167-169.
[3] Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897г. Т.XXVIII. Оренбургская губерния. СПб., 1904. — С.54-57, 70-71.

гына түгел, төбәкнең икътисади һәм иҗтимагый-мәдәни тормышында да әһәмиятле роль уйный башлый. Кичәге крестьяннар, мещаннар арасыннан миллионнар белән эш итүче сәүдәгәр, эшкуарлар үсеп чыга. Чиләбе мөселман-татар җәмгыятенең бер үзенчәлеге аның икътисад һәм мәдәни өлкәләрдә Троицк белән тыгыз элемтәдә торуында. Даими рәвештә Троицкида яшәүче татар сәүдәгәрләренең шактые Чиләбедә контора, кибет, складлар тотканнар. Закир Галиев иң әүвәл Чиләбедә Троицкидагы «Бертуган Яушевларның сәүдә йорты» вәкиле булып хезмәт итә. 1906 елда ул мөстәкыйль рәвештә ашлык, бакалея һәм мануфактура товарлары белән сату эшенә керешә, Чиләбедәге он тарттыру ширкәтенең пайчысы була һәм 2 нче гильдия сәүдәгәр дәрәҗәсенә күтәрелә. 1909 елда аның байлыгы 100 мең сум исәпләнә, каралтылары белән 5 йорт, 2 лавка аның милкендә була. 1918 елда аларның бәясе 500 мең сумга җиткән.

Эшлекле сәүдәгәр җәмәгать эшләреннән дә читтә тормаган. Ул Рус сәүдә-сәнәгать, Берләшкән һәм Дәүләт банкларының исәп-хисап комитеты, хосусый Себер һәм Идел-Кама, Дәүләт банкларының Эрбет ярминкәсендәге вакытлы бүлекләрендә әгъза булып тора. 1894 елдан З.Галиевне Чиләбе шәһәр думасына гласный, ягъни депутат итеп сайлыйлар, 1912 елдан ул Чиләбе кызлар гимназиясе химаячеләре шурасында, ә 1914 елдан сәүдә мәктәбе химаячеләре әгъзасы. 1913 елның 1 гыйнварында эшлекле сәүдәгәр Владимир тасмалы көмеш медаль һәм шул ук елның 30 маенда Романовлар династиясенең 300 еллыгы истәлеге уңаеннан бронза медаль белән бүләкләнә.

Могтәбәр сәүдәгәр Чиләбе татар-мөселман җәмгыятендә генә түгел, империя масштабындагы милли хәрәкәттән дә читтә тормаган. Закир Галиев 1905 елның 15 августында мөселманнарның Беренче Бөтенрусия корылтаенда Чиләбе вәкиле буларак катнаша, «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыруга 1 мең сум акча иганә кыла. Шул ук партиянең 1906 елның 13-23 гыйнварында Санкт-Петербургта узган II корылтаенда да делегат сыйфатында катнаша[4].

Закир Галиев Чиләбе татар-мөселман җәмгыятенең дә иң эшлекле әгъзаларыннан була. Ул — Чиләбе мөселман татар китапханәсенең фәхри, ягъни мактаулы әгъзасы[5], мөселман хәйрия җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы һәм идарә әгъзалыгына кандидат[6]. Чиләбе мөселман зираты ихатасын торгызу өчен акча җыйганда да ул бертуганы белән иң күп иганә итүчеләрдән була[7], авыл мәчетләрен төзүгә дә (мәсәлән, Татарстанның хәзерге Зәй районына кергән Чыбыклы авылы) булыша[8].

Шуңа күрә Габделбарый Батталның Тукайны каршы алу үтенече белән Закир Галиевкә мөрәҗәгать итүе очраклы хәл булмый. Бу могтәбәр сәүдәгәрдә дин һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Баруди (1857-1921) да кунак булып китүе мәгълүм.

Сүзне тәмамлап, шуны әйтергә кирәк: Чиләбедә могтәбәр татар сәүдәгәрләре шактый булган. Әмма Г.Баттал Тукайны каршылауны теләсә кемгә түгел, ә бәлки шагыйрьнең якташы, җырларда җырланган Наласа авылы егете, могтәбәр сәүдәгәр Закир Гали улы Галиевкә (1856-1919) тапшырган икән. ■

[4] Денисов Д.Н. Курс.хезмәт. — Б.169.
[5] Отчет Челябинской мусульманской бесплатной народной библиотеки — читальни. За 1912 г. — Миасс, 1913. — С.10.
[6] Отчет Челябинского мусульманского благотворительного общества, учрежденного в память юбилея 300 летия царствования Дома Романовых за 1914 год. — Челябинск: 1915. — С.16, 32.
[7] Чиләбе мөселманнарының дәхи бер һиммәтләре // Тормыш. — 1916. — 24 апрель.
[8] Минзәләдә // Вакыт. — 1906. — 3 октябрь.

Арча районы Гөберчәк авылында Мөхәммәт Мәһдиев музее

АВЫЛЫБЫЗ ТАРИХЫННАН БЕР КИСӘК

Мөхәммәт Мәһдиев

2000 елның 6 июлендә ТР Мәдәният министрлыгы һәм Арча районы хакимияте тарафыннан, Арча урман хуҗалыгы ярдәме белән Гөберчәк авылында Татарстан Республикасының халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Сөнгатулла улы Мәһдиевнең мемориаль музее ачылды.

Шул көннән башлап биредә, әдип һәм аның нәсел-нәсәбенә нисбәтле төрле мәгълүматлар, экспонатлар туплау белән бергә, Гөберчәк авылының да тарихы өйрәнелә. Ә инде авылыбызның тарихын Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» кебек әсәрләре һәм дистәләгән мәкаләләреннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Сезнең хозурыгызга да әдипнең музей фондында сакланачы «Авылыбыз тарихыннан бер кисәк» дип исемләнгән мәкаләсен тәкъдим итәм. «Арча хәбәрләре» газетасының 1991 елның 3 декабрь санында басылып чыккан әлеге язма төбәкне өйрәнүчеләр өчен кызыклы булыр, дип уйлыйм.

Мәкаләне укый башлаганчы, андагы кайбер мәгълүматларга тукталып үтик.

Авылыбызның әүвәлге мәчетен төзеткән игелекле шәхес Габдрахман Әхәт улы Ишморатов (1857-1922) — 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, җирбиләүче. Аның Арча районы Үрнәк авылында ат заводы, Казанбаш авылында май заводы, бәз мануфактурасы, Казанда чәй үлчәү-бүлү бинасы булган. Атларына күп мәртәбә Россия һәм чит илләрнең дәрәҗәле бүләкләре бирелгән.

Сөнгатулла абзый исә, Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе, заманында авылыбызның имамы һәм мөдәррисе булган. Музеебызда аңа нисбәтле экспозиция бар.

М.Мәһдиев Гариф Ахуновны Ярулла староста нәселеннән икәнлеген телгә ала.

Мәгълүм булганча, әдипнең әнисе Бибинур, Гөберчәк авылы кызы, Кече Өчиле авылының Ахунҗанына кияүгә чыккан. 2001 елдан авылыбызның бер урамы Гариф Ахунов исемен йөртә.

М.Мәһдиев «манара ук куя алмаслар инде безнең төбәктә», дип яза. Әдипнең 1991 елда ак кәгазьгә басылып калган хыялы 2005 елның ноябрендә генә гамәлгә ашты — авылыбызның үзәгендә өр-яңа мәчет халыкка иман нуры чәчә башлады. Әмма, музей төзелгән көннәрдә, данлыклы Габдрахман Ишморатов салдырган, Сөнгатулла хәзрәт имамлык иткән, йөз елдан артык тарихка ия мәчет бинасы авария хәлендә дип сүтелде, аның урынына башлангыч мәктәп төзелде. Кызганыч, 2014 нче елның сентябреннән бу мәктәптә укулар туктатылды.

Халидә Габидуллина,
Мөхәммәт Мәһдиев музее җитәкчесе

Гөберчәк авылына мәчетне XIX гасыр азагында-XX гасыр башында Казан арты бае Габдрахман Ишморатов салдырган. 1915 елга кадәр анда Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган Хәким хәзрәт муллалык иткән. Ул зур укымышлы кеше булган, чыгышы белән дә шул Кышкар ягыннан. Аның бер малае Нурислам Беренче Бөтендөнья сугышында үлеп калган, икенче малае Шәйхелислам авылның мөәзине булып хезмәт иткән. 1914 елны Хәким хәзрәт авырып китә. 1961 елда мин аның архивыннан «Кыйссаи Йосыф»ның бер кулъязмасын табып Казанга илтеп бирдем, гыйльми әдәбиятка ул кулъязма 37 нче сан белән кереп китте һәм ул бөтен дөньяга «Гөберчәк кулъязмасы, Мәһдиев нөсхәсе» дигән исем астында мәгълүм. «Кыйссаи Йосыф» китабында (1983, Казан) Хәким хәзрәт турында кыскача мәгълүмат та бар. Поэманы тикшергән игелекле галим Ф.Фәсиев Гөберчәк кулъязмасын текстология, графика һәм палеография (хәрефләр формасы) ягыннан әһәмиятле дип билгели.

Хәким хәзрәт авырып киткәч, Гөберчәк халкы яшь мулла эзли башлый. Бу хәбәр Сикертән авылында яшәүче бер тол хатынга ишетелә. Аның бөтен булган малайлары сугышка алынырга тиеш икән. Арадан берсе — Сөнгатулла исемлесе, мәдрәсә тәмамлаган икән. Тол хатынга әйтәләр: улыңны мулла итсәң, сугыштан калдырып була, дип. Чыннан да III һәм IV Дәүләт думасы депутаты Галиәсгар Сыртланов таләбе белән татар-башкорт муллаларын хәрби хезмәттән азат итү турында закон чыгарылган була. Тол хатын Шәмсикамал бу турыда хәбәрдар икән. Сугыш башлануга аның бер малаен алалар: карчык кайгыдан югалып кала, кулыннан эш төшә. Ике көннән соң (август башы) икенче улын чакыртып алалар. Карчык урынга егыла. Атна үтми — өченче улын, укымышлысын, аеруча яратканын сугышка алалар, карчык, хәсрәттән торып утыра һәм эшкә керешә. Гөберчәк авылына торып йөгерә һәм халыктан приговор җыйдырып, шуны күтәреп волостька чаба. Ул вакытта почта бик төгәл эшләгән, приговор һәм аның белән волостьның үтенече 10 августта Казан шәһәрендә урнашкан 95 нче запас батальонның командирына килеп керә. Беренче резолюция: «отказать». (Бу документларның барысы да миндә саклана.) Сөнгатулла солдатның 95 нче запас батальондагы 5 нче рота командирына язган «Докладная записка»сында аның Арчадагы урыс-татар училищесын уңышлы тәмамлавы, Оренбургтагы Диния нәзарәтеннән «имам-хатыйп, мөгаллим булырга яраклы» дигән белешмәсе булуы һәм Гөберчәк халкының аны мулла итеп сайлаулары (приговор) турында әйтелгән. Һәрхәлдә, бераз резолюцияләр сала-сала, аны Алатырьдан кайтарып җибәргәннәр. Тол карчык теләгенә ирешкән. Солдат кайткан — телисеңме, теләмисеңме, хәзер инде Гөберчәк авы-

Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе (уңда) **Сөнгатулла – патша армиясе солдаты. Вильно. 1907 ел**

Габдрахман Ишморатов төзеткән мәчет бинасы

лына барып Хәким хәзрәттән мәхәлләне кабул итәргә кирәк...

Әмма Гөберчәк авылы алпавыт Габдрахман Ишморатов йогынтысында. Мәчетне шул салдырган, димәк, мулласын да ул куярга тиеш. Г.Ишморатов, гадәттә, Гөберчәк авылындагы Мөсәгыйт байда туктый. Килә, авыл балаларына бушлай китап тарата, крестьяннарның ат нәселен яңарту буенча эш алып бара, мәчетне карап чыга. Бу юлы да, килгәч, авылның булачак мулласын Мөсәгыйт бай өенә чакырталар. Чәй мәҗлесендә Ишморатов әлеге солдатны сынап карый: мулла булырга яраклымы, юкмы? Ә тегесе ун ел буе Сатыш мәдрәсәсендә укыган. Алпавытка ошап куя бу егет һәм Ишморатов аңа фатиха бирә: авылны кабул ит, староста белән бергәләп халыкны тәрбияләгез, йорт-җир, урамтыкрыкларны, чишмәләрне карагыз, халыкның әхлагын күзәтегез. Ул вакытта авылда Ярулла исемле кеше староста була (мин аны әле картлыгында күреп белә идем, киң җилкәле, бияләйләре җиргә тиям дип салынып торган озын куллы мәһабәт карт иде, кырык беренче елда үлде, Гариф Ахунов шул нәселдән, дип беләм).

1915 елның 9 ноябрендә Гөберчәк авылында мәктәп ачыла. Төрле елларда туган малайларның (нигездә 1900-1905 елгылар) исемлеге булдырыла — барлыгы 57 малай. Боларның барысын да диярлек мин күреп белә идем, аларның

бик күбесе Ватан сугышы фронтларында һәлак булды. Сөнгатулла мөгаллимнең беренче «наборы»ның исемлеге миндә саклана. Мәкаләне язар алдыннан моны тагын бер мәртәбә карап чыктым: исәннәрдән ике генә кеше — Әхмәдуллин (Хәмитов) Нигъмәтҗан, Хәнәфиев Ислам Ватан сугышында яраланып кайттылар, агротехник, бригадир булып колхозга хезмәт иттеләр. Гөберчәк авылында алардан да өлкән берәү дә юктыр инде.

1936 елга кадәр мәчет эшләде. Муллалыгыннан 1918 елда рәсми рәвештә баш тартса да, Сөнгатулла кулында мәчет ачкычы саклана. 1929 елда латин хәрефенә күчкәнче («Яңалиф») ул шунда балалар укыта, 1930 елда «Яңалиф» буенча әзерлегем җитми», дип укытудан баш тарта. 1925-1926 елларда ислам дине, аның халыкка зарары турында күп җирдә дискуссия-бәхәсләр оештырыла. Бәхәс-дускуссиянең иң зурысы (1926 елда булса кирәк) Арчада уздырыла. Минем белүемчә (раслардык документларым кулда юк), бу дискуссиядә галим Г.Шнаси*, ике-өч тапкыр кыйбласын алыштырып, төрле Аллага хезмәт иткән шагыйрь Нәҗип Думави катнаша. Бәлки әле Богырослан мулласы, Октябрь борылышыннан соң татар муллаларының «кара эшләре», «ислам диненең халыкка зарары» турында китаплар язып, Мәскәүдә «Фән һәм дин» исемендә журнал чыгарып яткан, динне, Тукайны сүккән, ләкин үзен мөселманча җеназа укытып, юып, кәфенләп күмәргә васыять әйткән Чыгътай да (Галиәсгар Гафуров) Арчага килгәндер. Шул елның газета төпләмнәрен карарга кирәк. Һәрхәлдә, Сөнгатулла абзый ул бәхәсләрдә катнашкан, анысы — факт.

1935 елның ахырында булса кирәк, авыл советы һәм колхоз активистлары мәчет ачкычын алу өчен көрәш башладылар. Шәйхелислам мөәзин, аның урынына еш кына манарадан азан әйтүче Мөхәммәтсафа карт борчылып йөгерештеләр... Ачкычны Сөнгатуллага китереп бирделәр. Ләкин көннәрдән беркөнне власть ияләре аннан мәчет ачкычын алдылар һәм шул көнне мәчеттә «вичыр» ясадылар. Мәчет манарасына 1929 елда колхоз оешканда бер тапкыр флаг элгән булганнар инде. Ачкыч кулга кергәч ул флаг, манарада ук булмаса да, мәчет түбәсенә гел эленде. Сталин туган көнгә дә, Ленин үлгән көнгә дә, Париж Коммунасына да, 8 Мартка да... Мәчет ишегалды ямь-яшел тавык үләненнән генә тора иде. Без, бөтен урам малайлары, шунда уйнап үстек. Хәер, кызлар да. Хәтфә чирәм өстендә нинди генә йөгереш-куышлар, сынамышлар булмый иде...

1937 елның декабрендә авылның элеккеге мулласы, 1915-1929 еллардагы мөгаллиме Сөнгатулланы НКВД органнары кулга алды һәм, унҗиде көн төрмәдә тоткач, атып үтерде. 1939 елны мәчетнең манарасын кистеләр. Май ае иде. Мәчет янына кара болыт булып халык җыелды. Әни бу фаҗигане күрмәс өчен күрше Сикертән авылына йомыш табып китте. Манара шыгыр-шыгыр килеп озак чайкалды. Моны кисүчеләр Сикертән ТБУМнең (тулы булмаган урта мәктәп) математика укытучысы Фәизов Мәгъсум (Саба районы Оет авылы егете дип хәтердә калган) һәм Гөберчәк башлангыч мәктәбе укытучысы Гатият Әсәдуллин (Яңа Масра авылы егете) иде. Манара гөрселдәп ауды, аның цинктан коелган ике шарлы ае (өч метрлар чамасы озынлыкта) безнең бәрәңге бакчасына очып төште. Аны шундук пар ат җигелгән арбага салып Арчага озаттылар. Манара тактасыннан мәктәпкә утын лапасы, бәдрәф салдылар. Халык манара кисүчеләргә бик рәнҗеде, аларны каргады. Ни хикмәттер, шул ук җәйне М.Фәизовның кулы шеште, халык телендә «сырхават» дигән бер авыру бар, «Фәизовка сырхават

* Г.Шнаси — Габдулла Шөнаси — «Хөсәения» мәдрәсәсе, Казан университеты, Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты мөгаллиме. Татар телендә физика, химия, биология, медицина буенча дәреслекләр авторы.



Авылыбызның яңа мәчете

булган, кулы чери икән», дигән хәбәр таралды. Бераздан ул ниндидер бер махинациядә гаепләнеп төрмәгә дә кер-де бугай (бу турыда мәктәп ветераны, Иске Му авылында яшәүче Гөлниса апа Фәһмиева белә). Әсәдуллин Гатият исә Ватан сугышында һәлак булды.

Гомерләренең соңгы минутларында бу кешеләрдә халык күңелен рәнҗеткәннәре өчен үкенү хисе булгандырмы-юкмы, хәзер инде әйтүе кыен. Хәзер күп кенә ветераннар «заманы шундый иде», дип акланалар. Әмма, мәчет-манарасын кисәргә берәүне дә беркем дә мәҗбүр итмәде. Аны кискән өчен, әгәр ялгышмасам, күпмедер күләмдә акча да түлиләр иде кебек... Халкы ныграк торган авылларда манаралар исән калды.

Мәчет бинасы Гөберчәк авылында әле дә тора. Аның астында — клуб. Өске катын хәзер дә мәчет, китапханә итеп файдаланырга була. Хельсинкида (Финляндия) шулай, мин анда булдым. Шәһәр муниципалитетыннан бер бинаны алганнар да, шунда татар мәктәбе, шунда буфет, ашханә, намаз-нияз өчен зал, китапханә... И утыралар тройка-костюм кигән егетләр, и сөйләшәләр телефоннан, и басалар компьютер кнопкаларына... Безгә бит инде муллаларны болай тасвирлап килделәр: яшел чапанлы, капкорсаклы, таяклы, чалмалы... Без шулай тәрбияләнгән. Әмма Көнбатышта алай түгел. Хәтта Көнчыгышта да. Мулла аларда өч-дүрт тел белә, европача киенә, рок музыка да тыңлый, кинофильм да карый. Чит илләрдә диннән көлмиләр.

Ничек кенә булмасын, мәчет — изге, пакь урын. Аның янында гел пакьлек кенә булырга тиеш. Хәзерге тимер юл станцияләрендәге кабахәтлектән генә торган бәдрәф кебек нәрсәләрне мәчет территориясендә тотуны ислам дине тыйган. Мәчет яныннан кырык адым киткәч кенә үзеңнең табигый хаҗәтләреңне үтәргә мөмкин, дип өйрәткән ислам.

...Элек яшел-хәтфә чирәм белән түшәлгән Гөберчәк авылы мәчетенең ишегалдын күптән бетерделәр инде. Сугыштан соңгы елларда җитәкче иптәшләр гел читтән булды шул. Хәзер анда сазлык: трактор, комбайн борыла. Алар борылган җирдә нәрсә калганын без беләбез инде. Быел Апас, Чүпрәле, Буа, Чистай якларында халык мәчет салып ятканда, авылыбыз җитәкчеләренә мин дә язма рәвештә дәшеп карадым: манара ук куя алмаслар инде безнең төбәктә, һичьюгы шул ишегалдын сакларга иде... Юк, булмады. Балаларга тәрбия урыны булган элеккеге хәтфә ишегалдына быел ясин чыктылар. Манара кисүчеләрнең рухы әле дә яши. Бик кызганыч. Без бик кара як шул... ■

ИЗГЕ КОЙМА КЫЙССАСЫ

Зәки Зәйнуллин

...Әтием Лотфулла Зәйнуллин 1965 елның 22 апрелендә вафат булды. Әнисе Гөлмәрфуга әби, абыйсы Хәйрулла каберләре уртасына җирләдек. Берничә ел үткәч, Рәшидә апамның улы Салават әти каберенә сирень агачы утырткан. Кечкенә чыбыктан үсеп китеп, ул әтинең каберен тоташ томалап, әбинең һәм Хәйрулла бабакайның да каберенә күчеп, аларны да каплый башлады.

Узган гасырның туксанынчы еллар уртасы. Мин зиратта әтинең каберен тәртипкә китерәм. Теге сирень агачын тоташ кисеп ташлап, кабер өстен казыйм, сирень тамырларыннан каберне азат итәм. Шулай тырышып эшләгән бер мәлдә, зиратка унлап кеше килеп керде дә, капкадан ерак түгел генә яңа кабер казырга тотынды. Эшләвемнән туктап, кабер казучылар янына бардым.

— Әссәламегаләйкем! Кемгә казыйсыз?

Сәламне алдылар:

— Кичә кич Касыйм вафат булды бит, шуны җирлибез бүген.

— Кайсы Касыйм?

— Түбән Оч Пүликәр Касыймы. Әллә ишетмәгән идеңме?

— Ишетмәгән идем.

Касыйм! Беренчедән дүртенчегә кадәр бергә укыдык, бер урамда яшәгән идек. Әти каберендә эшемне туктатып, Касыймга кабер казыштым. Җирләдек минем сабакташны. Җитмешкә дә җитмичә китеп барды, бахыр…

Халык, Касыймны җирләгәч, зираттан чыгып китте. 1912 елда туган, Чишмә урамында яшәүче, колхозда комбайнчы, бригадада завхоз булып эшләгән Әгъзам абый Әхмәров исә минем янга килде:

— Калхузда бергә эшләгән малай идең бит син. Сөйләшим әле, дип килдем. Исәнме, Зәки?!

Эшне ташлап исәнләшәм. Үләнгә утырабыз.

— Сине бик зур палкауник, диләр. Дөрестер бит?

Елмаям:

— Полковниклар бар да бер чамада инде алар — погоннарында өч йолдыз.

Тукаевлар төрбәсендәге ташъязма

— Әтиеңнең каберен карыйсың икән...

— Каберенә якын килеп булмый — сирень басып китте.

— Бер елны мин туган тиешле бер бабайны Ырынбур янындагы Каргалы зиратына күмешергә бардым. Бер чардуган да юк. Куйдырмыйлар мәчет картлары. Нәкъ уртада җиде карагай үсеп утыра. Башка бер агач юк. Зиратлары тоташ ап-ак кылган белән капланган. Искиткеч матур була икән ул шулай. Безнең зиратның кайбер урыннарына керә торган түгел: тоташ чардуган, кабер өстендә әрекмән, әрем, шайтан таягы үсеп утыра — утап булмый. Син, Зәки, әтиең кабереннән дә, әниеңнекеннән дә чардуганнарны алгансың. Әниең каберендә җир җиләге, чия үсеп утыра. Әтиең каберенә дә күчә башлаганнар алар...

— Бу сиреньне бетерәм мин. Әтинең каберендә дә чия белән җиләк үсәчәк!

Башкортстанның безнең яктагы тау араларында кыргый чия үсә. Биеклеге бер-ике метрдан артмый. Илләмә дә тәмле инде. Бакча чиясе тәм ягыннан аңа җитми.

Сорый миннән агай:

— Зәки, син безнең зиратның таш коймасын ничәнче елны салганнарын беләсеңме?

— Беләм. 1908 елда салганнар.

— Каян белдең син аны?

— Керә торган капка башындагы ташка «1908 ел» дип язганнар бит. Аптырабрак сорый:

— Әллә син гарәп имлясын да беләсеңме?!

— Беләм. Җитмеш икенче елны өйрәндем.

— Алай икә-әң! Син, Зәки, миннән дә шәбрәк, әйбәтрәк, гыйлемлерәк икәнсең бит!

— Шулайдыр бик. Макта, Әгъзам абый...

— Мактыйм шул. Синең кебек егет — Эстәрлебашта бердәнбер! Зиратыбызның таш коймасын кем салдырганны беләсеңме?

— Кем салдырсын ди инде? Эстәрле халкы!

Әгъзам абый елмая, минем кем салдырганны белмәгәнгә шатлана:

— Түгел шул. Халык салдырмаган. Авылыбызның иң зур бае булган Гапкадыйр мәгъзүм турында ишеткәнең бармы?

— Бар, әти сөйләгән иде. Ул мәдрәсә мөдәррисе Харис хәзрәт Тукаевның төпчек малае булган. Патша биргән тархан дәрәҗәсе әтисеннән аңа калган. Атлы тарантас белән юлда барганда, тарханның, дугага эленгән кыңгырауларын яңгыратып, губернатор кибиткасын узып китәргә дә хакы булган. Бик комсыз иде Гапкадыйр мәгъзүм, дип искә ала иде минем әти аның турында...

Әгъзам абый бик җитди сүзләр белән миңа яңалык әйтә:

— Син белмәгәнне җиткерим әле. Бик әйбәт итеп хикәятләр язасың. Әгъзам абзый Әхмәров сөйләгән иде, дип берәр язу язарсың. Менә бу, безнең авыл зиратының асыл таш коймасын Габделкадыйр мәгъзүм тархан Тукаев тоташ үз акчасына эшләткән. Аның ике мең дисәтинә кара туфраклы җире булган. Шунда ул каты бодай үстереп, итальяннарга алып барып саткан. Тегеләр шул бодайдан үзләренең ыспагит дигән атаклы токмачларын ясаган.

— Зиратыбыз бик зур бит. Ул кадәр ташны кайда чыгарганнар?

— Авылдан сарык фирмысына барганда, Бакый Баткан елгасы күпереннән чыккач, уң якта биек Бакый Баткан тавы бар бит әле?

— Соң?!

— Шул тауның уң ягындагы яссылыкта җирне ачып, күп итеп таш чыгарганнар. Таш чыккан җирдән авыл очындагы зиратка турыдан юл салып, зират янына бер ел буена таш ташыганнар һәм койма итеп сала барганнар. Тарханның акчасы җитми башлагач, абзалары Мөхәммәтшакир белән земский начальник булып эшләгән

Габдерәхим Тукаевтан алып торып, соңыннан түләгән.

Менә сиңа комсыз тархан Гапкадыйр! Бу зират коймасына инде йөз ел тулып килә икән ләбаса.

— Син Гапкадыйр мәгъзүмнең кайда җирләнгәнен беләсеңме, Зәки?

— Беләм, Әгъзам абый!

— Кайда инде, син белгәнчә?

— Гражданнар сугышы елларында ул акларга ярдәм иткән. Бер полкныны, дивизиянеме ашаткан, киендергән. Унтугызынчы елны аклар белән качып чыгып киткән. Утыз икенче елны, трудармиягә чабата илткәндә, Урта Азиядәге Фирганә каласы янындагы хәрби совхозда Гапкадыйр мәгъзүмне безнең авылның Ябрәй Хәсәне күреп таныган. Шул совхозда атлар карап, конюх булып эшли икән, шунда үзе салган кечкенә саман өйдә яши, ди. Яшь хатыны Әсмабикә белән икәү генә…

— Син, Зәки, миннән дә күп беләсең. Ә үзең илле икенче елдан бирле зимагурлыкта йөрисең.

— Безнең авылның фаҗигале тарихы бит, Әгъзам абый.

Агай көрсенә:

— Коммунист-большевикләр халыкка бәхетле тормыш бирдек, дип никадәр генә шапырынса да, ялган ул. Гади халыкның канын күп эчте алар, нык изделәр. Мин моны сиңа курыкмыйча әйтәм. Син, Зәки, безнең чыпчын Эстәрле егете. Илләмә дөрес итеп, курыкмыйча язасың. Сиңа коммунистлардан нык эләккәндер инде?

Көләм:

— Булгалады инде, тик мин аларны истә тотмыйм, оныта барам…

Әгъзам абзый белән шул зират эчендә очрашып-сөйләшеп, чирәмдә утыру миндә һәрчак җылы истәлек тойгысы тудыра. Аны оныгы Венера бик яхшы итеп карады. Ул һәрчак пөхтә, матур, юылган киемнән йөрде. 2012 елда аңа йөз яшь тулды. Венера бүгенге көндә Әгъзам абзыйның сеңлесен карый. Район китапханәсендә эшли. Бик инсафлы, сабыр шәхес. Алла ярдәменнән ташламасын ул Венераны…

***

Узган гасырның алтмышынчы еллар башында Башкортстанның Эстәрлебаш район башкарма комитеты рәисе булып, чыгышы Мәчетле районыннан булган Нур абый Фәтхиев эшләде. Хәзер юк инде ул, вафатына егерме еллар чама-

сы. Эстәрлеләр, ул асыл татар егетен һаман онытa алмыйча, «Фәтхиев заманында», дип сагынып искә төшерә. Эстәрле авылының төньягында кырчынташтан, комнан торган 150-200 метр биеклектәге өч чакрымга якын текә таулар сузылган. Шулар аш тәлинкәсеннән юанрак карагайдан торган урман белән капланган. «Фәтхиев утырттырган агачлар алар!» — диләр бүген дә чын Эстәрле кешеләре.

Шул алтмышынчы еллар башында бер җомга көнне район башкарма комитеты рәисе Нур Фәтхиев Түбән Оч мәчетенә җомга намазына килгән. Ул мәчет картаеп вафат булган Гапкадыйр Күпкәк дигән бабайның кечкенә салам башлы йортында иде. Кергән Фәтхиев, туфлиләрен салып, алга үтеп, идәнгә җәелгән чүпрәк паласка утырып, җомга намазына кушылган...

Намаз тәмамлангач, Ибраһим мулладан рөхсәт алып алга үткән дә, картларга карап, аякларын мөселманча «бөкләп», чүпрәк паласка утырып, сүз башлаган:

— Абзыйлар, бабайлар! Минем сезгә, район рәисе буларак, бик зурдан гозерем төште. Рөхсәт итсәгез, шуны әйтергә килдем мин.

— Рөхсәт, Фәтхиев, сөйлә!

— Авылның зираты сез картлар карамагында. Ул бер чакрым озынлыкта таш койма белән уратып алынган. Шушы таш койманы башкарма комитетка бирегез. Аның урынына мин сезгә бик шәп тактадан яңа койма ясатам. Баганалар, такталар, борыслар, кадаклар, яшел буяу бүгеннән бар. Яшелгә буярбыз һәм 15 ел саен мин сезгә аны яңа коймага алмаштырып торырмын. Шул сезгә минем гозер. Мин буш йөри торган җитәкче түгел. Мәчетегезнең башы салам түбәдә, ул бик иске икән. Иртәгә үк эшчеләр килеп, салам түбәгезне сүтеп, башын шифер белән ябарлар. Уйлаша торыгыз мин әйткән тәкъдимне. Киләсе җомга намазына, сезнең карарны ишетергә дип, мин монда тагын килермен.

Мәчет картларының гәүдәгә иң бәләкәе Миңлебай Пичче рәис Фәтхиевка сорау бирә:

— Фәтхиев иптәш, таш сиңа нәрсәгә кирәк? Бик күп бит анда таш. Койма озынлыгы белән бер чакрымга җитә...

— Зур итеп культура сарае салырга иде авыл уртасында. Клуб урнашкан элеккеге зур мәчет бинасы нык тузды бит. Ул инде егерме өченче елдан бирле, район клубы булып, безгә хезмәт итте. Әгәр зират коймасын бирсәгез, ике катлы итеп, утыз биш метр озынлыкта, унбиш метр киңлектә культура сарае төзи алабыз.

Мәчет мөтәвәлие (мәчет, зират хуҗалыгын карап алып баручы) Сәлахетдин Песәй карар кыла:

— Фәтхиев туган! Без киңәшләшик мәчеттә. Икенче җомгага шушында җавап алырсың. Монда килергә вакытың булмаса, шул турыда безгә җиткер, үзебез сиңа керербез.

— Рәхмәт, килештек! Җомга намазына ярты сәгать кала килермен.

Алдагы җомгада мәчеттә очраша болар. Фәтхиев, идәндәге чүпрәк паласка утырып, сүз башлый:

— Мәчетегезнең башын шифер белән яптылар. Инде зиратның таш коймасы турында сез картларның карарын тыңлыйк.

Сүзне Сәлах Песәй башлый:

— Фәтхиев энем! Мәчет башын шифер белән яптырганың өчен сиңа рәхмәтләребез бик зурдан. Син безгә ярдәм иттең, инде без дә кулдан килгәнчә сиңа ярдәм итәргә булдык. — Тамагын кыргалагандай итә, дулкынлана. — Зиратның таш коймасы хакында без бик каты ыспурлаштык. Яшь чаклардагы кебегрәк итеп. Күпчелек тавыш белән, без — мәчет картлары, зиратның таш коймасын сиңа бирергә булдык. Шул менә...

Фәтхиевнең шатлыктан елмаюы чибәр йөзенә тарала, куанып кулларын уа. Сәлах бабайның сөйләгәнен бүлеп, үзенең куанычын белдерә:

— Илләмә дә шәп бабайлар инде сез...

Сәлахетдин бабай аңа карап ала да әйтә:

— Минем сүз бетмәде бит әле, улым...

— Гафу, бабай, әйтәсе карарны әйттең бит инде.

— Анысы әйтелде. Дөрес! Картлар таш койманы сиңа бирделәр бирүен. Тик аларның сиңа бер сораулары бар.

— Әйт, Сәлахетдин бабай, соравыгызны. Тыңлыйм.

— Син, Фәтхиев улым, утырган паласыңа тотын, ныграк тотын — безнең сорау бик хәтәр, тәгәрәп китә күрмә.

Картлар елмаеша, аларга карап, Фәтхиев тә елмая: «Койманы картлар бирделәр бит инде!» — янәсе...

— Сорау мондый, улым. Син таш койманы сүтеп алдың ди, аның урынына такта койма ясатып куйдың ди. Шуннан соң узды ди син әйткән унбиш ел. Инде такта койма тузган, яңаны ясатырга кирәк. Районда син хуҗа түгел — күчеп киткәнсең... Без, үлеп, Ходаебыз карамагына күченгәнбез. Бездән соңгы мәчет картлары керделәр ди син утырган урындыкны биләгән яңа рәискә. Әйткәннәрдер ди такта койма турындагы үтенечләрен. Ә ул картлардан сораса: «Сезгә яңа такта койма төзергә вәгъдә биргән Фәтхиев атлы бәндә кем булган ул?» — диеп.

«Ул — синең урында утырган элекке хуҗа», — диярләр.

«Мин сезгә такта койма ясарга вәгъдә бирмәдем. Договорыгызны мин знать ни знай. Юк сезгә такта койма, бар чыгыгыз минем кабинеттан!» — дисә? Яңа койманы яңа рәис ясатмаса, яңа мәчет картлары кая барырга тиеш булырлар икән соң?! Шул сорау безнең башта, улым Фәтхиев. Ә бит таш койма туза торган түгел — мәңгелек ул!

Рәис Фәтхиев башын иеп, чүпрәк паласка карап бик озак утыра. Аннары исә башын калкыта да:

— Мин, бабайлар, үземне акыллы гына егет дип санап йөри идем. — дип сүз башлый. — Түгел икәнмен. Таш койманы миңа бирдегез сез, ә сорагыз белән утка тыктыгыз да, аннан алып, бозлы суга салдыгыз. Аңладым мин үземнең сезнең кебек, акыллы татар бабайлары кебек, төпле итеп уйлый белмәгәнемне...

Тимим мин сезнең таш коймагызга. Һәм сез дә, кем генә сораса да, бирмәгез! Ул изге таш зират коймасы — Эстәрлебашның данлыклы тарихы һәм бик зур байлыгы. Юләр теләгем өчен сез картлардан гафу үтенәм. Нужагыз

Эстәрлебаш авылының борынгы зиратында – өмә. 2015, октябрь

чыкса, туры үземә керегез, һәрчак ярдәм итәрмен. — Шулай ди дә, кузгала башлый.

Мөтәвәли Сәлахетдин Песәй елмаеп, аны туктата:

— Фәтхиев улым! Китми тор әле! Без инде, картлар, сиңа сорау биргәч тә, таш койманы сүтеп алмаячагыңны алдан ук аңлап сөйләштек. Шунлыктан, сиңа үтенечебез бар.

— Сөйлә, бабай, тыңлыйм.

— Син таш койманы сораганда, такта койма ясарга багана, такта, киртә, кадакларым бар, әзерләр, дидең. Буявым да бар, яшел төстә, дидең.

— Нигә санаганыңны аңлап бетермим, бабай! Барысы да бар инде. Складта, ишегалдында яталар.

— Син, Нур улым, шул нәрсәләреңне бөтенләе белән безгә, мәчеткә бир дә куй инде!

— Нәрсә эшлисез алар белән?

— Без шул зиратның таш коймасын тагын бер такта койма белән уратып алып, буяп та куйыйк инде. Иртә-кич авыл көтүләре киткәндә-кайтканда маллар таш коймага кашынып-ышкынып, койманы ишәләр. Таш койманы төзегәндә азрак кызыл балчык кушып, кара туфракка утыртып төзегәннәр. Мал кашынганга ташлары җиргә коела.

Фәтхиев, исе китеп, чүпрәк палас өстендә тезелешеп утырган төрле зурлыктагы, төрле тазалыктагы Эстәрлебаш мәчете картларына сокланып, уң кулын һавада селтәп, шатланып көлеп җибәрә:

— Бирәм сораганыгызны! Бу кадәр асыл бабайларга ничек итеп атказайт итү ди! Бирәм, бабайлар. Үлми торыгыз әле! Мең яшәгез!

***

Бүген дә Эстәрлебаш зираты ике катлы койма белән уратып алынган: эчке койма — таштан, тышкысы — тактадан. Мәчет, эчке таш койманы унбиш ел саен яңа такта койма белән уратып, яшел төскә буятып куйдыра. Рәис Фәтхиевне искә алып, аңа рәхмәтләр укып эшлиләр ул такта койманы эстәрлеләр. Юк инде ул асыл татар егете бу дөньяда...

Әйе, менә шундый ике катлы зират коймасы бар Эстәрлебаш исемле зур вә данлыклы авылда. Борынгы Бохара-Болгар сәүдә юлында, тау астында, Эстәрле елгасының башында утырган авыл ул. ■

Фәнзаман Батталның Татарстан радиосында әдәби хезмәткәр чагы

Бер-ике сүз...

Шулай килеп чыкты ки, вазгыятьне тулаем аңлап та бетермәстән, миңа быел җәй бакыйлыкка күчкән Фәнзаман абый Батталның күпмедер дәрәҗәдә «варисына» әверелеп куярга туры килде. Ул журналыбызның дусты иде. Актив авторыбыз булды. Чираттагы килүендә өеп калдырган материаллары — соңгысы булыр, дип кем башына китерсен шунда? Җир җимертеп, табаныннан ут чыгарып йөргән чагы иде бит!

Ләкин әһле каләм, ни дисәң дә, бәхетле халык. Әйе: үзеннән соң язганнары кала аның. Инде яхшы язучы булса, тагын да куанычлырак: чөнки андый очракта үзеннән соң яхшы язганнары калачак. Бәй, бу — күпме бичара галим-голәмә бәһасез гомере бәрабәренә эзләп тә тапмаган үлемсезлек формуласы түгелме соң?

Фәнзаман абыйның бер күңел җимеше (әкият иде ул) көзлектә «Идел»дә дөнья күрде. Хәзер менә икенчесе «Безнең мирас»та урын ала... (Тагын бер материал бар әле, соңрак, үз вакыты җиткәч, анысы да басылыр, иншалла.) Нидән гыйбарәт ул — шушы язма? Өлкән каләмдәшебез Татарстан радиосында хезмәт куйган елларда (1984-1993) эшләнгән радиоочеркның кәгазь нөсхәсе: гепатит йоктырган битләр, машинкада җыелганда чәүчәләкләнеп китешкән кирилл хәрефләре... Ул бу материалның шушы рәвештә, әңгәмә шәкелендә, ремаркалар-ниләр белән бергә дөнья күрүен теләгән иде. Хәзер ачуланып килеп, редакцияләгән өчен «Бетергәнсең син моны!» дип «рәхмәт» әйтә алмый — иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун! — шулай да, беркадәр кул кертми булмады: сөйләм теле — сөйләм теле инде ул. Әдәби тел — үзгә.

Бераздан шунысы да ачыкланды: журналист Хәмзә Бәдретдинов очерк каһарманының (аның 1900-1993 елларда гомер кичермеше беленде) туган авылы турында «Борнаш иле» исемле китап чыгарган икән. (Без ул китаптан берничә фотосурәт «алып тордык».) Хәер, каһарманы, дидем дә... Әлбәттә, язманың бер генә кешегә багышланмавын, аның бер генә кеше тарихы булмавын син, кадерле укучы, тиз аңларсың. Бу — гомум ил тарихы. Барыбызныкы да, димәк...

Рүзәл Мөхәммәтша

БӨТЕН ӨМЕТ ЯШЬЛӘРДӘ

Фәнзаман Баттал

Казан сөйли. *(Музыка.)*

Яшьләр өчен тапшыруыбызны башлыйбыз. *(Музыка.)*

Яшьлек — гомернең ин садә, иң матур кисәге. Әмма еллар агышы һәрвакыт алга бара, кеше олыгая һәм күңеле белән әледән-әле яшьлегеннән урап кайта. Истәлекләрне бер-берсенә ялгый торгач, яшәгән гомеренә нәтиҗә дә ясый кеше. Төрле хатирәләрне, вакыйгаларны искә төшерә, яшьләр гыйбрәт алсын, тиешле бер фикергә килсен өчен кызыгын да, кызганычын да сөйләргә тырыша.

Бүгенге тапшыруыбызның кунагы — шундый вакыйгаларга бай гомере белән безнең гасырны тулаем күреп үткән кеше. Төгәлрәк таныштырыйк: исеме — Лотфулла, фамилиясе — Булатов, яши торган җире — Апас районының Борнаш авылы. «Бөтен өмет яшьләрдә» дигән радиоочеркның авторы — Фәнзаман Сәетбатталов. *(Әз генә музыка.)*

И тормыш! Шахтёр итеп ундүрт яшьтән җир астына да төшерде, Гражданнар сугышында да йөртте, шәхес культының бәгырьгә төшәрлек бимазасын да күрсәтте. Ватан сугышын башыннан ахырына кадәр кичте Лотфулла Булатов. Барысын да сөйләргә әзер. Әмма төп гаме — үз колхозы турында. Үзе оештырган колхоз хакында.

Булатов. Колхозыбыз егерме тугызынчы елның кышында төзелде. Без тәртәдән чыкмадык, гариза язган вакытта һәрбер кешегә аңлаттык: «Телисең икән колхозга керергә, чәчүлегеңне саласың, атыңны — тарту көчеңне бирәсең. Суканы, тырмаңны, атыңның абзарын да... Менә шулай, абзый кеше». Бик кыенсына бу. «Хатын белән, малайлар белән кайтып сөйләшик әле», — ди. Чәчүлекләрне өч урынга җыеп салдык. Һәрберсенә комсомоллардан каравыл куйдык. Мылтык бирдек. Бездә дә булды амбарларны ватарга, чәчүлекне алырга йөрүчеләр. Ирек бирмәдек. Язда беренче чәчүгә чыктык. Кыска вакыт эчендә чәчүне бетердек. Бик уңышлы булды.

Диктор. Лотфулла агай як-якка

Чордашлар (сулдан) **Кәбир Ибраһимов, Госман Ногманов, Лотфулла Булатов, Хәмидулла Әхмәдуллин. 1979 ел**

каранып ала да, тәрәзәнең зур гына өлешенә ишарә ясый. «Менә шуның кадәр кенәгәсе бар иде колхозның», — дип көлеп куя. Хуҗалыкның бөтен исәп-хисабы шул кенәгәгә сыеп беткән...

Булатов. Анда язылган «фәлән кеше» — фамилиясе, исеме... Аты шуның хәтле эшләде. Үзе эшләде. Таяк сызып барыла аңарга — учёт. Семьясында кем эшкә чыккан — һәрберсенә берәр таяк сызыла. Көз җитте. Хәзер икмәкне ничек бүләргә? Менә, җәмәгать, уйлашыйк... Фәләннең сыеры бармы? Бар. Сарыклары ничә? Фәлән хәтле. Тавыклары күпме, казлары күпме? *(Көлә.)* Кызыл флаглар күтәреп һәр хуҗалыкка китереп үк бирәбез. Икмәкне үлчәү юк — подаукалап өләшәбез. Тавык башына, каз башына, сарык башына, сыер башына... Икенче китергәндә: «Урыным юк, кирәкми, алып китегез», — диләр. Мондый хәлләрдән соң халык кызыксынды инде. Утызынчы елда йөз процент белән колхозга керделәр.

Диктор. Егерме тугыз яшьлек Лотфулла Булатов күреп яши ул чорда — кайбер авылларда колхозлашу рәхимсезлекләр, гаделсезлекләр белән бара. Болай да гасырлар буе иза чиккән халыкны тинтерәтүгә мөмкин кадәр җай калдырмаска кирәк. Колхозны халык чираттагы михнәт итеп түгел, өметле киләчәк итеп күрсен! Шул максатны куя партия ячейкасы секретаре. Азмы-күпме тәҗрибә дә ярдәм итә аңа.

Булатов. Без егерме дүртенче елда «кредитное товарищество» оештырдык бит. Егермеләп хуҗалык бергә эшләдек. Егерме тугызынчы елга хәтле барды бу. Анда күбрәк атсызлар кергән иде. Җитәкчесебез Бикмурзин Гариф бервакыт наркомземга, җир эшләре комиссариатына юл тотарга уйлады. «Вәт, җәмәгать, без баруын-барырбыз, анда бит хуҗалыкларның байлыгын, хәлен сорыйлар», — ди. Журнал ясаган икән. Күз алдында: «Булатов Лотфулла, тимер башлы ызбасы (анда безнең ике тәрәзәле, салам белән япкан ызба гына, югыйсә!), тимер башлы каралтысы, абзары бар, аты юк», — дип язып куйды. Һәрберебез турында шулай. Ярар, күрсәтә тегендә, ат сатып алырга акча сорый бит инде, моңа әйтәләр: «Ничек бу хуҗалыкка бирмәскә? Болар түли ала. Күрәмсең, монда нәрсә — атлары гына юк бу мескеннәрнең». Шулай итеп Гариф абый атлар да алып кайтты... Бәясен түләп бетерә алмаган идек, аннары хөкүмәт списәйт итте аны. *(Көлә.)*

Диктор. Кемнәргә генә кагылмады шәхес культының кара шаукымы! Революциягә ышанган, бөек максатларга омтылган кешеләрне дә халык дошманнары дип тамгалады бу шаукым, якты киләчәкне күрергә өметләнгән

«Почему сез раскулачивать итмисез?..»

җир улларының һәм кызларының күген кара болыт каплады.

Булатов. Берсендә нарследователь килде. Мин партия ячейкасы секретаре. «Почему сез раскулачивать итмисез муллаларны?» — дип бәйләнә. Мин әйтәм: «Соң, аның бурасы бар иде, бер сыеры бар иде. Ул работник тотмады. Җире шуның кадәрле. Без бу адымга бара алмыйбыз...» И, хәзер актлар төзеде-нитте! Тентү үткәрде. Җиденче елгы, уникенче елгы прокламацияләр табылды. Бер егерме штук. «Бу — нәрсә?» — ди. «Мин социал-демократлар партиясендә тордым, — ди мулла. — Без шундый прокламацияләр тарата идек». Анда болай язылган: «Сезнең яннарыгызда алпавытлар бар. Җирләрен алып чәчегез, урманнарын талагыз. Байлыгын яндырыгыз!» «Моны ник вакытында таратып бетермәдегез, ник калды бу?» — ди нарследователь. Теге әйтә: «Бит ул меңнәр иде бездә! — ди. — Кеше күрмәгәндә генә базарда ташлап китә идек», — ди. Барыбер вулыска чакырып судить иттеләр. Биш елга. Төрмәгә япмадылар. Үлгәнче Канашта эшләде, милиция атларын карады.

Диктор. Лотфулла Булатов авыр сулап куя мондый вакыйгаларны хикәя кылганда. Юк, җиңел түгел иде гөнаһсыз, гаепсез кешеләрне яклау. Кызгануыңны сизсәләр дә: «Син үзең дә контра түгелме?» — дип күзеңә текәлеп карыйлар иде.

Кайчандыр аты, сыеры булган өчен дә сөргенгә озаталар адәм балаларын ул дәһшәтле елларда. Хәзер Лотфулла Булатов кебек өлкәннәр мондый фикергә дә килә: авыллар бушап кала, дибез, кешеләр китә, дибез, колхозда яки совхозда эшләргә кадрлар җитми, дибез; үз авылларына, ата-баба нигезенә җаны-тәне белән бирелгән кешеләрне җирдән биздерү нәкъ шул чорда — утызынчы елларда башланды лабаса! Юк, булган-беткән афәт кенә түгел шәхес культы, аның дәвамы бу көннәргә дә килеп тоташа. Тарихның буеннан-буена изге дип саналган туган җиргә карата салкынлыкны, чит итеп, ят итеп карауны буыннар күңеленә дә салды ул еллар.

Булатов. Насыйбуллин дигән бер егет Казан университетын тәмамлагач Мәскәүгә, академиягә китте. Утыз беренче, утыз икенче еллар бу. Укып бетерергә өч ай вакыты калганда авылга кайтып төште. Ә без андыйларны чалгы белән борчак чаптырырга кырга алып чыга идек. Бу да шунда. Сөйләшергә утырдык. Ул инде күп белә...

Диктор. Ачлык елларында кайбер дәүләтләр безнең илгә азык-төлекләтә ярдәм итмәкче булалар. «Правда» газетасында «Без капиталистлар ярдәменә мохтаҗ түгел!» дигән эчтәлектәге язмалар басылгалап тора. Әлеге белемле егет шуларның берсен укып, халыкка болай аңлата: «Ялагайлар оештырган мәкалә генә бу, җәмәгать. Ил ачыга, ил икмәккә мохтаҗ. Халыкка башка илләрнең ярдәме бик кирәк».

Булатов. Аннан соң инде кереп китте эчкәрәк. Сталинга... Турыдан-туры әйтә: «Менә Сталин бар инде, надан бит ул. Маркcларга, Лениннарга карaганда — пионер гына», — ди. Без, билгеле, шикләнә калдык. Районнан Садыйков дигән уполномоченный да бар иде. Шул район НКВДсына җиткергән: «Ленин колхозына, Борнаш авылына бер студент кайткан, давай, тикшерегез. Аның сүзләре бик куркыныч». Килделәр. Тикшерделәр. Казаннан килеп суд үткәрделәр. Политический. Аңарга бирделәр илле өченче статьяның... икенчесе белән микән... унбиш ел. Хәзер, суд беткәч, үзен сөйләтәләр. «Менә син шулай дип әйттеңме Сталинны?» «Әйттем!» — ди. «Пионер дип әйттеңме?» «Әйттем!» — ди. *(Көлә.)* Артык эчкә керә башлагач, судья кычкырды: «Прекратить!»

Диктор. Әле дә сокланып искә ала Лотфулла Булатов: ил өстендәге бәла никадәр генә куркыныч булмасын, ул чорда да бар иде, җитәрлек иде халык өчен үзен фида кылырдай кешеләр.

Алар соңгы минуткача горур калдылар.

Булатов. «Курыкмагыз! Без — меңнәр! Сталинның малае бүген атасын атарга әзер! Монда мин судить ителгәнмен икән, әле безнең иптәшләр җитәрлек!» — диде егет шунда.

Диктор. «Демократия», «сүз иреге» дигән сүзләрне еш кабатлыйбыз, күңелләр дә шуңа күнегеп бара. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, шикләнеп тә куябыз. «Вакытлы бәхет кенә түгелме бу?» — дибез.

Булатов. Ул вакытта кешеләр белән кара-каршы сөйләшүе дә куркыныч иде. Хәзер дә шуның шикелле килеп чыгарга мөмкин. Әллә ниләр сөйләп ташларсың да... Партшколада укыган чакта берзаман кешеләрне «чүпли» башладылар. Без җыелып сөйләшәбез: «Нүжәли Сталин белми икән шушы нәрсәне? Сталин белсә, бу тамаша булмас иде». Казанда Лепаларны[1], аның соңында Абдуллиннарны[2], Хисамовларны[3], Вәли Шәфигуллиннарны[4] кулга алдылар. Күпләрне инде. Студентлар шул хакта гәпләшә. Сталинны тикшерәләр. Утыз бишенче елны берничәбезне укудан кудылар. Бардык шкулга. Элеп куйганнар: «Булатов — исключение из школы, Фәләнов — исключение из школы...» Хәзер нишләргә кирәк? Әле дә Казанда бер таныш студент очрады: «Лотфулла абый, хәлең ничек?» — ди. Мин әйтәм: «Әнә, эленгән, кара укып. Хәл шулай минем». «Нишләмәкче буласың?» — ди. «Берәр җиргә эшкә керәсе иде», — димен.

Диктор. Студент Лотфулла Булатовны сәүдәдә эшләүче танышына җибәрә. Уч төбедәй кәгазьгә записка да язып бирә... Киров урамындагы[5] илле алтынчы магазинга урнашып, анда өч айлап эшлиме, НКВДга чакыралар...

Үз кайгысы да кайгы Лотфулланың. Әмма иптәшләренең язмышын кыл өстенә куймаска тырышу хисе көчлерәк. НКВД юлында йөртүләрен әйтә дә, үзенә янаган куркынычның шәүләсе башкаларга төшмәсен өчен, гариза язып эштән чыга. Инде ничәнче мәртәбә бер үк сорау каршыга килеп баса...

Булатов. Шуннан, хәзер кая барырга? Урамнан күңелсез генә атлаганда Габдрахманов исемле берәү очрады. Исәнләштем. Ул безнең Апас районында исполком председателе булып эшләде. Аннан алынгач, бөтен Татариядә заготзерно белән командовать итте. «Булатов, нишләп йөрисең?» — дип сорый бу. «Менә, эшсез әле мин, кая барырга да урын юк, эш кирәк иде», — дим. «Әйдә, табам сиңа эш», — ди. «Кайда?» «Вәт, Коркачыкка җибәрәм мин сине». Анда су белән эшли торган ак он тегермәне урнашкан икән. Директор урынына шунда рекомендовать итте. Тагын өч ай эшләдемме — янә НКВДга чакыралар... Биектау районы НКВДсына. Тиз генә Казанга барып, Габдрахманов янына кердем. «Иптәш Габдрахманов, нишлибез?» — дим. «Иптәш Булатов, үзебез дә калтырап утырабыз. Давай, гариза яз. Кит син. Казаннан ук кит! Хәзер шундый вакыт, алырга мөмкиннәр сине», — ди. «Соң, минем бернәрсәм дә юк, менә шушы бер сумкам бар да, үзем бар», — дип карыйм. «Алар таба», — ди. Кая барырга, нишләргә? Аллага тапшырдым

---

[1] Альфред Лепа — Татарстан өлкә комитетының беренче сәркатибе (1933-1937). 1938 елда атып үтерелә.

[2] Бари Абдуллин — Татарстан өлкә комитетының икенче сәркатибе (1931-1935). Курск өлкәсенең Ливны райкомында эшләгән вакытта кулга алына. 1937 елда атып үтерелә.

[3] Гарәф Хисамов — вакытлыча Казан шәһәр комитетының икенче сәркатибе вазифаларын башкара. 1938 елда атып үтерелә.

[4] Вәли Шәфигуллин — тумышы белән Борнаш авылыннан. Россия телеграф агентлыгының Татарстан бүлекчәсе мөдире, Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият бүлекчәсе мөдире. 1939 елда Норильск лагеренда вафат була.

[5] Бүгенге көндә Казанның Мәскәү урамы.

— Мәс-кәү-гә!

Диктор. Геолог та итә аны язмыш, балта остасы да... Илнең төрле почмакларына барып сыена. Ниһаять, Урта Азиягә юл тота. Ике ел чамасы тынычлап эшли. Әмма туган як сагындыра. Айлык ялга дип кайтса, райкомга чакыралар. «Җибәрмибез, синең кебек кадрлар кирәк», — диләр. Кем булып эшләргә, тагын нинди хәлләргә юлыгырга тиеш булгандыр Лотфулла, анысы караңгы. Шул сорауларга чумып, шөбһәләнеп йөргән көннәрдә ил өстенә яңа афәт иңә — Бөек Ватан сугышы башлана. 1941 елның җәендә үк Лотфулла Булатов мәхшәр уртасына килеп керә.

Булатов. Без беренче сугышны Белоруссиядә каршыладык. Аннан чигенә-чигенә килдек Мәскәү оборонасына. Мин ул чакта «Максим»да пулеметчы идем. Бик каты сугыш булды инде, аны сөйләп тормасаң да ярый. «Бер шаг та артка китмәскә!» Шулай эшләдек тә.

Диктор. Каты яраланып госпитальгә керә Лотфулла Булатов, кабат сафка баса. Артиллериягә күчә. «Кызыл Йолдыз» ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Польшаны азат итү өчен барган сугышларда кабат яралана. Бер үкенече кала: хыялланып-хыялланып та Берлинга җитә алмый. Әмма бирелеп уйланганы бөтенләй башка. Ни өчен сугыш озакка сузылды? Ни өчен егерме миллион кешенең җанын кыйды[6]? Көч җитмәүдән, сугышка әзерлек булмаудан гынамы бу? Шул сораулар тынгы бирми аңа.

Булатов. Приказ килә: «Атмаска!» Шундый бәрелешләрдә дошман безнең тулы полкларны кырып сала иде. Нәрсәдән бу менә? Немецлар авылга керә. Авылны күреп торабыз инде, ике километрда ул. Озакламый бөтен йортлардан төтен чыга башлый. Бер пуля атарга рөхсәт ителми шунда! Беләсезме? Бер пуля атарга! Ә немец кыра! Ул бернәрсәгә дә карамый. Өч кешене күрсә, снаряд бәрә. Хәзер самолётлар килә. «Воздух!» Яктыра! «Не шевелись!» Шунда да винтовка белән залп бирергә рөхсәт ителми. Кырык бердә, кырык икедә гел шулай булды. Кырык өченең ахырында приказ үзгәрде: немецлар авылга керәме, кайда бар, кайда күренә — атарга! Аннары инде гел икенче булдык — безнең як бик җиңә барды, тегеләр чигенә барды.

Диктор. Лотфулла кебек ил картлары фикеренчә: «Кеше никадәр күп кырылса, дөнья никадәр ныграк җимерелсә, сугыш шулкадәр тарихи булачак, онытылмаячак. Димәк, мин дә онытылмаячакмын», — дип уйлый Сталин бу чорда. Ул чактагы беркатлылыгыңа кызарып та куясың, авызыңнан меңнәрчә тапкыр чыккан сүзләрне кире җыеп алырдай буласың.

Булатов. Барыбыз да «За Сталина!» дип кычкыра идек инде. «За Родину!» «За Сталина!» «Сталиннан зур кеше, аңардан оста командовать итүче юк, анардан галим кеше юк», — дигән фикер иде безнең башта.

Диктор. Безнең халык шулай гасырлар буе баш иеп, ил мәнфәгате белән патшалар, диктаторлар мәнфәгатен аера алмый яшәгән. Әнә бит, Сталинның тиранлыгы турында да сүз хәзер генә башланды[7]. Иртәрәк тә мөмкин иде ләбаса... Халыкның да күзе иртәрәк ачылыр иде...

Сугыштан соң Лотфулла Булатовны колхоз председателе итеп куялар. Тагын мәрхәмәтсез авыр еллар була бу. Ватан язмышын да кайгыртырга, авылдашларының гомерен дә саклый белергә кирәк. Әнә бит, күп авылларда үзе үстергән икмәкне кулга тотарга да өлгермичә ачтан кырылды халык...

Булатов. Казаннан килде бер уполномоченный. «Кәпәч» дип кушамат

[6] Россиядәге соңгы рәсми чыганаклар (2001) раслаганча, СССР бу сугышта 26,6 миллион кешесен, Алмания — 4,047 миллион гаскәриен югалткан. Шуңа өстәп, тагын 2,91 миллион немец сугышчысы совет әсирлегеннән кире кайтмый.

[7] Хәзер, илдәге гомум вазгыять үзгәргән кебек, Сталинга мөнәсәбәт тә яңадан үзгәрә бара.

РКП(б)ның X съезды. В.И. Ленин Татарстан партия оешмасы вәкилләре арасында. Уртада – «Эш» газетасының редакторы В.Шәфигуллин, аның артында – күренекле журналист һәм язучы В.Бахметьев. Х.Якупов картинасыннан репродукция

тактылар аңа. Хәзер кырга чыгабыз. Ат белән барабыз. «Әнә, тегендә хатыннар кайтып килә, — ди бу. — Кесәләрендә ярма-мазар юк микән?» «Мин аларга ышанам, берни юктыр», — димен. Белеп торам, юкса: кесәләренә тутырып кайталар бит инде борчак шикелле әйберне, ну бит инде күтәреп түгел! Халык бит әле туймаган!

Диктор. Инде хәзер илдә бөтенләй башка тормыш бара. Шул үзгәрешләр хакында уйланган саен, аларны күреп сөенгән саен Лотфулла агай тирән уйга чума. Күпме михнәтләрне кичерүчеләрнең балалары дөрес аңлыймы моны? Рәхәт дигән нәрсә дә михнәт кебек үк бутап куймыймы кешеләрнең акылын? Бакчаны корт баскан кебек, тагын бер яман гадәт боза кешеләрне. Анысы — чын хезмәттән читләшү, башкалар эшләп тудырган байлыкны чумырып алырга тырышу. Үзгәртеп кору чорында болганчыклыктан арына кешелек, шул ук вакытта әлеге кыңгыр сыйфатлар да ачыграк күренә. «Үзгәртеп коруны аңлар вакыт җитте бит инде», — дип куя Лотфулла агай һәм дәвам итә.

Булатов. Ул бит бик тирән нәрсә, бер уйласаң. Әлбәттә, тормыш яхшыра бара. Ошатам мин Горбачёвны. Бөтен эшләгәне дөрес аның. Ул әрәмтамакларны яратмый бит. Менә хәзер кайбер урыннарда эшчеләр кирәгеннән артык. Штат бар. Үзебездә генә хәзер алты агроном, диләр. Нәрсәгә кирәк ул, ә? Алты агроном?! Монда бит бер Ваһапов бар иде бөтен районга. Эшләтеп тора иде шул. Хәзер бер колхозда... Нишли алар? Баралар да, кузнец янында утыралар да кайтып китәләр. Йә! Ул администрация идарәсендә эшләүчеләрне кара. Анда бит бөтен өстәл тулган. Сыер саварга кеше юк. Ә монда буш урындык таба алмыйсың!

Диктор. Өлкәннәр һәрвакыт алдагы буыннарга зур өмет баглый, хәзерге яшьләрнең үзләреннән акыллырак, сәләтлерәк булуын тели. Бездән соң бу җирдә нәрсәләр булыр? Яшьләр чын бәхетнең мәгънәсен аңлап яшәрме? Бихисап сораулар... Ачык тәрәзәдән урамга, үзе утырткан биек агачларга — халыкта күптән инде «Булат бакчасы» дип йөртелгән мәһабәт урманчыкка караган хәлдә Лотфулла агай да шул ук сорауларны кабатлый. Монда үзеннән соң да агачларның артачагына шикләнми ул. Яшьләр утыртачак, яшьләр киңәйтәчәк бу урманны. Тормышның үзен дә яшьләр сафландырачак. Бөтен өмете яшьләрдә ил картының... *(Музыка.)*

Сез «Бөтен өмет яшьләрдә» дигән радиоочерк тыңладыгыз. Авторы — Фәнзаман Сәетбатталов, редакторы — Борис Зиннәтуллин. Тапшыруны Фәнзаман Сәетбатталов алып барды. *(Музыка.)* ■

ТӘЛГАТ МИҢЛЕБАЕВ ЯДКЯРЛӘРЕ

Илдар Низамов

2015 елның җәй башында Әлмәт районының Кичүчат авылындагы Ризаэддин Фәхреддин мемориаль музеенда шушы авыл егете, журналист-публицист, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, фән кандидаты Тәлгат Хаҗиәхмәт улы Миңлебаевны (1953-1991) искә алу чаралары булып узды. Музейда аңа багышлап бер бүлек оештырылган. Экспонатлары яңартылып тора. Яңа китапны («Тәлгат Миңлебаев кояшы») туплап чыгаруда Тәлгатнең апасы Зәмзәмия, аның ире Әхтәм Нәфыйгов, музей хезмәткәрләре, журналистлар Диләрә Гыймранова, Эльвира Харрасова һәм Сүрия Мингатина зур тырышлык куйган. Бик зур рәхмәт аларга!

Кеше дигәнең, ничә ел яшәвенә карамастан, үзеннән соңгыларга нинди дә булса игелек калдыра: кемдер йорт салган, агач утырткан, юллар түшәгән, буалар буган, кемнеңдер балалары, шәкертләре халыкка хезмәт итә, кемнеңдер җырлары, китаплары рухи азык булып яши. Шундыйларны, дөньядан кайчан китүенә карамастан, ихтирам итеп сөйлиләр. Бүген Тәлгат Миңлебаев исеме онытылмаган икән, аны әледән-әле искә төшереп торалар икән, димәк ки, милләтнең бу баласы да кардәшләренә нинди дә булса игелек кылып киткән.

Тәлгат Миңлебаев... Әйе, күпләргә таныш исем бу: вафатына байтак ел үтеп китсә дә, ул һаман да хәтердә. Аның турында беркемнән дә, беркайчан да начар, тискәре фикер ишеткәнем булмады. Ә бит якты дөньядан кырык яше дә тулмаган килеш китеп барган затның игелекле гамәлләре шактый мулдан. Р.Фәхреддин исемендәге музей хезмәткәрләренең менә шуны истә тотуы, авылдашлары Тәлгат Миңлебаевның мирасын һәрдаим барлап, туплап, бер-бер артлы дигәндәй, аерым китаплар итеп чыгаруы хуплауга, мактауга лаек. Ул басмаларда Тәлгатнең яшь чагында язган шигырьләре белән бергә публицистик әсәрләре дә, көндәлек язмалары белән хатлары да, аның иҗатына фәнни анализ ясаган мәкаләләр дә, сагынып искә алган якты хатирәләр дә, иҗтимагый эшчәнлеге, фәнни казанышлары турында мәкаләләр белән рәсми документлар да урын алган иде.

Публицистиканың төп үзенчәлеге — аның алга, киләчәккә карау сәләте. Гади генә әйткәндә, бүгенге проблемаларның иртәгә ничек чишелеше турында борчылу, шул хакта уйлану, җитди мәсьәләләрне барлыкка китергән шул чор вазгыятен әдәби-сәнгати чаралар белән тәэсирле итеп анализлау,



тасвирлап, сурәтләп бирү. Публицист Тәлгат Миңлебаев нәкъ менә шундый сыйфатларга ия иде.

Аның журналистика өһелләренә үз вакытында әйтеп өлгергән теләкләре бүген дә актуаль, тирән мәгънәле: *«Бүгенге төшенке, үзара ызгышып торган, эчкерлелек нормага әйләнгән һәм өметсезлек җәелә барган чорда бездә сафлыкка, чисталыкка әйдәүче фикерләр кирәк... Халык фикерен сизгер өйрәнеп, аңа колак сала белик. Мәкаләләрнең низагка илтми, җәнҗалга бутамый торганын, ә гаделлеккә, вөҗдан һәм җан тынычлыгына, ил иминлегенә алып чыга торганын сайлый белү дә үтә мөһим...»* (Социалистик Татарстан, 1990 ел, 20 апрель).

Киләчәкне ачык күз алдына китерергә, теләсә нинди вакыйга, күренешнең үсеш тенденциясен алдан күрә белергә, җәмгыятьтә барган процессларның иҗтимагый тамырларын ачыклый барырга — менә болар хакында аның кызыклы күзәтү, анализ, эксперимент нәтиҗәләре «Преобразующая журналистика» китабында (Казан, 1990) һәм башка җитди мәкаләләрендә җентекле тасвирланган иде.

Яшь галим Тәлгат Миңлебаев тәүге адымнарын ясаган татар социолингвистика фәненә үзеннән зур өлеш кертеп калдырды. Милли хис, милли горурлык тәрбияләүдә, аерым алганда милли лидерлык сыйфатлары тәрбияләүдә ана теленең, милли мохитнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын ассызыклап, күпләп татарча китап бастырып чыгару зарурлыгын, ана телебездәге матбугатның эчтәлеген, сыйфатын яхшырту, радио-телевидение тапшыруларының вакытын арттыру кирәклеген искәртте. Татар теленең дәүләт теле буларак рәсмиләштерелүенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген күп санлы мисаллар, дәлилләр белән исбат итте.

Татар журналистының эшчәнлеге гомер-гомергә өч юнәлешле булды: үзе язды, бүтәннәр язганны төзәтте — редакцияләде һәм тәрҗемә белән шөгыльләнде. Менә бу өченче эшчәнлек татар журналистикасында зур әһәмияткә ия булып, үзенә янә өч юнәлеш хасил итә: тәрҗемә эшен оештыру, бу эшкә белгечләр әзерләү һәм тәрҗемә эшчәнлегенең фәнни-нәзари нигезенә таянып, көндәлек тәрҗемә

белән шөгыльләнү. Шунысы кызыклы һәм әһәмиятле: бу өч юнәлеш тә, бер-берсеннән аерылгысыз рәвештә, Тәлгат Миңлебаев эшчәнлегендә чагылыш тапкан.

Кулымда тарихи бер документ — КПССның Татарстан өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә тикшерергә әзерләнгән бер чараның эш планы. «Татарстанда тәрҗемә эшенең хәле һәм аны үстерү юллары турында» дип исемләнгән ул планны алда телгә алынган бүлекнең ул чактагы инструкторы Тәлгат Миңлебаев төзегән һәм имзалаган булган. Гамәлгә ашырырга, дип Өлкә комитет сәркатибе аны Казан дәүләт университеты ректоры Александр Коноваловка җибәргән. Ректор, үз чиратында, ул планны проректор Миркасыйм Усмановка һәм факультет деканы Флорид Әгъзәмовка юллаган. Миңа ул Ф.Әгъзәмовның «Старшему преподавателю Низамову И.М. Прошу составить план мероприятий и внести предложения» дигән култамгасы белән 1988 елның 10 маенда тапшырылды.

Бу очраклы документ түгел иде. Аның нигезе — партия эшенең планлы чарасы, дип аңлатылырга тырышылса да (КПСС Программасында хезмәт ияләрен тәрбияләүдә һәм укытуда тәэсирле чара буларак, ана телләрен алга таба үстерү каралган), чынлыкта ул милләт тормышында килеп туган бер кичектергесез, җитди мәсьәләне тану факты иде. Әлбәттә, хәлнең кискенлеге, мөшкел булуы турыдан-туры танылмый, әмма «*... бүген икътисади, рухи-идеология эшендә, социаль өлкәләрдә милләтара бәйләнешләрне тагын да җанландыру контекстында сыйфатлы тәрҗемәнең әһәмияте үскәннәнүсә. Тәрҗемә бүген икетеллелекнең нигезен тәшкил итә, шул ук вакытта мәдәниятнең нигезе булуын да саклый. Безнең шартларда журналист, педагог, ана теле укытучылары, депутатлар, идарә хезмәткәрләре, төрле идарә, эшханәләрнең, учреждениеләрнең хезмәткәрләре тәрҗемәнең теория һәм гамәли нигезләрен белергә тиеш...*», дип бик дөрес сүзләр дә әйтелә.

Әнисе Миңлекамәр

Менә шушындый гомуми тезисларга уңай мисал иттереп, Татарстан китап нәшриятында елына 100 исемдә китап һәм брошюраның татарча чыгарылуы, шуның яртысы урысчадан һәм башка телләрдән тәрҗемә әсәрләре булуы күрсәтелә. Янә дә, уңай фактор итеп, район һәм шәһәр газеталарының, өчесеннән кала, барысы да урысчадан тәрҗемә ителеп (дубляж) чыгарылуы китерелә.

Шуннан соң гына документның барлыкка килүенең чын сәбәпләре ачыклана башлый — ягъни иҗтимагый ихтыяҗ менә шушылай югары булып та республикада тәрҗемә эшенә әле тиешле игътибар җитми икән. Менә фактлар: иҗтимагый-сәяси тәрҗемә белән политологиядән, философия, журналистикадан гына түгел, филологиядән дә ерак торган кешеләр шөгыльләнә. Татарстанда тәрҗемә эше белән һөнәри-вазифаи шөгыльләнүче

Рәсемдә (уңнан сулга, чүгәләгәннәр) **– Ф.Фәтхи, А.Садыйков; басканнар – Л.Лерон, Р.Мөбарәкшина, Р.Фәизова, И.Шаһиев, Т. Миңлебаев, Р.Саттарова, Л.Хәйруллина. 1982 ел**



200 кешедән берсенең дә махсус белеме юк.

Документта шулай ук көндәлек басмаларда рәсми, директива текстларының тиешле дәрәҗәдә булмавы, район, шәһәр матбугатының текстлары тәрҗемәсенең түбән сыйфатлы булуы, шуның аркасында дубляж басмаларның тиражы кими баруы икърар ителә. Тәрҗемә басмаларның, рәсми чыгышларның, күргәзмә агитациянең (төрле өндәмәләр, тантаналы җыелышларга чакыру билетларының да), элмә язу, рекламнарның урысчадан татарчага тәрҗемәсе кебек үк татарчадан урысчага тәрҗемәләрнең дә (чувашча, удмуртчаларныкы да) оригиналныкы белән чагыштырганда түбән дәрәҗәдә булуы әйтелә.

Бу документны әзерләү барышында Тәлгат Миңлебаев тәрҗемә эшенең чын хәленә бик җаваплы карап, мәсьәләнең төбенә төшеп өйрәнгән иде: ул редакцияләрдә бу һөнәргә бәйле журналистлар белән аралашты, сорашу үткәрде; бу максатта төпле мәгълүмат алу өчен «Тәрҗемәче анкетасы» төзеп, аны белгечләрдән тутыртып, без дә мәгълүмат бирдек. Тәрҗемәчеләрне укыту планын да Тәлгат Хаҗиәхмәт улы фикердәше Флорид Әгъзәмов белән турыдан-туры аралашып эшләде...

Тормыш безгә бүген дә бөтенләй үк өметсезләнмәскә куша. Милләт яшәсен өчен татар теле яшәргә тиеш, телне яшәтүнең иң көчле чара-чыгаракларының берсе булган тәрҗемә дә яшәргә, камилләштерелергә тиеш. Шөкер, бүген дә бездә уңай үзгәрешләр кертердәй тәҗрибә бар. Һәрхәлдә, Тәлгат Миңлебаевның тәрҗемә эшчәнлегенә керткән тырышлыгы нәтиҗәләрен, аның файдасын бүген дә тоеп яшибез. Аларны яңа шартларда кабызып-яңартып кына җибәрергә кирәк.

Тәлгат Миңлебаев шигырьләре

БЕРЕНЧЕ КАР

Төшим микән, әллә төшмимме, дип
Беренче кар төшә җай гына.
Беренче кар... Төшә беренче кар
Алтын көзнең соңгы аенда.

Менә тагын төшә: берәү, икәү...
Бар табигать акка төренә.
Кара җирне ак ашъяулык белән
Ябып куйган кебек күренә.

Беренче кар ап-ак мамык кебек,
Атлап бару шундый күңелле.
Беренче кар белән төрле якка
Эзләр салу бәхет түгелме?

КӨНБАГЫШЛАР

Бакчаларга якты тараталар, —
Көнбагышлар үсә һәр җирдә,
Сары күлмәк киеп биегәндәй,
Тирбәләләр җылы, саф җилдә.

Ә чуклары сары ялкын кебек,
Әйтерсең лә кояш ярчыгы.
Яңа куйган йөзек кашы кебек
Шул чукларда яна таң чыгы.

ЭЗЛӘР

Эзләр, эзләр —
комда кала
сукмак булып.
Җил исүгә
җуелалар
күпме йөреп.

Комдагылар —
күмеләләр
җил исүгә.
Кардагылар —
су булалар
яз җитүгә.

Комнарга да,
карларга да
Мәңгелеккә
уелмыйлар.
Ә калсалар,
күңелләрдә
һичвакытта
җуелмыйлар...
Җуелмыйлар.

ТӘРӘЗӘЛӘР

Тәрәзәләр
Якты сибеп,
Тора көлеп.
Урамнарга
Кояш үзе
Төшкән кебек.
Тезеп куйган
Йолдызлардай,
Караңгыда,
Миңа таба
Килә йөзеп.
Тәрәзәләр...

Тәрәзәләр —
Йолдызстан
Төшкән кебек.
Якты өйдә
Яхшы хуҗа
Өйгә якты
Өстәр кебек.
Тәрәзәләр
Миңа таба
Килә йөзеп...

***

Туган йорт,
Туган нигез.
Йорт һаман шул,
Нигез генә иңә...
Тыкрык шул ук,
Һаман шулай тыныч,
Һаман шулай җанлы,
Тик кешеләр генә...

Остазлар һәм шәкертләр

СҮЗЛӘР

Сүзләр —
берәүләргә дөреслектән качу өчен,
берәүләргә дөреслекне ачу өчен.

Сүзләр — аталардан балаларга,
буыннардан буыннарга,
күчеп бара мирас булып.

Сүзләр иҗегендә кояш торсын —
бирсен җылысын!
Ике кисәк бозны
эретеп ябыштыра
йөрәк җылысы.

Ике гомерне бергә бәйли
йөрәк җылысы.

Сүзләр җылысы —
барыннан көчле,
алар бәйли
буыннарны,
гасырларны,
кешеләрне һәм эшләрне.

ТӘЛГАТ МИҢЛЕБАЕВ КӨНДӘЛЕГЕННӘН:

***

«Бу да йолдыз дисеннәр өчен якты яну гына җитми, якты итеп сүнәргә кирәк...»

***

«Кыска гына тәнәфесләрдә студентлар белән саубуллашу. Бугазда төер. Минем тормышымда һәрвакыт шулай булды: теләмичә кабул иттеләр, соңыннан — җибәрәселәре килмәде».

***

«...Шигырьләремә килгәндә, әйтергә теләгәнемне әйтеп бетерә алганым юк әле. Күңелемдәге шигъри моңнарымны мин студентларга лекцияләремә салып бирәм».

***

«Кешеләр өчен кечкенә генә булса да кояш булсам, мин бик бәхетле булыр идем». ■

ТЕЛ БЕЛГӘН – ИЛ ГИЗГӘН

КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов белән «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, язучы Рәдиф Сәгъди әңгәмәсе

– Минем мәдрәсә тәмамлаган бабам 3 тел белә иде: гарәпчә, татарча, урысча. Аның улы ике генә тел белде: татарча һәм урысча. Минем дә шул чама. Оныкларымның бер генә тел белүе ихтимал – урыс теле. Бу мәсьәләгә сез ничек карыйсыз? Сез бит җитәкчеләргә якын кеше. Аларга бу хакта әйткәнегез бармы?

– Мәсьәлә, әлбәттә, катлаулы. Бу темага еш сөйләшәбез, бәхәсләшәбез. Миңа калса, республикабыз җитәкчелеге дә, министрлар да әлеге мәсьәләне бик яхшы белә, аңлый. Шулай да шактый гына проблемалар кала бирә. Чынлап та, безнең буын балаларының телләрне начар белүе безне бизи торган әйбер түгел. Боларның барысын да исәпкә алып, без үзебезнең уку йортыбызда 1995 елдан бирле әлеге юнәлештә системалы эшчәнлек алып барабыз. Әйтик, татар теле һәм әдәбиятын үзләштерүчеләр инглиз теле белгечлеген дә ала. Соңгы елларда татар бүлегендә укучы студентларыбыз инглиз теленнән тыш гарәп, төрек яки кытай телләрен дә өйрәнә ала. Бу безнең яшьләребезгә киләчәктә эшкә урнашу, яңа үрләр яулар өчен дә зур ярдәм булыр, дибез.

Әлбәттә, Россия күләмендә бердәм дәүләт имтиханнары кертелү милли телләрне өйрәнүгә, гомумән, милли мәгариф системасына шактый зыян салды. БДИ кертелгәнче, безнең мәктәпләрдә ана телендә укыту шактый югары куелган иде. Хәзер исә әтиәниләр дә, балалары БДИын урыс телендә тапшырасы булгач, уку-укыту процессы да урыс телендә булырга тиеш, шулай булганда гына әйбәт нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин, дип уйлый. Бу күпмедер дәрәҗәдә дөрестер дә, ләкин икенче яктан безнең башка матур мисалларыбыз да бар. Мәсәлән, Казан шәһәрендәге Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе укучыларының БДИ буенча күрсәткечләре урыс тел-

ле мәктәпләрнекеннән һич кенә дә ким түгел, хәтта артыграк та. Бер яктан, без балаларны татар телендә укытмас өчен ниндидер сәбәпләр эзлибез, БДИ булгач, укыту урыс телендә булырга тиеш, дибез. Икенче яктан, мәктәп, әти-әниләр, җәмәгатьчелек һәм без, уйланып, алга таба стратегияне булдырырга тиешбез. Монда инде балалар бакчаларындагы тәрбиячеләрнең, мәктәптәге укытучыларның әзерлек дәрәҗәсе, аларның һөнәри сыйфатлары бик зур роль уйный. Үзебезнең институтта да, Мәгариф министрлыгы һәм республикабызның башка уку йортлары белгечләре белән дә әлеге темага бик еш әңгәмә корабыз.

Берничә телне укыту проблемасына килгәндә, кызганычка каршы, бүген инглиз һәм урыс телләрен укыту аерым система һәм методика буенча алып барыла. Ә баланың ана теле үзенчәлекләре исәпкә алынмый. Укучы туган теленең фонетик, лексик үзенчәлекләрен өйрәнми торып, урыс яки чит телләрдәге үзенчәлекләрне өйрәнә башлый. Бу юнәлештә бик күп фәнни-тикшеренүләр бар. Галимнәр фикеренчә, бала үз туган телен тиешле дәрәҗәдә белгәндә генә чит телне өйрәнүдә зур уңышларга ирешә. Шуңа күрә без республикабыз җитәкчелегенә шундый тәкъдим керттек: яшьләргә 3 телне өйрәнү бурычы куярга — татар, урыс һәм, ким дигәндә, бер чит тел. Телләрне укыту аерым концепция буенча, туган тел нигезендә алып барылырга тиеш. Дәреслекләр дә безнең респбулика һәм монда яшәүче балаларның үзенчәлекләрен истә тотып эшләнергә тиеш. Дөрес, бүгенге көндә кайбер эшкәртмәләр бар. Ләкин алар, кызганычка каршы, тулысы белән безнең проектка җавап бирми.

— Рәхмәт, бу турыда өстәгеләрнең уйлавы күңелгә тынычлык бирә. Тик борчу бетми, чөнки тагын 20-30 елдан затлы телебез бөтенләй юкка чыгарга, сабан туе бөтенләй башка халык мирасы булып калырга мөмкин: читекләре, киемнәре, бөтен байлыклары... Бу, мине генә түгел, күп язучыны борчый. Әгәр тагын берничә елдан үзгәрешләр ясый алмыйбыз икән, зур фаҗига булачак. Колхозлар ташландык хәлдә, кайбер авылларда эчкечелек хөкем сөрә. Бу — татар тәрбиясеннән, гореф-гадәтеннән чит-

кә китү. Мин үзем Казандагы 113 нче татар мәктәбен бетердем. Күршедә генә рус телендә белем бирә торган мәктәп бар иде. Ләкин бездә тәрбия бер башка югарырак булды. Спорт буенча да, физика-математика буенча да җиңә идек. Боларны югалтсак... Начар уйлар башка керә дә...

— Дөрес әйтәсез, дистә ел, гасырлар дәвамында килгән гореф-гадәтләребез, үзебезнең тәрбия алымнарыбыз бар. Алар, һичшиксез, безгә телебезне, мәдәниятебезне сакларга ярдәм итә. Тагын бер кат ассызыклап үтәсем килә, милли тәрбиядә мәктәпнең, гаиләнең, җәмәгатьчелекнең роле бик зур. Без югары уку йортында әлеге максатка ирешү өчен шактый гына чаралар уздырабыз, эшчәнлек алып барабыз.

Форсаттан файдаланып, үзебезнең татар вакытлы матбугаты вәкилләренә рәхмәтемне әйтәсем килә, сезнең «Безнең мирас» журналы белән хезмәттәшлек итәбез, алга таба да бу гамәл уңышлы дәвам итәр, иншалла. Башка журнал редакцияләре, шулай ук, Бөтендөнья татар конгрессы, Язучылар берлеге белән дә актив эшлибез. Максатлар куеп, киләчәктә шулай системалы эш алып барсак, милләтебезне саклап кала алырбыз, дип уйлыйм.

— *Әйе, Аллага шөкер, журналда халкыбызның гореф-гадәтләрен, күренекле шәхесләребезнең мирасын туплап чыгарабыз...*

— Чынлап та, «Безнең мирас» журналы милләтебезне, халкыбызны, гореф-гадәтләребезне саклауда зур эш башкарып килә. Мин беләм, сезнең планнарыгыз бик зурдан. Без Сингапур кебек илләргә барып өйрәнә алабыз, башка илләрдә тәҗрибә туплыйбыз. Ләкин үзебезнең мирасыбызны белү, барлау һәм андагы уңай тәҗрибәне файдалану — безнең бурыч-максатларыбызның әүвәлгеседер. Сезнең журнал — бу юнәлештә мәктәпләр өчен дә, югары уку йортлары өчен дә иң беренче ярдәмче. Журнал озын гомерле булсын иде. Һәм инде үзегез куйган бурыч-максатларга ирешергә Ходай насыйп әйләсен! ■

Мин утырткан агачлар шаулап үсә...

Фәйзелхак Ислаев

Тарих, киләчәккә аман-имин илтеп тапшырыр өчен, Вакытны җыеп, төйнәп куя. Көннәр уза, еллар уза, чорлар уза, системалар тузып юкка чыга һәм гасырлар кисешкән бер чатта Кеше (әллә халык кадәр Халыкмы?) исәнгерәп калырга мөмкин: кем мин? нишләп торам монда? кая барышым иде? арткамы? алгамы? Шундый мөһим, хәлиткеч минутта, чикләвек кабыгын таш бәреп ваткандай, Тарихи Хакыйкатьне ялганнан арчып бирер, башта кайнаган бихисап сорауларга дөрес җавап табарга ярдәм итәр өчен һәр милләтнең киләчәкне күзаллап, үткәннәрне барлаган фидаи затлары булырга тиеш. Татар кебек шанлы, данлы, югалтуларга, табуларга, гыйбрәтле вакыйгаларга һәм, ни аяныч, кара ялганга, ялага, фальсификациягә бай тарихлы кавем өчен — бигрәк тә. Шөкер, асыл ир-егетләр дигәндә (сугышта, тарихта, әдәбиятта, сәнгатьтә, мәдәнияттә һ.б.) милләтебез беркайчан да фәкыйрь булмады.

Тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаевның төп фәнни хезмәтләре исемлегенә игътибар юнәтү җитә, җанга суелып кергән хатирәләр яңадан терелеп күз алдына баса гүя: «Татар халкының җиһады», «Идел буенда православие миссионерлары», «Идел буенда ислам һәм православие (XVIII гасыр): бәрелештән үзара түземлеккә таба», «Батырша восстаниесе. 1755 ел»...

Кичәге көненә багып дөрес нәтиҗәләр чыгарган халык кына киләчәккә өметле караш ташлый, андый халыкның гына киләчәктә мондый хаталар, ялгышлар кылмаска, тегe яисә бу куркыныч янаганда сакланып калырга, исән калырга ышанычы бар.

Күркәм юбилее уңаеннан, әйдәгез, бергәләп даими авторыбызның тормыш һәм фәнни иҗат юлын искә төшереп узыйк әле...

Редакция

ГАИЛӘ

Мин 1946 елның 2 гыйнварында хәзерге Пермь краеның Октябрь районы Уразмәт авылында туганмын. Әтием Габделхак исемле (1906-1963). Аның белмәгән эше юк иде, һәрнәрсәгә кулы ятты — кирпечтән мич тә өйде, нарат тамырын кайнатып сумала да чыгарды. Сабый килеш Гражданнар сугышын күреп калган ул — кызыллар белән аклар күз алдында сугышкан, диярлек: бакчабызда пулемёт торган, ә бабабызның базында бер кызылармияче ээзәрлекләүдән качып көн уздырган. Сталин чорында, күмәк хуҗалыкка керергә теләмәгән өчен, әтине лагерьга сөргәннәр. Беломорканалны төзүдә катнашкан. Соңрак Бөек Ватан сугышына киткән, Кырымны яклаганда алманнарга әсир төшкән, аннан качкан, Польшага кадәр барып җиткән, каты яраланган. Сугыштан соң «хыянәтче» мөһере сугылган. Ул вафат булганнан соң да, төрле анкеталар тутырганда, миңа шактый шөбһәләнергә, борчылырга туры килә иде — әсирлеге хакында, гомумән, тел яшердем.

Әнием Нәгыймә турында бик аз беләм. Богородское хастаханәсендә, үлем белән тартышкан көннәрендә, мине тәмле-тәмле конфетлар белән сыйлавы хәтеремдә. Озакламый без әнисез калдык. 1953 ел иде бу. Шул ук елда мин беренче сыйныфка укырга кердем.

Фәйзелхак (уңда) **апасы Һаҗәр һәм энесе Фәйзулла белән**

МӘКТӘП

Егерме яшемә кадәр туган авылымнан чыкмадым. Ул чорның һәр бала-чагасы кебек, минем дә иң садә вакытым табигать кочагында, күмәк хуҗалык эшендә, укуда үтте. Ниндидер истәлекле вакыйгалар булуын хәтерләмим — караңгы татар саласында гади-гадәти тормыш белән яшәдек: авылга ут та кермәгән иде, радио да юк, кинофильмнар да күрсәтмәделәр.

Мин «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләренә укыдым. Ул вакытта бездә башлангыч мәктәп кенә. Ләкин, һич көтелмәгәндә, җиде чакрым ераклыктагы Бикбай авылы мәктәбе янып көл булды. Анда якын аралардан бик күп укучы килеп белем эсти иде. Күршетирәдә укытырга яраклы зур бина табылмаганлыктан, безнең мәктәпне җидееллыкка әвереләдерделәр. Чыбык очы туганыбыз Габдерәхим абый берничә ел буе директор вазыйфасын башкарды, тарих фәнен укытты — ихтимал, минем һөнәри тарихчыга әверелүемдә аның да өлеше булгандыр.

Урта белемне бездән егерме чакрымда урнашкан Сазавылда алып бетердем. Әмма моңа озак куанырга туры килмәде — шул ук 1963 елның 17 июлендә әти дөньядан кичте.

1964 елда Пермь университетының тарих бүлегенә читтән торып укырга кердем. Имтиханнар шактый катлаулы. Урыс телем чамалы. Бу кимчелектән татар авылында яшәп беркайчан да арына алмавым көн кебек ачык. Шуңа күрә ике елдан Пермьгә күченергә карар кылдым.

ТОРМЫШ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ

Читтә хезмәт юлымны слесарь-сантехниклыктан башладым. Закамск

Галим Марсель Әхмәтҗанов белән

микрорайонының тулай торагында бүлмә бирделәр. Бер үк вакытта кичке дәресләргә йөрдем, ялларымны район китапханәсендә үткәрдем. 1970 елда университетны тәмамлап, шул ук елның сентябрендә Сания исемле чибәр, акыллы, төпле кызга өйләндем. Әмма безгә озак вакыт гөрләшеп яшәргә туры килмәде, гаилә тормышының барлык ләззәтен тоеп гомер итә башладым, дигәндә генә мине СССРның Кораллы көчләре искә төшерде. Яшьлегемнең бер елын Смоленск өлкәсендәге Сафоново шәһәрендә калдырып кайттым. Сөйгәнем белән көн саен хат алышу гына саргаюдан саклап калгандыр.

Армия сафларыннан азат ителгәннән соң төрле елларда смена башлыгы, ПТУда, кичке мәктәптә укытучы, Фәнни-тикшеренү институтында сәяси агарту кабинеты җитәкчесе булып эшләдем; галимнәр белән аралашу, фәнни тикшеренүләргә һәвәслегем Пермь университетының аспирантурасы ишеген кактырды. 1983 елның апрелендә диссертациямне яклау бәхетенә ирештем. Шатлыгымны уртаклашырга Диссертация советы әгъзалары, кафедра укытучылары, аспирантлар безгә, Закамскига җыелды. Банкет-мазар уздыруларның тыелган чагы иде бу. Кунакларны җәмәгатем белән аның әнисе (каенанам) сыйлады (ул махсус шуның өчен Пермьгә килде). Сый, нигездә, татар халык ашларыннан гыйбарәт иде, кунаклар аларны кабып карауга «аһ» итте һәм озак гомер әле «теленңне йотарлык ризыклар» турында сөйләп, күңелле хатирәләрен яңартты.

И КАЗАН, НУРЛЫ КАЗАН!..

Казанга күченергә уйлый башлаганчы, мин Пермь дәүләт авыл хуҗалыгы институтында — укытучы-доцент (1983-1993), гуманитар факультетта декан (1990-1992) булып эшләргә өлгергән идем инде. Бардада узган Пермь татарларының тарихы һәм мәдәнияте проблемаларына багышланган конференциядә беренче тапкыр Г.Ибраһимов исемендәге институтның галимнәре, милләтпәрвәрләр Рәшит Ягъфәров, Дамир Исхаков белән таныштым һәм, башкалабызда эш табыла калган очракта, гаиләм белән Татарстанга күченергә теләгем барлыгын әйттем. Хәерле эш булды ул. Шул ук елны Тел, әдәбият һәм тарих институтына өлкән фәнни хезмәткәр итеп штатка алдылар. Акыллы затлар, галимнәр белән аралаша торгач, Идел буенда ислам, православие дине мәсьәләләре кызыксындыра башлады, җиң сызганып татарларны чукындыру сәясәтен өйрәнергә керештем. Яңа керәшен конторасы тарихын әзерләү (1997) — бу эшнең күркәм нәтиҗәсе булды. Кулъязманы мөфти Габдулла хәзрәт Галиуллинга күрсәттем, ул мине, китапны бастырып чыгару мәсьәләсе буенча сөйләшергә, Кабан арты мәчете имамы Исхак хәзрәт Лотфуллинга җибәрде. Бераздан «Татар халкының җиһады» исемле басма «табадан төште». Шунысын да әйтим: бу — иҗади биографиямдә шулкадәр тирән анализланган бердәнбер мәҗмуга; аның турында төрле сүзләр ишетелде, әмма мин язган өлешкә рецензентлар тарафыннан тел-теш тидерү күзәтелмәде.

Дөрес, Пенза өлкәсенең Городище район мәхкәмәсе аны җиңел кул белән «тыелган әдәбият» исемлегенә керттекертүен, әмма тискәре бәһа биргән белгечләр аның кереш өлешеннән башка бүлекләрен укып изаландымы икән? Белмим. Шикләнәм. 1999 елда нәшер ителгән «Идел буенда православие миссионерлары» исемле китап, мөгаен, шул яктан аерата кыйммәтледер: анда мөселманнарны чукындыру һәм керәшен конторасы, православие миссонерлары эшчәнлеге турында моңарчы беркайда да басылмаган мөһим документлар дөнья күрде.

Туксанынчы еллар уртасында үзем өчен өр-яңа тема — татар тамгалары дөньясын ачтым[1]. XVII-XVIII йөзләр чыганакларын өйрәнгәндә кулыма гаять кызыклы документлар килеп керде — алардан күренгәнчә, татарларда имза урынына тамга куя гадәте еш очраган. Фәнни мәсьәләдә бу, Миркасыйм Госманов, Дамир Исхаков һәм тагын берничә галимнең аерым сюжетыннан тыш, гомумән, өйрәнелмәгән, эшләнмәгән, эшкәртелмәгән өлкә булып чыкты. Бик күп төрле тамгалар җыеп, конференцияләрдә нотык тоту, матбугатта басылу бәхетенә һәм мәртәбәсенә ирештем.

Ихтимал, яшәлгән гомеремә күпмедер нәтиҗә ясап карасам, нигездә, канәгатьлек хисе кичерермен — юлымда һәрвакыт яхшы кешеләр очрады, кирәк чакта һәрдаим ярдәм кулы суздылар, гаиләм — җәмәгатем Сания, балаларым Чулпан, Алсу, Азат — ныклы терәк булды. Чын ир-ат агач утыртырга, йорт салырга, шигырь язарга тиеш, диләр. Мин утырткан агачлар Уразмәттә, Пермьдә, Казанда, Арчада, Каенсарда шаулап үсә, Пермьдә үз кулларым белән ике бакчачы йорты күтәрдем, инде шигырьләргә килгәндә... Тарихта калырлык ике юл шигырь иҗат итмәсәм дә, тарихның үзе турында күп уйландым, күп эзләндем, күп өйрәндем, күп яздым...

«Мин бәхетсез», дип әйтү килешмәс. ■

---

[1] Сүз уңаеннан. Укучыбыз хәтерлидер: 2015 елның гыйнварында баш мөхәррир Ләбиб Лерон Татарстанның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән очрашып әңгәмәләште. Шунда Фәйзелхак Ислаевның тамгалар турындагы «Уртак мирас» язмасы («Безнең мирас», №10, 2014) беренче Президентыбызның да кызыксынуын уяткан иде.

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Сания Ислаева

«Тормышыбызның шатлыклары да, зур кайгы килгән чаклары да булды. 45 ел бергә яшәү дәверендә Фәйзелхакның авыр сүз әйткәнен хәтерләмим».

***

«Без Фәйзелхак белән 1969 елда завод тулай торагында яшьләр өчен оештырылган бик матур кичәдә таныштык. Ул мине вальс биергә чакырды. Соңыннан өйләнешкәч тә (1970), икәү парлашып, биеп-җырлап дигәндәй яшәдек. Мәскәү янындагы бер ял йортында вальс биегән өчен махсус приз да алган идек».

***

«Пермь университетын тәмамлаганнан соң Фәйзелхакны Совет армиясе сафына алдылар. Бер ел хезмәт итү дәверендә ул миңа көнаралаш хат җибәреп торды. Хатларын шулхәтле матур итеп, йөрәк җылысы белән яза иде. Мин аларны кадерләп саклыйм».

***

«Икебез дә эшләдек тә, укыдык та. Мин Пермь политехник институтында башта кичке бүлектә, аннары көндезге бүлеккә күчеп уңышлы тәмамладым. Бер-бер артлы дүрт балабыз дөньяга килде. Пермь шәһәрендә, урыслар арасында яшәсәк тә, аларга чын татар исемнәре бирдек. Беренче кызыбыз — Чулпан. Бу исемне Муса Җәлил иҗатыннан алдык. Икенче кызыбызга Наилә исеме куштык. Бу татар хатын-кызлары исемнәре арасында минем өчен иң кадерлесе. Өченче кызыбызга Алсу исеме җырдан алынды («Алсу гөлләр чәчәк атсын барасы юлларында»). Дүртенче балабыз — ир угыл. Аңа Азат исеме куштык. Ул Бөек Җиңүнең 40 еллыгында, 9 май көне туды».

***

«Гомер буе Фәйзелхакның кулыннан китап, гәҗит-журнал төшмәде. Шулкадәр мавыгып укыгандыр ки, бала тирбәткәндә китап укып, коляскадан бала очып төшкән вакытлар да булды. Поезд каршыларга барып, кунаклар үзләре безгә килеп җиткәч, алар артыннан кайтып кергән очраклар бер генә булмады».

***

«Фәйзелхак — үз туганнары арасында, минем туганнарым арасында мөхтәрәм кеше, балаларыбыз өчен үрнәк эти. Балаларыбызны кечкенәдән походларга, чаңгы шуарга «өстерәдек». Пермьнең әкияттәгедәй матур Урал тауларында чаңгы шуа идек. Инде балаларыбызны үстердек, укыттык. Барысының да үз тормышлары. Алты оныгыбыз бар».

«Әтисе – Габделхак Исламетдин улы Бөек Ватан сугышы башлангач, беренчеләрдән булып, фронтка китә».

***

«Фәйзелхакның әтисе — Габделхак Исламетдин улы (1906-1963) урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемгә генә ия булуга карамастан, ул күп укыган, өенә газеталар яздырып алган, сәясәт белән кызыксынган. Авылда гади колхозчы, бригадир, колхоз рәисе урынбасары, ферма мөдире, ветфельдшер, умартачы булып эшләгән».

***

«Әнисе — Ислаева (Гарипова) Нәгыймә Гариф кызы (1910-1953) турында мәгълүмат бик аз, чөнки ул Фәйзелхакка җиде яшь тулгач вафат булган. Хәлле крестьян гаиләсендә үскән, Бөек Ватан сугышы чорында тыл хезмәтенең бөтен авырлыгын үз җилкәсендә кичергән бу ханым, 1931-1952 еллар аралыгында сигез бала тудыра, шуларның бишесе яшьли вафат була». ■

«Парларны Ходай күкләрдә кавыштыра, диләр. Мине, Татарстан кызын, шушы Пермь егете белән кавыштырганы өчен Ходаема, язмышыма рәхмәтлемен!»

Редакциябезнең даими авторы, тарих фәннәре докторы, профессор **Фәйзелхак Ислаевны** *гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, аңа сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар телибез. Мөхтәрәм галимнең яңа хезмәтләре белән журналыбызның 2016 елгы саннарында таныша аласыз.*

ӘХЛАК*

К.Бикколый, Г.Госмани

ДУСЛЫК

Дөньяда тору өчен ашау-эчү, кием-салым никадәр зарур исә, көн итү өчен дус вә аркадаш та шулкадәр хаҗәттер. Бабаларыбыз: *«Йөз сум малың булганчы йөз дустың булсын»*, — дигәннәр. Бик гүзәл мәкальдер. Дуслык малдан күпкә артыктыр. Мал сиңа һәр җирдә куәт вә ярдәм итсә дә, гакыл вә фикер бирә алмас. Әмма садыйк[1] дус иң мөшкел вә иң авыр хәлгә килдегеңдә киңәшләшүгә әзер булып, синең ярдәмеңә ирешер. Бөтен дөнья малын биреп тә котылу мөмкин булган бәлаләрдән азат итәр. Ләкин дус булачак кешенең сүзендә тугры, дуслыгы садыйк булуы тиештер. Моны дус булганчы дикъкать итү тиештер. Ул кеше ата-анасына ничек булмыш? Әгәр дә аларга итагатьсез булса, ул кешенең дуслыгыннан кач, анда һич файда юктыр. Дус булачак кешенең әүвәлге хәле мәгълүм булмаса, аның хәзерге хәленә бак, нәфесенә иярүче була күрмәсен. Чөнки нәфескә иярүче — шайтан дустыдыр. Дус булган кеше күркәм холык иясе булсын. Күркәм холыклы кеше илә бик дуслык хасил кылсаң, аның кадерен бел, үлгәнче аннан аерылма, даими аңа хөрмәт күрсәт. Мондый дуслар җәүһәрдән кадерле вә газиздер...

САРАНЛЫК

Кулда булган малны ахирәт гамәле кеби күреп, мөмкин булганда да фәкыйрь-мохтаҗларга ярдәм кылмый, мәчет-мәктәп кеби изге урыннарга сарыф кылмый, мәңгелеккә килгән кеби малны саклап торуга әйтерләр. Бу исә бик черек вә яман холыклардандыр. Саранлык илә адәмнең һич ризыгы артмадыгы кеби, юмарт булу илә дә малы бетмәс. **Аллаһы Тәгалә малны фәкыйрь-мохтаҗларга ярдәм итеп изгелек хасил итәр өчен, мәктәп-мәчет кеби хәерле урыннарга сарыф итеп, динне куәтләр өчен бирмештер.** Аллаһы Тәгалә кушкан җирләргә юмартлык кылсаң, Аллаһы Тәгалә малыңны арттыра барыр. Әмма саранлык кылсаң, дөньяда бәхил саран, дип яман исемең чыгып, халык каршында мөрәүвәтсез[2] кешеләрдән булып, кадерең бетәр, дустың азаер, гөнаһың күбәер. Ике дөньяда да бәхетсез булып калырсың. Пәйгамбәребез: *«Сараннар тәмугка якын, җәннәттән ерак кешеләрдер»*, — диде. Гакыллы кеше дөнья малын кызганып үзен-үзе тәмугка якын кылмас, Аллаһы Тәгалә биргән малның кадерен белеп, фәкыйрь-мескеннәргә, ятим вә мохтаҗларга ярдәм итеп, дөнья вә ахирәттә хәер күрергә тырышыр. Әгәр малың булып та, юмарт-

* 1911 елда язылган әлеге әсәрнең алдагы өлешләрен журналыбызның 2014 елгы 9, 11, 12; 2015 елгы 1, 6 саннарыннан, шулай ук www.beznenmiras.ru сайтыннан (тулысынча) да укый аласыз.

[1] Садыйк — чын, эчкерсез.

[2] Мөрәүвәт — егетлек, ирлек.

лык итеп, изге эшләргә сарыф итеп, мәчет-мәктәп кебиләрне бина кылып калдырсаң, үлгәч тә сине яхшы кеше иде, юмарт иде, милләтен сөя иде, дип кыяматкәчә изгелек илә зикер кылырлар. Әмма саран кеше, кызганып, малыннан үзе дә хәер күрми, милләтенә дә ярдәм итми. Җыяр-җыяр да беркөн дөньядан китәр. Аның һич яхшы исеме калмас. Каты кеше иде, хәерсез иде, дип үлгәч тә башын авырттырырлар.

ГАШРӘТ (ЭЧҮ, ТИПТЕРҮ)

Нәфескә булышып зәүкъ-сафа, уенкөлке илә кыйммәтле вакытны кәеф вә азгынлыкта уздырмактыр. Бу исә шәригатебездә каты хәрәм булганы кеби, гакыл кашында да иң начар вә иң кабахәт сыйфат булып, адәмнең һәлакәтенә сәбәп булган бер авырудыр. Миллион вә миллиард мал вә мөлкәте булган байларны бер тиенсез калдырган, бөтен дөньяны тотарлык гакылы булган гакыллыларны мәҗнүн иткән нәрсә — зәүкъ-сафага бирелмәктер. Чөнки бу кәеф-сафа кешене чиксез-хисапсыз начарлыклар вә азгынлыкларга төшереп, бөтен малыннан мәхрүм итәдер. Ахырында, харап итеп, дөньядан юк итәр. Кәеф-сафа, барча азгынлык вә усаллыкларның башы булып, инсанны олуг гөнаһларга төшерер, дөньялыкта фәкыйрь-мохтаҗ итеп, хурлыкта вә түбәнлектә калдырыр. Кәефкә бирелгән кеше нәфесе теләгән һәрбер яманлыкны кылыр вә һәрбер начар эшләрне эшләр. Аның күбрәк файдаланылганы да иң кабих, иң куркынычы, адәмне дөнья вә ахирәт һәлакәтенә салучы, малны бетереп, угыл-кызын ятим, фәкыйрь калдыручы, барча гөнаһларның анасы булган исерткечтер. Аның ни дәрәҗәдә кабахәт идекен белмәк өчен бер мәртәбә сәрхушларга карау җитәр. **Исерткеч эчүченең күзләре тонар, гакылы китәр, башы әйләнер, ни сөйләгәнен белмәс, алдындагыны күрмәс, әйткәнен ишетмәс, ерткыч бер хайван сурәтенә керер.** Әдәпле кешеләр аны күрсәләр, аның яман исеннән, начар кыланмышларыннан куркып явыз хайваннан качкан кеби качарлар. Гашрәт итүче нәфесенә ияреп, азгынлыкка бирелүче булып, аның гадәте дә исерткеч эчеп дөнья көлкесе булып калмактадыр. Димәк, кәеф-сафага бирелү диваналыкның башы булып, аңа гадәт иткән кешегә дәва юктыр. Шуның өчен нәфесне яшь вакытта тыярга, гакылны нәфескә хуҗа итәргә кирәк.

ГАҖӘБ (ОЛУГЛАНМАК)

Үзенә-үзе исе китеп, мин галиммен яки баймын, дип үзен-үзе югары дәрәҗәдә күрмәк, олугланмак — яман холыкларның зурысы — тәкәбберлек сыйфатыдыр. Бу исә шәригатебездә бик зур гөнаһлы фигыльләрдән булып, адәмне ярамас хәлләргә төшерер. Аллаһы Тәгалә каршында гамәлләрнең олысы үзеңне-үзең ким күреп, нәфесеңне түбән күрмәктер. Олугланмак белән изгелек булмас. Бәндәгә ни илә олугланмак кирәк? **Бай булса, байлык — Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтедер. Ул бер көн синдә булса, иртәгә икенче кешегә күчүе дә ихтималдыр.** Гамәл илә олуглану янә мөмкин түгел, чөнки гамәлнең кабул булуы мәгълүм түгелдер. Галим булса, гыйлемне бирүче дә Аллаһы Тәгалә булганлыктан, ул нигъмәтне бирүчегә даими шөкердә булып, үзеңне ким вә түбән күрмәк тиештер. Галимнәр: *«Адәмнең иң галиме Аллаһы Тәгаләдән куркучысыдыр, әмма адәмнәрнең иң надане — үзен-үзе олуг күрүчедер»,* — дигәннәр. Олугланмак адәмне дөнья вә ахирәттә харап итәр, чөнки үзенүзе олуг күрүче гөнаһын хәтерләмәс, ахирәтне күңеленнән чыгарыр, дөньяда үзеннән зур кеше юк, дип фараз итеп, һәркемгә тәкәбберләнеп, барлык изгелектән мәхрүм калыр. Мондый кешене һәркем дошман күреп, аның янына бармаслар, аннан ерак булырлар. Андый кеше байгыш кеби үзенә тиң тапмый ялгызлыкта һәлак булыр.

САБЫРЛЫК

Бәла-каза килгәндә сабыр итү һәм башка гамәлләрнең һәркайсында сабырлык, вәкарьлектә булу — күркәм холыкларның иң олугсыдыр вә бик изге сыйфатлардандыр. Сабырлыктан олуг чара һич булмас. Сабырлык илә барча мөшкелләр җиңел булыр. Башка бәла килгәндә сабыр итми, кайгырып «аһ-аһ», дип үртәнү дошманыңны гына шатландырудыр. Хәзрәти разый Аллаһу ганһү: *«Һәр囲 эштә сабыр итү тәндә җан кебидер — баш булмаса тән бернәрсәгә ярамас. Эшеңдә сабырлык булмаса, ул эштән һич файда булмас»,* — димештер.

Бабаларыбыз: *«Сабыр төбе — сары алтын»,* — дигәннәр. Бик гүзәл мәкальдер. **Берәү сиңа яман сүз әйтсә, син аңа яман җавап бирергә ашыкма, сабыр ит. Чөнки яман кеше синнән дә яман итеп, зур кычкырышларга, олуг җәнҗалга китереп, мәсхәрә булырсың.** Әгәр сабыр итсәң, сине һәркем гакыллы, сабырлы, тәүфыйклы, дип мактап, сиңа мәхәббәт итәрләр. Әмма дошманыңны ахмак, холыксыз диярләр. Сабырдан һичвакыт зарар килмәс, әмма ашыгу күп вакыт адәмне һәлак итәр. Шуның өчен галимнәр, ашыгып үкенечкә калудан сабыр илә үкенеч хәерлерәктер, димешләр.

Балалар, сез һәр эшегездә сабырлык итәргә тырышыгыз. Юк нәрсәләр өчен хафаланып, куркып-каушап үзегезне үзегез һәлакәткә салудан сакланыгыз. Сабырсызлык яман холыкларның башы булып, күптөрле ярамас эшләргә сәбәп булыр.

СҮЗДӘ ӘДӘПЛЕ БУЛМАК

Сүз адәмне барча хайваннардан аерган кеби, адәмне адәмнәрдән дә аерып, кешенең кем идекен күрсәтүче бер корал булганлыктан, әдәбен кайгыртмак һәрбер әдәпле кешенең бурычыдыр. **Сүз сөйләүче — үз теле илә үзенең кем идекен әйтеп бирүчедер.** Мәҗлесләрдә озын-озын хикәяләр сөйләмәк; кешегә һичбер юл бирми, даими үзең генә сөйләп тормак; сүзне сөйләгән вакыт тыңлаучыларга аңладыңмы, дип, мәҗлес әһлен аңсыз ахмак җиренә куймак; һич хаҗәт булмаган сүзләр сөйләмәк яки бер сүзне берничә мәртәбәләр сөйләмәк; бик кычкырып яки кеше аңламаслык акрын сөйләмәк; сүз арасында һич тиешсез, ягъни буш сүзләрне тәкрар әйтеп, үзеңнең сөйли белмәгәнлегеңне күрсәтмәк; күзкашларны кузгатып, кулыңны яки бармагыңны селкетеп сөйләмәк; бере өстенә берен ашыгып сөйләмәк; ярамас көлкеләр сөйләмәк; мәҗлестә булган кешеләрнең берсен хурлап, кешенең хәтерен калдырырлык сүзләр сөйләмәк — һәркайсы әдәпсезлектер. Мондый холыксызлардан бик саклану тиештер. Кеше сөйләгән вакыт ихлас илә генә тыңлап тормак; сөйләүченең сүзен ачык йөз илә кабул итмәк; үзеңнән зурларга юл бирмәк, алардан алда сөйләүдән сакланмак — сүзнең әдәбеннәндер. Мәҗлесләрдә сүзне бик саклык илә сөйләргә гадәтләнү — гакыллы, инсафлы балаларның холкыннандыр. Сез, балалар, моны бик игътибар кылыгыз. Үзегездән зурлар сүзгә керешсә, аңа каршы төшүдән сакланыгыз.

Берәү бер кешедән сүз сораса, җавап бирергә ашыкма; сүзне аңламастан, әүвәл алай түгел, болай ул, дип кире кагарга ашыкма; кешенең сүзе тәмам булмыйча аның сүзен бүлеп сөйләмә; сүз арасында оятсыз сүзләр, начар, әдәпсез урам сүзләрен катыштырудан бик саклан. **Кешегә каршы төшеп, берәүнең сүзен бүлеп хәтерен калдыру, сөйләр өчен кычкырыш-тавыш чыгару — бик әдәпсезлек вә ахмаклыктыр.** Берәү сөйләгәндә көлеп тормак яки читкә карап тормак; кеше сөйләгәнне тыңламый башка кешеләр илә сөйләшеп тормак; сүз сөйләүчегә тукта, чү, ялгыш сөйлисең, дип кычкырмак; берәү хәсрәтен бәян кылып сөйләгәндә шатланып тормак; шатлыгын сөйләгәндә йөзне чытып кайгы рәвешендә тормак — әдәп вә тәрбиясезлек галәмәтедер. ■

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Аз, ләкин дәвамы булган изгелек, дәвамсыз булган изгелектән яхшырактыр. Чөнки керешкән эштә ныклык күрсәтмәү вә дәвам иттерә алмау, ул эштә мәхәббәт камил булмау да ялкаулыкка галәмәттер.

● Ихлас булмаган гамәлнең дәвамлысында да, дәвамсызында да хикмәт булмас.

● Дусларның дошман булып китүләре вә дошманнарның дус булулары мөмкин. Дус вакытта тиешле булган хәлләрнең бөтенесе белдерелсә, дошман булганыннан соң, үкенечле булырга мөмкин.

● Күңел ихлас булса вә кабул булынуына игътикад (инану) урынлашса, дога, теләсә нинди вакытта вә теләсә нинди тел белән булсын, кабулият белән мөшәррәф (бәхетләнгән) вә файдасы күреләчәктер.

● Бер кавем вә бер милләт яхуд бер кабилә вә җәмгыятьнең олугсын хөрмәт кылу шул кавем вә милләт яки кабилә вә җәмгыятьнең бөтенесен хөрмәт итү булыр.

● Бер кавемнең хөрмәтлесе булган яки гыйлемнән ләззәт алган кешеләрне кадәри хәл ихтирам кылырга тиешле.

● Адәм баласы өчен кайгылар бик авыр вә уңайсыз нәрсәләр, шулай булса да, һәр авырлыкның астында бер җиңеллек вә бертөрле файда булганлыктан, кайгылар да файдасыз түгел. Кайгы күрү сәбәбеннән адәм балаларының холыклары төзәлә, күңелләре яхшылана, гакыллары артадыр.

● Адәмнең башларына килә торган һәлакәт вә казаларның күбесе сер фаш ителү сәбәбеннән булуы мәгълүм.

● Кеше үз серен үзе сакларга тиешле. Үзе саклый алмый башка берәүгә сөйләсә вә аннан башкаларга таралса, моның өчен шул кешене шелтә кылырга хакы юктыр.

● Һавадагы торнага була кулдагы чыпчыкны җибәрү — гакылсызлыктыр. Килүе катгый булмаганнан, күпкә аз булса да, килеп торган нәрсә яхшырак.

● Иманы булмаган кешенең каршында изгелек белән явызлык арасында күп аерма булмас.

● Кеше үзе хакында ялгышырга, үз гаиләсеннән күзе сукыр булырга мөмкин. Шул сәбәпле үз хәлен белергә теләүчеләр өчен дөрес юл — кешеләрнең сүзләрен ишетүдер.

● Бер милләтнең дини эшләре әһәмиятсез адәмнәр кулларына төшү берлә кыямәт булмаса да, шул милләтнең юкка чыгачагы вә хәят китабы төрелеп, тарих архивларында сакланачагы мәгълүм.

***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Тәрбия эшендә мөһим бер мәсьәлә

Кәбир Туйкин

Бала киләчәк тормышка әзерләү өчен тәрбия ителә. Әгәр баланың яшәве өметле булмаса, аны тәрбия кылу өчен энергия түгүнең мәгънәсе дә юк. Шуның өчен хәзерге педагогия тән тәрбиясенә, гигиенага зур урын бирә. Фән, әдәбият яңалыклары мәдәнияттә өстен торган халыклар арасында иртәрәк тарала. Педагогиянең дә тән тәрбиясенә, гигиенага әһәмият бирүе бездә хәзер генә телгә алына башланса да, мәдәнияттән алдан баручы халыклар арасында ул моннан берничә ун еллар элек гамәлгә куелган һәм нәтиҗәләре дә мәйданга чыккан. Мәсәлән, инглизләрнең атаклы философ һәм педагогларыннан саналган Спенсер (1820-1904): *«Баланы иң элек таза хайван итеп, аннан соң гына кеше итеп тәрбияләргә кирәк!»* — дигән лозунгны куйган. Гомумән алганда, Көнбатыш Европаның күп мәмләкәтләрендә тән тәрбиясенә, гигиенага нык әһәмият бирелгән. Шуның аркасында анда үлү безгә караганда бермә-бер ким. Европада елына 1000 кешедән 13-14 кеше үлә. Бездә 1000 кешедән 26 кеше чамасы үлә. Әле бу хисап бөтен Русия күләменә каратып ясалган, әгәр ул татар-башкорт халкына каратып ясалса, куркынычлы рәкымнар килеп чыгачак.

Халыкның үрчү-үрчемәве, икенче төрле итеп әйтсәк, яшәү-яшәмәве сәяси, иҗтимагый, икътисади һәм тарихи булган күп сәбәпләрдән килә. Шулар арасында педагогия иң зур урынны тота һәм мәсьәләне йә иҗаби, йә сәлби якка борып җибәрү дә нык роль уйный. Шунлыктан, без үзебезгә: «Безнең тәрбиябез берәмләрне һәм җәмгыятьне яшәтү нигезенә корылганмы?» — дигән бер сорау куярга һәм шуның җавабын эзләргә тиеш. Татар-башкорт халкы кебек, мәдәнияттә артта калган бер халыкның педагогларына, тәрбиячеләренә бу мәсьәләгә аерата әһәмият бирергә бик вакыт.

Бу мәсьәләне матбугат битләрендә, конференцияләрдә, мәктәпләрдә эшләп киңәйтергә, тирәнәйтергә һәм системага салырга кирәк булыр. Мәктәпләрдә анатомия-физиология, гигиена һәм дарвинизм системалы алып барылса һәм аңа күбрәк вакыт бирелсә, бигрәк тә педагогия курсларында, педагогия техникумнарында бу мәсьәләгә аерата әһәмият бирелсә, югарыда язылган сорауларга җавап бирүнең ишекләре ачылыр иде.

Туйкиннарның әниләре Гайшә Фәхри кызы, уллары Кәбир һәм Фазыл гаиләләре белән. Уң якта Кәбир, сул якта Фазыл гаиләсе. Бөгелмә, 1928 ел

Рәкым — цифр.
Иҗаби — уңай.
Сәлби — кире.
Нәзария — теория

Рухи хәлләр (ми системасында була торган физиология үзгәрешләре) белән тәннең башка әгъзалары арасында нык бәйләнеш булу — күптән билгеле булган бер мәсьәлә. Шулай ук төкерек бизләре, ашказаны бизләре, озынча биз, тир бизләре кебек сыеклык чыгара торган аппаратларның әһәмиятләре дә күптән билгеле бернәрсә. Соңгы елларда анатомия-физиология фәннәре бик зур адымнар атлады. Ул адымнарның берсе шуннан гыйбарәт: кешенең тәнендә бизләр (секрецияләр) бик күп. Алар төрлесе-төрле матдәләр эшләп чыгаралар. Аларның эшләп чыгарган матдәләре кешенең яшәве, эшләве өчен һава дәрәҗәсендә мөһим. [...]

Бу нәзарияләрнең сөземтәсе шул була: кайгы, курку, борчылу кебек сәлби булган рухи хәлләр, бизләргә сәлби яктан тәэсир итеп, бизләрнең эшләвен зәгыйфьләтә йә бөтенләй туктата. Көлү, шатлану, кәефләнү кебек иҗаби булган рухи хәлләр, бизләргә иҗаби яктан тәэсир итеп, бизләрнең эшен көчәйтәләр. Менә бу мәсьәлә педагогия өчен бик зур һәм файдалы материал бирә. Рухи хәлләрнең сәлби булганнары, бизләргә сәлби тәэсир ясап, кешенең (балаларның да) саулыгын югалта, организмын зәгыйфьләтә. Иҗаби булган рухи хәлләр, бизләргә иҗаби тәэсир итеп, кешенең организмын ныгыта, савыктыра. Кешенең организмнары ни тикле нык булса, ул төрле авыруларга да шултикле каршы тора ала. Организм зәгыйфь булса, авыруларга (чирләргә) каршы тора алмый. Димәк, кайгы, курку, борчылу кешенең саулыгы өчен ни тикле зарарлы булса, көлү, шатлану кебек кәефле хәлләр кешенең саулыгы өчен шултикле файдалы була. Спенсер да әйтә: *«Һәртөрле борчылу кешедә авыру тудыра. Көлү — шул борчылудан туган авыруларга дәва була»*, — ди.

Хәзер без үзебезгә тукталып китик: бездә көлү бармы? Үкенечкә каршы, һич юк. Без көлә дә, көлдерә дә белмибез.

Менә шуның өчен безнең алдыбызда (башка эшләр белән бергә үк) күңел ачу, күңел күтәрү, көлү кебек саулыгыбыз, яшәвебез өчен һава дәрәҗәсендә кирәкле булган бер эшне алга җибәрү эше тора. Бу эштә юлбашчылык итү анатомия, физиология, гигиена, психология, педагогиядән азмы-күпме хәбәре булган укытучылар һәм башка укымышлылар өстендә торса, бу эшнең беренче урыны яшь буынның кешелек фабрикасы булган мәктәпләр булырга кирәк.

Мәктәптә балаларны күңелле тоту, уйнату, вакыт-вакыт көлдерү мәктәп яшьләре арасында кызыл җеп кебек сызылып барырга тиеш!

Кеше тәрбиясенең бик аз өлеше генә мәктәп эчендә була ала. Баланың күбрәк вакыты мәктәп тышында, гаиләдә үтә. Ашау-эчү, кием-салым, ял, йокы, уен кебек бала тәрбиясенең бик зур бер өлеше гаиләдә үтәлә. Аннан башка баланың яралдык чорыннан башлап, мәктәп яшенә чаклы булган тәрбиясе һәм мәктәп тышында калган балаларның тәрбиясе бар. Шулар өстенә мәктәп яшеннән узган үсмерләрнең һәм зурларның тәрбиясе, кешенең үз-үзенә тәрбиясе бар. Мәктәп эчендәге тәрбия дә мохит белән бик нык бәйләнә, шунлыктан тәрбия мәсьәләсен киң күләмдә алырга туры килә. Шуның белән бергә тәрбия эшендә мәктәпнең ролен билгеләргә кирәк булыр: мәктәп, бөтен тәрбия эшләренең мәркәзе булып, мәктәп тышындагы тәрбиягә үрнәк булырга һәм җитәкчелек итәргә тиеш. Әгәр мәктәп тәрбияне үз эчендә генә алып барырга маташса, бик зур ялгышкан булыр иде. Шунлыктан мәктәп тәрбиянең нигезләре, максади юллары белән бөтен мохитне таныштырып барырга һәм тәрбиянең зур бер өлешен мәктәп тышына юнәлдерергә тиеш. Бигрәк тә саулык саклау, яшәү мәсьәләсен аерата хатын-кызлар арасында үзләштерү тәрбиянең алдынгы бурычларыннан санала һәм зур энергия көтеп тора.

Бөгелмә

«Мәгариф». — 1927. - №4. — 31-33 б. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

1. УТАЧЫЛАР (ТАБИБЛАР) БЕЛӘН АРАЛАШУ ТУРЫНДА

Шуларның бер төре – имче, табиблар,
Барча чир-ауруны нәкъ шулар имләр.

Бу кешеләр сиңа кирәк булырлар,
Исән-сау яшәргә терәк булырлар.

Тере бәндә калмас аурусыз-чирсез,
Хастадан ут[1] илә дәвалар имче.

Чир ул әле тере булу билгесе.
Үлем – терелекнең тәмам киресе.

Имчеләрне изге бел һәм тот якын,
Кирәклеген таны һәм хакла хакын[2].

2. СИХЕРЧЕЛӘР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Болардан соң килә – бар әфсүнчеләр,
Сихер вә зәхмәттән алар имчеләр.

Аралашу кирәк болар белән дә,
Чакырырга җил-җик чире тигәндә.

Күрим, дисәң, бераз файда, батыр дус,
Аларны да якын тот һәм бер сүз куш.

Сихерчене табиб өнәми бер дә,
Сихерче табибтан йөзен чөергән.

Ләкин кяр итмәстер гел дару гына,
Бөти ярап куя ич ару гына.

3. ТӨШ ЮРАУЧЫЛАР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Тагы бер белек, күр, бу төш гыйльме ул,
Төш күрсәң, юраучы ачар иге юл.

Йокласа бер кемсә һәм дә төш күрсә,
Файдалы булачак, тәгъбире килсә.

Игегә юраса ки төш юраучы,
Иге ул булачак, белеп тор – ачык.

Әгәр юралышы бик яман булса,
Хәер бир ярлыга, гомумән бул сак.

Бу төш гыйльмен Тәңре Тәгалә, хәтта,
Хәтергә алган берничә аятьтә.

Төше иге булса, торып сөенсен,
Иге булмаса бер Хакка сыгынсын.

Имчеләрне изге бел һәм тот якын,
Кирәклеген таны һәм хакла хакын.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Ут – «үлән, үсемлек».
[2] Ягъни — «тиешенчә әҗерен бир, түлә».

Ярлыга өләшсә әйбер һәм акча,
Иншаллаһ, аңардан афәт качачак.

Яхшыга юралса төшең — юш килер,
Ләкин ул төшеңне нечкәләп тикшер.

Юраучының кирәк белеме киңе,
Үзе булсын зирәк, күңеле изге.

Боларны хәтерлә, истә тот, туган
(Теләсәң, кардәш мин, теләсәң агаң).

4. ЙОЛДЫЗЧЫЛАР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Хәзер инде килик йолдызчыларга,
Эшнең иң нечкәсе менә шуларда.

Ел, ай, көн исәбе боларда туган.
Бу исәп бик кирәк булгалый, туган.

Моны белим, дисәң, бел һәндәсәне –
Санарга өйрәтә ул һәрнәрсәне.

Өйрән тапкырлауны, бүлү-кәсерне[3],
Кырыс имтихан тот һәм бул тәдбирле.

Дәрәҗәне бел һәм төркем ысулын,
Шуны белгәч, тамыр алырга алын.

Кушу һәм чигерү, мәйданнар үлчәү,
Җиде кат фәләктән билгеле бүлҗәл[4].

Тагын да эстәсәң әлҗәбер укы,
Һәм Уклидис-галим ишеген туки[5].

Кирәк дөнья эше, кирәк ахирәт,
Галимнәр санаса, беленә бигрәк.

Рәтсезлеге дөнья һәм дин эшеңнең,
Юк кына нәрсәңнән башланыр синең.

Бер эш эшлим, дисәң, белеп әмәлен,
Сорау кирәк яхшы һәм яман мәлен.

**Белгечтән сораш, тик ышанып барма,
Чын белгеч һәр эштә – фәрештә, Алла.**

Котлы көн һәм ай бар, була котсызы,
Котлырагын сайла инде, дус кеше.

Ни шәп сүз әйткән бер белемле карый:
«Эшне бик белешкәч, эшләргә ярый.

Инсан эшне белем илә башласа,
Ирешер, мөгаен, теләк-максатка.

Беренче ярдәмче һәр эштә – белем,
Белемең кичексә, өлгермәс кулың».

Белгечтән сораш, тик ышанып барма,
Чын белгеч һәр эштә – фәрештә, Алла.

Белгечне изге бел, ярат, хөрмәтлә,
Аның белән юкка-барга телләшмә.

5. ШАГЫЙРЬЛӘР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Шагыйрьләргә килик, сүз тезүчегә –
Кешене мактаучы һәм тиргәүчегә.

Кылычтан да үткен боларның теле,
Вә кылдан нечкәдер уе-күңеле.

Нечкәрәк мәгънәле һәм татлы сүзләр
Ишетим, дисәң син, шагыйрьне эзлә.

Алар, уйлап баксаң, диңгезгә кереп
Энҗе-якут тапкан гауваслар[6] кебек.

Алар данлаган зат илдә дан ала,
Алар сүксә — яман аты тарала.

Болар белән сак бул, рәнҗетмә бер дә.
И, кардәш, эләкмә бер һөҗви[7] телгә,

Әгәр дә үзеңә мактау теләсәң.
Сөендер аларны – булды, вәссәлам!

---

[3] Монда терминнар — кәсер (бүлү калдыгы), дәрәҗә һәм тамыр турында бара.
[4] Бүлҗәл – «унике еллык хайван циклы».
[5] Бу урында бик күп гарәби математик терминнар китерелә. Без аларны якынча тәрҗемәләдек. Уклидис – Евклид. Әлҗәбер – «алгебра».
[6] Гаувас – «водолаз».
[7] Һөҗви – сатирик, мыскыллы.

Дөрес яшим, дисәң һәрнинди хәлдә,
Ашың хәләл булсын, акыллым, тәүдә.

Әгәр сорасалар нидер, бир генә,
Үзеңне сатып ал болар теленнән.

6. ИГЕНЧЕЛӘР БЕЛӘН АРАЛАШУ ТУРЫНДА

Игенчеләр тагы бер котый[8] катлам,
Кем-кем, ә игенче кирәктер мотлак.

Болар белән, түрә, йөреш, аралаш,
Уйла – алар бирә сиңа икмәк, аш.

Барча аяклыны нәкъ болар асрый,
Җитештереп тора ил-атка аш-су.

Кемнең тамагы бар һәм дә сулышы,
Боларга мохтаҗ була һәм бурычлы.

Сиңа шиксез кирәк ошбу кешеләр:
Яшәү һәм ашауны хәл итә шулар.

Болар белән сөйләш:
«Ничек, – дип, – хәлләр?»
Авызың пакь булыр һәм ашың хәләл.

Ни ди, ишет, әнә сагынык башы[9] –
Һәр хәвефле эштән сакланган кеше.

«Дөрес яшим, дисәң һәрнинди хәлдә,
Ашың хәләл булсын, акыллым, тәүдә.

Сакланып эш итим, дисәң, билгеле,
Мөһим ризыгыңның саф, хәләллеге.

Фәкыйрьлектән чыгып бай булыйм, дисәң,
Азу-тузудан бик саклан син, белсәң.

Һәрвакыт хөрмәттә булыйм, дисәң дә,
Талауга катнашма, гадел бул, бәндә.

Талау боза илне төптән – тамырдан,
Чыгара төп эздән һәм сау акылдан.

Ирешкән бәхтеңне фетнәдән сакла,
Фетнә ул үрт – янгын кабызгыч чакма.

Ни шәп әйткән гүзәл кыланышлы зат –
Гыйлеме һәр эштә кулланышлы зат:

«Фәсәт-фетнәләргә син килмә якын,
Каралтыр корымы, тимәсә ялкын.

Фәсәт белән дәүләт тормаслар бергә,
Торса, кунак кебек – фәкать бер төнгә».

Кыскасы, җирбагар – синең терәгең,
Аның тәңре бирмеш кулы, күңле киң.

Җир йөзендә ниләр йөзә, очалар
Һәм йөриләр – ашка мохтаҗ ич алар.

Җирбагарга катыл, үтә, сүз бирсәң,
Яхшы сүзләр сөйлә, ачык йөз күрсәт.

Булмаса сәүдәгәр – дөнья гизүче,
Кайчан кияр идең шәп тун – кеш эчле.

7. САТУЧЫЛАР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Болардан тыш тагын сатучылар бар
Сату өчен йөрер, төрле юл табар.

Аллага тапшырып, ерак китәләр,
Яшәү кирәгеннән сәүдә итәләр.

Алар белән булаш, әвеш-тәвеш ит,
Сораганнарын бир, алыш-биреш ит.

Дөньяңа ни кирәк, булыр аларда:
Илгә тансык бизәк, сирәк таварлар.

Шәрыкътән гарепкә урап киләләр,
Ни теләсәң шуны табып бирәләр.

Төмән төрле һәм ил тансыгы булган
Нәрсәләрне алар табырлар, туган.

Булмаса сәүдәгәр – дөнья гизүче,
Кайчан кияр идең шәп тун – кеш эчле.

Кытай кәрваны һәм аның чаң чыңы
Булмаса, табылмас тавар асылы.

---

[8] Котый – КБ-тә «группа, социаль катлам» мәгънәсендә кулланыла, гомумән исә «шкатулка».
[9] Сагынык – гомумән «хәвефсезлек», КБ-тә, күрәсең, «дума, дәүләт советы».

Сәүдәгәрләр ерак барып алмаса,
Энҗе-мәрҗән күрмәс идең ләбаса.

Саный китсәң шундый нәрсәләр төрен,
Сүзең озын булыр һәм талыр телең.

Менә шундый була сәүдәгәр халкы,
Аларга кагыл һәм ачык тот капкаң.

Тырышып аларны якла, кадерлә
Һәм изге атыңны ерак җәерләр.

Болар ич дөньяда дан тараталар:
Яман йә яхшы, дип сөйләп кайталар.

Сиңа азмы-күпме бирсәләр әйбер,
Аларга бир әҗер – күңлен сөендер.

Сәүдәгәр бик белә файда-зарарны,
Сөйләшсәң, шул ягын байка аларның.

Ни ди, ишет, дөнья гизгән мосафир,
Күп күргән, башыннан кичергән бер ир:

«Дөньяда даныңны таратыйм, дисәң,
Чит сәүдәгәрләргә игътибар күрсәт.

Таратыйм, дисәң дөньяда даныңны,
Кунак затка[10] күрсәт игътибарыңны.

Даның ерак китсен, дисәң, кыл шуны –
Сәүдәгәрләреңә кызганма сыйны.

Теләсәң, китсен, дип, изге ат-даның,
Хөрмәтләп тот килгән сәүдә кәрванын.

Шул мөгамәләдә бул сатучыга.
Тыныч сәүдә барса, син шатлан шуңа.

8. ТЕРЛЕКЧЕЛӘР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Терлекче хакында инде сүз ачыйк:
Барлык хайваннарның ул ич хуҗасы.

Терлекчеләр — гадел. Юк йорты-ние,
Кешеләргә менмәс аларның йөге.

**Белексез кешедән, зинһар, ерак тор,
Алардан саклану отышлырактыр.**

Җийге, киге, меңге айгыр – сөлекләр,
Болардан чыгар йөк йөкләр көлекләр[11],

Кымыз, сөт йә йон, җәү һәм йогырт, корыт,
Җәемлек киез һәм эзәр – өйгә тот[12].

Файдалы кешеләр ошбу кемсәләр,
Яхшы булыр файда күрсәтсәң әгәр.

Аларга аралаш, ашат һәм эчер,
Гадел бул, бергәләп тереклек кичер.

Бир сораганнарын, ал кирәгеңне,
Алдамаслар алар – мин беләм инде.

Болардан сорама низам, белекне,
Хөкемнәре иркен була, и, иплем.

Һәм бик әдәпле бул аралашканда:
Җәзада түрәгә бармаслар алар.

Иплэп сөйләш: алар һич дус түгелләр,
Басымчак булыр бик җаһил чигилләр[13].

Ни яхшы әйткән бер низам бирүче,
Халык белән булып, сынап белүче:

«Белексезне артык якын тотма син —
Көтелмәгән бер эш килеп чыкмасын».

Моннан да яхшырак әйтә тәгълимат
(Эш иткәндә дөрес тәгълимат кыйммәт):

«Наданга ягылма, үзеңне сакла,
Бәхетле яшәрсең менә шулчакта».

Белексез кешедән, зинһар, ерак тор,
Алардан саклану отышлырактыр.

Менә шундый инде терлекчеләр дә,
Бу сүземне онытма төрле хәлдә.

Дәвамы бар ■

[10] Кунак зат — «сәүдәгәр» мәгънәсендә.
[11] Ягъни: олау, йөк ташу өчен кирәкле атлар да болардан саттырып алына.
[12] Бу сәтырларда кайбер сирәк сүзләр очраса да, татар сөйләшләрендә барсы да бар. Сөлек – монда «хәрби ат», көлек – «юл, олау аты», эзәр – «өй тирәли пәрдә, түрләмә».
[13] Чигил халкы. Чагыштыр – болгар кабиләсе эсегел.

КАЙТ ӘЛЕ МОНДА, ВАТАНГА!..

Мөдәррис Вәлиев

Мин – бәхетле авыл баласы. Нәби ага Дәүли белән бер авылда туганмын, Шамил абыем Маннапов белән бер йортта үстем. Күршедә – Габдулла Кари авылы Күлбай Мораса, Фатих Сәйфи-Казанлы туган Карамалы... Үргәрәк менеп карасаң – Хәсән Туфан, Нәҗип Думави, Утыз Имәни, Абдулла Алиш, Габделҗаббар Кандалый карьяләре күренә. Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмә бездән нибары утыз чакрымда гына... (Башкаларын санап тормыйм.) Әмма Гаяз Исхакый исемен мин, оятыма күрә, «Казан утлары» журналында эшли башлагач кына ишеттем һәм иҗаты белән дә шулчакта ныклабрак таныштым.

Мәктәп елларын әйтеп торасы юк, университетта XX йөз башы татар әдәбиятын укыткан мөхтәрәм мөгаллимнәребез дә аның исемен телгә алырга курыкканнардыр, күрәсең. «Казан утлары» журналында эшләгән вакытта Гаяз Исхакый хикәяләренең машинкада басылган ничәнчедер нөсхәсен миңа күренекле язучыбыз Рабит Батулла алып килгән иде. Без алар арасыннан «Башкорт бәхете» дигәнен сайлап алып бастырдык (Ибраһим Нуруллин кереш сүзе белән, 1989, 6 нчы сан). Бәхетсезлеккә күрә, дип әйтимме (бу әле партия өлкә комитеты дигән өркет-оешмалар заманы иде), озак та көттерми, Уфа ягыннан шикаять килеп төште: аларга татар классигы әсәрендәге «башкорт» сүзе ошамаган. Шуның өчен партия безне утлы табага бастырырга маташты. Мәгәр буа ерылды, аны инде туктатып булмый иде: 1989 елның 1 нче санында Әмирхан ага Еникинең «Көтелмәгән хат», 1990 елның 1 нче санында Ибраһим ага Нуруллинның «Кайту» дигән мәкаләләрен һәм шул ук вакытта «Ике йөз елдан соң инкыйраз» романын, «Сөннәтче бабай» хикәясен (әзерләүчеләр – Рифә Харрасова, Ибраһим Нуруллин), Гаяз Исхакыйның Максим Горькийга хатын (1990 ел, 10 нчы сан) бастырып чыгардык. Бу – баш мөхәррир Ренат Харис тырышлыгы белән, татар халык иҗатының йөзек кашы булган «Идегәй» дастанының да кабат кайткан чагы («дастан – бары тик башкорт халык иҗаты жанры» дип аңарчы ук шикаять язганнар иде). Соңрак Ибраһим ага Салаховның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») басылды. (Үзем редакцияләгәнгә беләм: Ренат Харис бу әсәрне дөньяга чыгару өчен «органнар» юлын күп тап-

Гаяз Исхакый.
Токио, 1935 ел



Тәрҗемәи хәле

«Милли байрак» газетасы хезмәткәрләре белән.
Мукден, 1936 ел





Әдипнең үзе исән чакта басылып чыккан китаплары

тады.) Урыс әдәбиятында боз кузгалу иртәрәк булса да, безгә, ике кат (федераль һәм автономияле) түшәм астында милли әдәбият-мәдәният хакына яшәгән-эшләгән кешеләргә, яз, һәрвакыттагыча, кичегебрәк килә бит.

Инде китап нәшриятларында эшләгән чагымда Гаяз Исхакыйның моңарчы Берлинда, Лондонда, Парижда, Варшавада, Токиода төрле телләрдә басылган тарихи-сәяси «Идел-Урал» хезмәтен (Рафаэль Хәкимов язган кереш сүз белән), шулай ук яңа чордагы беренче әсәрләр тупланмасы «Зиндан»ны — анда әдипнең уникe проза әсәре, биш пьесасы кергән иде — (төзүчесе Лена Гайнанова; Гаяз Исхакыйның тормыш һәм иҗат юлы турында мәгълүмат биргән Ибраһим Нуруллин, Һәнүз Мәхмүтов, Лена Гайнанова мәкаләләре белән), Флүн Мусин, Миңнәхмәт Сәхапов монографияләрен, булачак унбиш томлыкның Лена Гайнанова төзегән һәм, асылда, барлык әдәби әсәрләрен үз эченә алган — баштагы биш томын (тыйнаклык сакламыйча әйтергә мәҗбүрмен: V томны басмага, инде мин Татарстан китап нәшриятыннан киткәч, Лена апа үтенечен тыңлап, «Мәгариф» нәшрияты хезмәткәрләре әзерләде), Фатыйма Ибраһимова төзегән VIII томны да дөньяга чыгаруда катнашырга туры килде. (Гафу итәсез, үзем белгән, Г.Исхакыйга мөнәсәбәтле эш чорларымны гына искә төшереп үтәм. Бу — әдипнең унбиш томлыгына бару адымнары иде, һәм ул буш урында гына тумады, дип әйтәсем килә.) Ниһаять, Татарстан Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Зөфәр ага Рәмиевтән соң текстология бүлеге мөдире вазифасын башкару миңа йөкләнгәч, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр Зөфәр Мөхәммәтшин, яшь галимәләребез Гөлназ Хөснетдинова, Фәния Фәйзуллина, Гөлчирә Ханнанова Гаяз Исхакыйның төрле газета-журналларда сибелеп калган, архивларда, шәхси кулларда сакланган язмаларын, хатларын һәм аның турында мәкаләләрне, истәлекләрне туплап төзегән тагын алты томы нәшер ителде.

Габдулла Тукайның «Мөхәрриргә» (1913) шигырендәге:

И мөхәррир!
Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир!


کوچمه اوقو کیتابلاری.


تاتار عقلی


مدرسه یپشی



Г.Исхакыйның Максим Горькийга язган хаты

Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!
Кайт әле монда ватанга, кайт әле,
саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер
җир тапмасынчы кер, рия!.. — дигән юллары Гаяз Исхакыйга багышланганын шагыйрьнең томнарын төзүчеләр йөз ел буе — 2013 елгы академик басмага кадәр язарга куркып килде. Рәис Даутов, Яхъя Халитов кебек нәшрият «зубр»ларының да теле «бәйле» иде шул. Академик басманың II томында исә (бераз көрмәкләнеп булса да) шундый аңлатма бирелә: *«Бу — Тукайның үлеменә 23 көн кала язган соңгы шигырьләреннән берсе. Ул сөргеннән кайтучы Гаяз Исхакыйны лаеклы каршылау өчен барган кампания уңае белән язылган...Татар милләте мәнфәгатьләре өчен көрәшүче Г.Исхакый 6 ел сөрген, төрмә һәм качудан Казан шәһәренә керә алмаган...»*

Хәтта Галимҗан Ибраһимов кебек шәхесләрнең, башка замандашларының китапларын әзерләп бастыручылар да Гаяз Исхакый исеменә сагаеп караган. Кайбер очракларда сәяси як кына түгел, көндәшлек тә мәгълүм роль уйнагандыр. Әмма инде бүген Гаяз Исхакый янәшәсенә басып нидер дәгъвалап азапланучылар, аның иҗатына «астагы балконнан» төкереп үз төкерекләренә

буялучылар аның белән көндәш була аламы соң?

Гаяз Исхакый исемен ишетеп кенә белгән кайберәүләрне аның белән беркадәр таныштырып китү урынлы булыр. Исмәгыйль Рәминең «Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлеге»ндә (Рәис Даутов редакциясендә) Гаяз Исхакый турындагы мәгълүмат шулай башлана: *«Язучы, җәмәгать эшлеклесе, революциядән соң эмигрант... Гыйлаҗетдин мулла гаиләсендә туа... 1906 елда бер-бер артлы «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», «Тавыш» исемле гәзитәләр чыгарып килә... 1913-1916 елларда «Ил», «Сүз», «Безнең ил» исемле гәзитәләр чыгара. Февраль революциясе булгач, «Ил» гәзитәсен яңадан тергезеп, большевикларга каршы яза... Гражданнар сугышы башлангач, Колчак армиясе белән бергә чигенеп, 1919 елда чит илгә чыгып китә. Маньчжурия, Кытай, Франция, Алмания, Польша, Төркия шәһәрләрендә яши, татар телендә «Милли байрак» гәзитәсе, «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара. Вафаты Төркиядә...* (Рәис Даутов искәрмәсе: *«Гаяз Исхакый 1954 елның 22 февралендә Анкара шәһәрендә вафат була һәм үзенең васыяте буенча Истанбул шәһәрендәге Әдернәкапы дигән зират ихатасына җирләнә».*) *Г.Исхакыйның әдәби әсәрләре 1911 елдан башлап «Гасыр» нәшриятында «Тулы мәҗмуга» булып басыла башласа да, тәмам булмый кала».* Газеталары белән халык күңелен агартса, реалистик әдәби иҗаты белән ул аны чынлыкны танырга, көрәш эченә өнди!

Әдипнең тәүге иҗат җимеше — «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» әсәре 1897 елда язылып, 1899 елда басылып чыга. Шуннан соң бер-бер артлы «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәясе, «Өч хатын берлән тормыш» (1900) пьесасы дөнья күрә. 1903 елда аның «Очрашу, яки Гөлгыйзар», «Бай углы» повестьлары һәм «Ике гашыйк» комедиясе, 1904 елда «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте басылып чыга. Сөргендә чагында да ул «Зиндан» (Казан, 1907), «Алдымбирдем» (Казан, 1907), «Тартышу» (1908; Мәскәү, 1917), «Солдат» (Казан, 1908), «Кыямәт» (Казан, 1910), башка әсәрләрен яза. Соңрак «Тормышмы бу?» (Казан, 1911), «Мулла бабай» (Казан, 1913), «Мөгаллимә» (Петербург, 1914), «Остазбикә» (Мәскәү, 1915), «Зөләйха» (Мәскәү, 1917) языла. Аны чын мәгънәсендә XX гасыр башы татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе, милли-мәдәни рухиятебезне яңа баскычка күтәрүче итеп таныткан — «Теләнче кыз» романы була.

Гаяз Исхакыйның иҗади мирасына ихтирамлы мөнәсәбәт, белгәнебезчә, аны үз туфрагына кабул иткән Төркиядә дә саклана. Татар әдибенә һәм сәясәт эшлеклесенә хөрмәт күрсәтү, иҗатын өйрәнеп, әтрафлы фәнни хезмәтләр язу анда күбрәк тә гамәлгә ашырылды бугай. Үзебездә исә туган авылында музее ачылу, зыялы якташлары Тархановлар һәм Закировлар фатихасы белән шунда ел саен Гаяз Исхакый укулары үткәрелүе, аның исемендә Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең махсус премиясе булдырылуы әдип шәхесенә һәм иҗатына игътибарны тагын да арттырды, дип әйтергә мөмкин. Алда телгә алынган монографияләрдән, мәкаләләрдән тыш, Хатыйп ага Миңнегулов һәм башка күренекле галимнәребез башкарган җитди тикшеренү-хезмәтләр, Галимҗан Ибраһимов исемендәге институт үткәргән төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдәге эчтәлекле доклад-чыгышлар да билгеле. Галиәсгар Камал исемендәге театрыбыз сәхнәгә чыгарган «Зөләйха» спектакле (премьера вакытында ике ягымда ике урыс утыра иде, алар бу мәлдә ни кичерә икән, дип «борчылуым» әле дә истә), шул трагедия нигезендә Рамил Төхфәтуллинның

нәфис фильм эшләве — икесе дә тәвәккәл һәм игелекле гамәл булды.

Татарстан китап нәшриятында басылган унбиш томлык «Әсәрләр» җыелмасы — Гаяз Исхакыйның әдәби һәм публицистик мирасы, шәхси хатлары, автобиографик язмалары, тормышына, иҗатына караган документлар, аның турында истәлекләр тупланган әлегә иң тулы басма. Кызганыч, ул чордагы нәшрият җитәкчелегенең тираж сәясәте аркасында «Әсәрләр»нең баштагы томнарын бүген китап кибетләрендә табып та булмый. Шуңа күрә, унбиш томның эчтәлеген кыскача искә төшерсәк, зыянга булмас.

Лена Гайнанова әзерләгән баштагы дүрт китапта әдипнең 1917 елга кадәрге әдәби мирасы — прозасы һәм пьесалары бирелгән иде. Алар арасында милләтнең киләчәге өчен борчылу белән тулы, аны саклау һәм үстерү юнәлешләрен билгеләгән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте, патша самодержавиесенең «кече туган»нарын күрә алмау сәясәтен фаш иткән «Зиндан» повесте, «Зөләйха» трагедиясе кебек әсәрләр бар. Бишенче том әдипнең мөһаҗирлектә иҗат иткән «Өйгә таба», «Көз», «Локман Хәким» кебек прозасын, «Дулкын эчендә», «Җан Баевич» кебек сәхнә әсәрләрен үз эченә алды. VI томны 1902-1914, VII томны 1915-1916 елларда «Тәрҗеман», «Таң йолдызы», «Бәянелхак», «Ил», «Казан мөхбире», «Сүз», «Безнең ил» газеталарында, «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре тәшкил итә. Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары язган мәкаләләр, аерым әсәрләренә бәяләмәләр, Казан губернасы жандарм идарәсе документлары (1898-1917) тупланманың VIII томында урын алды. IX том — 1917-1926, X том — 1928-1933, XI том — 1934-1936, XII том — 1937-1938, XIII том 1939-1954 елларда язылган сәясипублицистик хезмәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә. Аларда әдип күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче генә түгел, мөстәкыйль фикерле тарихчы-галим буларак та ачыла. Алда әйтелгәнчә, Гаяз Исхакыйның төрле мирасханәләрдә һәм шәхси кулларда сакланып калган хатлары, автобиографик язмалары (1902-1954) XIV томда туплап тәкъдим ителде. Андагы шәхси хатлар һәм «Тәрҗемәи хәлем» язмалары әдипнең тормышы белән танышырга теләгән укучылар өчен аеруча кызыклы. XV том — Гаяз Исхакыйның тормышы, иҗади һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турында 1923-1990 елларда төрле илләрдә басылган мәкаләләр, истәлекләр җыентыгы.

Бер яктан куанычлы, икенче яктан көенечле — моңа кадәр әле бер генә татар әдибенең дә язма мирасы шулай тупланып киң катлау укучыларга тәкъдим ителгәне юк иде. Гаяз Исхакыйның иҗади мирасын барлаучылар белә: аның «ватан»нан сөрелгәч, мөһаҗирлектә озак еллар яшәп иҗат итүе, хәтта исемен телгә алу да хакимият тарафыннан тыелган булуы һәм шуның аркасында әсәрләренең төрле киштәләрдә чәчелеп-сибелеп калуы шактый кыенлык тудырды. Алдарак «әлегә иң тулы басма» дип ишарә итүем дә шуңа — ул хезмәтләрнең кайберләре хәзергәчә шәхси кулларда кала, фәнни әйләнешкә кертелми дип беләбез. Шулай да, җитәкчелек хуплап торганда, эшләр болай барса, Татарстан Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгән Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимовның — якын елларда, ә соңрак Фатих Әмирханның да күп томлы академик басмаларын күрергә насыйп булыр әле! ■

МӘДРӘСӘ ҖИМЕШЕ

Гаяз Исхакый

Яңа мулланың указыны алып авылга килүе бөтен авылның муллага кияүгә чыгарга әзерләнгән кызларының башыны әйләндерде. Әйләндермәслек тә түгел: күз алдында яшь-яшь, өйләнмәгән, указлы мулла: «Кайсыңызны алыйм?» — дип басып торсын, имеш.

Иске хәзрәтнең кызы — мулла кызы булуы өчен, әнисе шул мәхәлләдә остазбикә булуы өчен: «Бу урын мирас тарикынча миңа тиеш!..» — дип дәгъва кылды. Тире берлә сатучы бай Садыйк абзыйның Соруры: «Безнең әти авылның бае, шуның өчен авылның иң зур дәрәҗәле урыны, остазбикә булып яшь муллага бару — минеке!..» — дип уйлады. Атасы авылның бае, агасы авылның куштаны Фәхриҗамал: «Безнең әти дә, абый да аны мулла итәр өчен әллә никадәр тырышты, бездән узып ятка барырга оят!..» — дип мулланы үзенә багышлады. Гөлчәһрә, шул кызлар арасында байлыгы берлә дә, дәрәҗәсе берлә дә тартыша алмаса да, матурлыгы, зифалыгы берлә һәммәсене бәреп екканга: «Мулла — минеке!» — дип утыртып куйды.

Менә шулар арасында Хәйдәр шәкерт мулла була башлагач та башланган бүлеш, яңа мулла указлы булып килгәч, тагы кызды. Кызлар мәҗлесе булырга ярамады, кызлар бер-берсене төрткәләшергә тотынды; хатыннар мәҗлесенең берсе дә шул кызларның аналары арасында кыч-кырышусыз үтмәде. Бөтен авыл шул Хәйдәр мулланың өйләнүе берлә мәшгуль булды. Бөтен авылның хатыннары гына түгел, хатын-кыз табигатьле ирләре дә мулланың һәр эшене, һәр хәрәкәтене тикшереп, килгән-киткән һәр кешене күздән кичереп, бөтен белгән-ишеткән хәбәрене урамга чыгарып, кибеткә барып сөйләп, суга барганда очраган ары як хатынына серне ачып яши башлады. Аурупаның патшасы кеби, мулланың бөтен тормышы, пыяла ящикка куелган нәрсә кеби, яхшы, яман тарафлары авылга күренеп торды, һәммә кешенең күз алдында тору туйдыргангамы, әллә мәдрәсәдә ялгыз торудан җик чиккәнгәме, Хәйдәр үзе дә тизрәк өйләнергә уйлый башлады. Хәйдәрнең күңеленә кергән вакытта ук шул хәбәр авылның бөтен тарафына «телеграф» берлә таратылганга, бөтен өйләрдә, урамнарда, су юлларында тагы шул мәсьәлә мөзакәрәгә куелды. Шул көнне үк Сорурның атасы — тирече бай килеп: «Фәлән боярдан, хәзрәт, җир алмакчы булам, кызым исеменә алсам, ничек булыр икән? Шәригать шуңа ничек әйтә?» — дип байлыгының дәрәҗәсене, кызның кыйммәтене сөйләп китте.

Фәхриҗамалның куштан агасы муллага тәэсир итәр өчен башка юл тапты. Ул әтисенең каралык исемене бетерер өчен быел әтисенең хаҗга җибәрү хәбәрене таратты. Иртәгесен үк яшь мулланы иртәнге чәйгә алып, хаҗга китүнең юлларыны сорашты.

Карт абыстай ялгыз хатын булганга, әллә нинди хәйләләр уйлап тормаенча, мәрхүм карт хәзрәтнең ихласлы мужикларыннан Шәрифулла абзыйны Хәйдәр мулла берлә тугрыдан-тугры сөйләргә үк кушты.

Матур Гөлчәһрәнең анасы, кызының матурлыгы, зифалыгы берлә алдырыр өчен, кич берлә ястүдән соң авыруга салынып, мулланы «ясин» укырга чакырырга җибәрде. Кызына киенеп-ясанып «яңгылыш кына» муллага күренергә кушты.

Хәйдәр шул хатыннарның авы эчендә аптырап калды. Ахырдан, уйлап-уйлап, байлыктан артык нәрсә юк, дип, Сорурны соратырга карар бирде. Шул хәбәр

теге кызларның әллә никадәр ачуларыны китерсә дә, аларның аналарының тирес кул берлә мулланы, Сорурны каргавына сәбәп булса да, кыз килешелде. Шул тартышуда җиңүе өчен Сорур бөтен авылның гына түгел, тирә-якның каһарманы булды. Бөтен кызлар, хатыннар аны сөйләгәндә: «Менә бәхетле!» — дип әйтүдән авызларын тыя алмады.

Туй җитте. Кияүгә чыккан иптәш кызларыннан бикәч булу хакында әллә никадәр хикәяләр ишеткән Сорур бөтен җаны-тәне берлә шул көнне көтә башлады. Санаулы көн үтте. Дүшәнбе көн никях укылды; җомгадан соң кияү керергә булды.

***

Сорурны күргәч тә Хәйдәрнең әллә нәрсәгә каушавы, аның кулларының гына түгел, хәтта бөтен тәненең калтыравы Сорурда начар хис уятса да, сөйләп киткәч, шундук онытты. Ләкин тагы: Сорурның янына килеп утыруы берлә Хәйдәрнең күзләренең калайланып китүе, тәненең тагы калтыравы Сорурның күңеленә шөбһә төшерде. Авылдагы бөтен хәбәрләр сөйләнеп китеп, шул туйның ваклыкларына кадәр тикшерелгәндә, Хәйдәргә кияүгә чыгарга теләгән авыл кызларыннан көлгәндә, Хәйдәр тагы ачык, кәефле күренсә дә, Сорур чәй урыны җыя башлагач, аны янына тартып утырту белән, тагы калтырарга, дерелдәргә тотынды. Шуннан бер минут үтәр-үтмәс Хәйдәрнең кыйнап ыргыткан кеше кеби хәлсез калуы Сорурның куркуыны арттырды. Ул, Хәйдәр хаста түгелме-фәләнме, дип шикләнә башлады. Үз эченнән, теге, иптәш кызлары сөйләгән кызыклар, рәхәтләрне көтәргә тотынды.

Ут сүнде. Урынга ятылды. Сорур беренче мәртәбә Хәйдәрне кочакларга өлгермәде, аны тагы бизгәк тота башлады. Сорур куркып:

— Син нишлисең? — дигәнгә, Хәйдәр:

— Бернәрсә юк, — дип җавап бирсә дә, әллә нәрсә, бик тиз изрәп китте.

Сорур чынлап сөешергә өлгерә алмады, ул өч көн бер буйдан әвен суккан кеше кеби йокыга китте. Сорур элгәре уйнап-шаярып уятса да, Хәйдәр уянгач та тагы бизгәк тотудан бүтәнгә ярамаганга, ул аны үз ихтыярына ташлады.

Хәйдәр мышнап-мышнап йоклаганда, Сорур үзенең хәлене төшенә башлады. Аңар моның бикәч булуы, теге иптәш кызлары сөйләгәнчә, кызык, рәхәт булмавы, Хәйдәрнең әллә нинди бизгәкле булуы чыннан да эчене пошырды. Иртә торгач та Хәйдәрнең, моның янына килә башлагач та яисә бер-беренә кулы тигәч тә күзләре калайлануы, аннан соң телене салындырып читкә китеп утыруы эшнең тикмә-тиген түгеллегенә ышандырды. Ул иртә берлә түшәк җәюче җиңгәсенә эшне сөйләде. Җиңгәсе анасына, анасы атасына серне ачты. Башка кызларны җиңүнең шатлыгы бик тиз кәефсезлеккә әверелде. Кызның атасы да, анасы да, боздылар, дип им-томга тотындылар — түбән оч Маһруй абыстай Хәйдәрнең ирлеге куәтләнсен өчен ат дагасыны чайкап эчерде; күрше чуаш авылыннан китерелгән чуаш карчыгының даруы да шурпага салынып Хәйдәргә бирелде; кырык чакрымдагы Ишми хәзрәткә дә ат атландырып өшкертергә җибәрелде. Ләкин Хәйдәр ирләнә алмады. Сорур янына килгәч тә күзләре калайланып, аягы-кулы калтырап, бизгәк тотудан үтә алмады.

Сорур үзенең хәле ничек икәнлегене тәмам аңлады. Хәйдәр шул көенчә калса, гомер буе ирле кыз булып торачагыны сизенде. Ул, элгәре акыртын гына булса да, бара-тора Хәйдәрне таларга тотынды. Хәйдәр, гаеп үзендә икәнене белгәнгә, бер сүз дәшмәенчә, башыны иеп торудан башка эш эшли алмады. Шул начар хәбәр авылга чыгып, Сорур теге тиңдәшләре арасында көлкегә калмас өчен, аерылу фикере, әлбәттә, йөртелмәде. Бөтен кардәш-кабилә ничек булса да Хәйдәрне терелтү ягыны куәтләде. Шуның өчен, өшкерү-төкерүдән бер мәгънә дә чыкмаганга, Хәйдәр күрше шәһәргә докторга да җибәрелде.

Доктордан Хәйдәр, авыруның сәбәбе — мәдрәсәдә вакытта кул берлә күп маташу икәнене белүдән башка, бер файдалы нәрсә алып кайта алмады. Аның биргән дарулары, кушкан эшләре, һичберсе аның шул вакытсыз бизгәгене куа алмады; аның ямьсез калтыравымы, күзенең калайлануыны бетерә алмады.

Сорурның аталары алдында бөтен мәсьәлә ачылды. Шул бәладән котылыр өчен аерып алудан башка юл юклыгы тәмам беленде. Ләкин шулкадәр мәшәкать берлә бирелгән, шулкадәр расход берлә туй иткән җирдән ничек итеп аерып алырга кирәк? Аннан ары, шулкадәр зур тартышу берлә алынган остазбикәлек урыныннан ничек аерылырга кирәк? Хосусән, шул остазбикә булып ашка йөрүне әллә ничә еллар уйлаган, әллә никадәр көткән Сорур ничек кулыннан ычкындырсын? Ничек шул дошманнарга үзенең урыныны бирсен? Әлбәттә, бирми. Тагы өмет бетмәгән әле. Хәйдәр бервакыт, әлбәттә, терелер, әлбәттә, авыл ашы, авыл һавасы берлә мәдрәсәдәге авыруы бетеп, ул да кеше булыр.

Шул уйлар берлә, Хәйдәрнең шул кимчелеге дөньяга чыгарылмаенча гына, Сорур Хәйдәрнең йортына төште. Ул, төннәрне Хәйдәрне эт итеп, эттән алып селкеп салып тиргәсә дә, мәҗлесләрдә кеше алдында һичбер серене белгертмәде. Эченнән шул дошманнарны көлдермәс өчен, шул остазбикә булып ашка йөрүне кулыннан ычкындырмас өчен кыз-остазбикә булып та торырга разый булды.

Бер ел үтте. Хәйдәр йортлар эшләтеп бетерде. Мәхәллә зур булганга, байлар күп булганга, тагы Сорурның атасы да караганга, бер елда Хәйдәр берлә Сорурның йортлары-җирләре тәмам байларча булды: сыерыннан сыеры, атыннан аты булды; тавык-кош, сарык-кәҗә берлә йорт тулды. Ләкин байый барган саен, тормыш киңәя килгән саен Сорурның күңеленең боеклыгы артты. Бетмәгән ашлар, мәҗлесләргә йөреп рәхәтләнгән саен тормышының иң кирәкле жире тулы түгеллеге үсте. Кыз булып гомерене үткәрү, тормышның шул рәхәтене татымаенча калу уе аны ташламады. Ул көнене-төнене шул уй астында изелде, ләкин шул бәладән котылырга юл таба алмады, тормышының шул тулмаган ягыны тутырырга җай була алмады.

***

Хәйдәр хәзрәт баеганнан баеды, йорт киңәйгәннән киңәйде, ат-сыер күбәйгәннән күбәйде. Әүвәлге еллардагы кеби, малай-шалай берлә йортыны карап булмый башлады. Хәзрәткә сукасыны сукаларлык, көлтәсене кертерлек, мал-туарны карарлык хезмәтче ялларга тиешләнде. Атлар, сыерлар берлә үзе дә йөдәп чыкканга, бераз тынар өчен, бу ел гына солдаттан калган Зарифны хәзрәт яллыкка яллады. Йорт-җир җыелып китте. Ындыр кеше төсене алды. Келәтнең бөтен почмагында тузылып ята торган оннар, ашлыклар җыелды. Хәзрәт тынычланып китте. Элгәрерәк зур кеше берлә сөйләү уңайсызрак төсле тоелса да, бара-тора абыстай да ияләште.

Абыстай берлә мулла абзый аштан кайтмады. Зариф йорттан китмәде. Аның йорт җанлылыгы, ашлыкны исраф итмәве, мал-туарны каравы өчен хәзрәт аны чынлап яратты. Куйганны көтеп тормаенча, кирәк вакытта үзе самавыр куюы өчен, ашыйсы килгәндә, абыстайны көтеп тормаенча, үзе аш пешерүе өчен абыстай да аңардан бик разый булды.

Тормыш иске хәлене алды, абыстайның башыннан теге уй китмәсә дә, Зарифның керүе берлә ул уй, алга таба да, артка таба да селкенмәенчә, һаман урынында калды.

Менә бер төнне Хәйдәр хәзрәтнең бизгәгеннән, калтыравыннан соң абыстай теге өйгә комган алырга чыкты. Күңеленнән Хәйдәргә әллә никадәр ләгънәтләр укып, аңар әллә никадәр дошманлык биләп, аш өенең ишеген ачты. Бастырып кына

куйган лампа яктысында аның күзе сәкегә сузылып яткан Зарифка төште. Өстенә ябылган бишмәтенең чабуыннан чыгып тора торган аның юан таза кулыннан, яңа гына мыек бөркеп килә торган аның тулы, ирлеге күренеп тора торган йөзеннән күзене ала алмады. Ул, әллә кайчан казан өстеннән комганны алган булса да, баскан җирендә каткан кеби калды. Аның күңеленә кылт итеп менә шул Зариф берлә теге мәсьәләне бетерү фикере килеп басты. Аның күңелендә әллә нинди уйлар йөри башлады. Күңеленең бер кырые: «Менә хәзер Зариф уянса иде, мин азрак елмаеп аңар аңлатыр идем», — дип аның уянуыны тели башлады. Икенче бер кырые: «Юк, юк. Харап булыр хәлем юк. Бөтен авылга чыгар, тизрәк чыгыйм», — дия башлады. Ләкин Сорур һаман урыныннан кузгалмады; тыныны эченнән генә алып, баскан җиреннән үтә алмады. Менә актыккы тараф җиңгән кеби булды, ул алга таба атлады. Ишеккә килеп җитте. Ләкин ишекне ачканда тагы бер мәртәбә Зарифка караудан күзене ала алмады. Җылы түшәгенә кереп яткач та шул уй аның башыннан китмәде. Иртә берлә торып, тәһарәт алып намаз укыганда да шул уйдан котыла алмады. Ул иртә берлә Зарифны күргәндә, аның берлә күзгә-күз очрашканда да әллә нигә кызарды. Зариф аның күңелендәге уены сизә кеби булганга, аның берлә сөйләшә башлагач та, аның бөтен йөзенә кызыл комач ябылды. Сорур һаман үзене тыеп торырга карар бирсә дә, хәзер Зарифка мөнәсәбәте башкарды: шул көнне үк аның иртәнге чәенә анасы китергән ак күмәчне бик зур кисәк чыгарды. Ашны да бу көн тәмлерәк иттереп бирде. Сөйләгәндә дә бик кычкырмый, бакырмый башлады. Ләкин кич кергәч, янында шул эшкә ярамаган Хәйдәрне күргәч, аның бөтен уе үзгәрде. Аның йөрәге кайнарга тотынды. Аның бөтен җаны-тәне шул уйдан үтә алмады. Әллә ничә еллар җыелып яткан шул хис аның башка уйларыны, кешедән куркуларыны — һәммәсене каплады, тәмамлады. Аның бөтен тәне берьюлы шул эшне тизрәк булдырыр өчен ашыккан кеби, һәр әгъзасы аерым-аерым да шул фикергә батты. Аның күкрәкләренең уыласы, билләренең кысыласы, иреннәренең үбеләсе килде.

Ул шуларга каршы чыдый алмады. Акыртын гына торып, бүлмәгә таба чыкты. Шул хисләрнең куәте тагы көчәйде. Кайнаган самавыр эчендәге бу куәте самавырны биеткән, сикерткән кеби шул хисләрнең дә кайнавы аны теге өйгә таба, теге сузылып яткан Зарифлы өйгә таба этә, төртә башлады. Ул ишеккә килеп җитте. Ишек тоткасына тотыну берлә аның күз алдына үзенең мулла хатыны булуының дәрәҗәсе, ашка йөрүләре, шул хәбәрнең авылга чыгып, иceме-җае китүе килеп басты. Дошманны күргәч, бөтен көчене җыеп, аңар ташлана торган гаскәр кеби, теге хисләр, теге сөясе килүләр тагы куәтлерәк иттереп аны биләде. Шул ике хис арасында сугыш башланды. Әүвәлгесене җиңеп беткәндә: «Зариф кабул итмәсә?» — дигән уй аның күңеленә килеп төште. Шуның артыннан әллә никадәр куәт берлә хурлану хисе аны каплап алды. Ул үзене Зариф куып чыгарган иттереп күргән кеби булды. Аның йөрәк кайнавы шул салкын уй берлә бераз басылды. Ул, сугыштан чыккан кеше кеби арып, урынына барып ятты. Бик озак уйлаганның соңында, чыкмавы яхшы булдымы, начар булдымыны уйлап очына чыга алмаганның соңында, ул йокыга китте.

Иртәгесен, көндез: «Бүген ни булса булсын, чыгам!» — дип утыртып куйса да, ул көнне дә чыга алмады. Көннәр үтте, атналар үтте. Сорур шул уй берлән изелсә дә, шул уйдан котыла алмаса да, кыз-остазбикәлектән дә һаман чыга алмады.

Менә бер төнне сәгать берләрдә Зариф ишекне кагып:

— Абыстай, сыер бозаулады! — диде.

Сорур, торып киенеп, имчәге шешмәсен өчен сыерны савып алырга чыкты. Бозауны караганда, сыерны керткәндә Сорурның күңеленнән теге уй чыкмаса да, ул шуны булдырыр өчен бер адым да атламады.

Ф.Муллахмәт рәсеме

Менә сыерны савып бетереп, Зарифка чыгарырга кушты. Үзе бармагы берлә авызыны ачып, бозауга угыз эчерде. Зариф кереп бозауны мунчаклагач, эшне бетереп чыгар өчен, урындыкка басып угызны шүрлеккә куярга булды. Ул чүлмәкне рәтләп ябып өлгермәде, аяк астындагы урындык таеп китеп, ул бөтен көче берлә сәкегә таба егылды. Шуны күрү берлә Зариф, кулларыны җәеп, сәкегә төшермәс өчен, абыстайны тотты. Бөтен тәненең куәте берлә Сорур Зарифның кулына егылды. Зарифның бер кулы аның күкрәге тугрысына туры килде, икенче кулы аның билене чолгап алды. Сорур ни булганыны уйлап бетерә алмады, Зарифның кулы тию берлә аның теге, баягы хисләре аны бөтенләй биләп алды. Ул, күз ачып йомганчы, Зарифның муеныннан кочаклап алып, Зарифның тулы йөзләреннән үбәргә тотынды. Уйланмаган бу эшкә Зариф элгәре исе китсә дә, уйлап торырга вакыт юкка, шул хисләр аны да биләп алганга, ул да җавапсыз калмады.

Кияүгә чыгуының дүртенче елында Сорур беренче мәртәбә бикәч булды, беренче мәртәбә теге кияүгә чыккан иптәш кызлары сөйли торган кызыклар, рәхәтләрне татыды. Теге уй аны хәзер йөдәтми башлады. Ул ачылды. Хәйдәргә дә йомшаграк кылына башлады, хатыннар берлә дә пәриләшеп орышышуыны киметте.

***

Шул вакыйгадан соң Сорур һәр көнне кич берлән аш өенә чыга, һәр көнне Зарифның каты ястыгыны бүлешә башлады.

Хәйдәр кичнең башында һәр көнне берәр калтырап, бизгәк тотып авырып алганга, Сорурның озын-озын югалуыны бик озакка кадәр сизмәде. Ләкин беркөнне, әллә нәрсәгә уянып китеп, Сорурны янында тапмагач, шөбһәләнде. Бераздан соң Сорур керсә дә, ул:

— Кайда идең? — дип сорады. Сорур ачуланган тавыш берлә:

— Кайда идем? Тышта идем! — диде. Үзе, килеп яткач, әллә нәрсәне уйлап бетергән кеби: — Әллә монда синең калтыравыңны саклап торырлар дип белдеңме? — диде.

Шул «синең калтыравыңны саклап торырлар дип белдеңме!» сүзе Хәйдәрнең күзене ачты. Ул, Сорурның шул сүзенең мәгънәсене тәмам аңлап, Зариф берлә Сорур арасында ни булганыны үз күзе берлә күргән кеби булды. Шул уй аны бөтенләй биләде. Ул үзенең шул хәленең ямьсезлеге уена батты. Үзенең хатынының, моның яныннан чыгып китеп, хезмәтчесе берлә йоклап керүенә әллә никадәр хурланды. Сорурны тиргәмәкче, орышмакчы, кыйнамакчы булды. Ләкин үзенең гаеплелеге аны тагы ул уйдан кайтарды. Ул аерып җибәрмәкче булды. Ләкин тагы берне алса да шулай булачак түгелме? Моңар, ичмасам, ияләште. Ул, төн буе керфегене керфеккә тидермәенчә шуны уйлап үткәрсә дә, шул уйның очына чыга алмады.

Иртәгесен Сорурның моның алдында бер дә гаепле төсле кыйланмавы Хәйдәрне: «Бәлки, бернәрсә дә юктыр, мин генә шөбһәләнә торганмын», — дидерсә дә, аштан кайткач та Сорурның Зариф өенә чыгып бик озак торуы аны тагы ышандырды. Ул ни эшләргә белмәенчә, радикальныйрак бер эш эшләр өчен вакыт көтәргә карар бирде. Ләкин бу карары да үзене алдау гына булганга, вакыт үткән саен Зариф берлә Сорурның мөнәсәбәте ныгаюдан башка бер мәгънә чыкмады.

Озак үтмәде, Сорур корсакка да калды. Бу хәбәрне белү берлә Хәйдәр: «Юк инде, бусы булмас!» — дип бик кызуланып караса да, артыны-алдыны уйлагач, моның берлә дә килешергә мәҗбүр булды.

Никяхның бишенче елында Сорур остазбикәдән, Алла биреп, бер угыл да туды. Шул эшкә исе киткән аналарына:

— Ник минем балам булмасын, минем ирем юкмыни?.. — дип җавап биреп котылса да, авыл хатыннарының сүзләреннән котыла алмады.

Бөтен авыл Зариф берлә Сорур гайбәтене сатарга тотынды. Хәйдәргә бу сүзләр, бу хәбәрләр никадәр авыр булса да, баш иеп: «Кабул иттем», — дип торудан башка юл юкка, ул ишетмәгәнгә, белмәгәнгә салынды. Йорт эшене бозмас өчен Хәйдәр хәзрәт Зарифны бер елга гына түгел, өч елга ялларга да мәҗбүр булды. Ул гына да җитмәде, Сорур Зариф өчен өченче өй дә салдыртты; йорт эшләре күбәйде, дип, Зарифка иптәш иттереп бер малай да алдыртты. Хәзер Зариф җомгаларга, гаетләргә Хәйдәр хәзрәтнең иске читегеннән, калошыннан, җиләненнән йөри башлады.

Садыйк байларның да Зарифка мөнәсәбәте бара-тора башкарды. Әүвәлрәк, өмә-фәлән булганда, өмәчеләр арасына гына ашка чакырдылар; бераздан зуррак мәҗлесләрдә икенче табынга да чакыргаладылар. Бара-тора һәр җомга көнне иртә берлә, Сорур остазбикә берлә Хәйдәр хәзрәт артка утырып, Зариф алга — ат башына утырып, Садыйк абзыйларга барулары гадәт хөкеменә керде.

Зарифның куәте, көче берлә мәхәллә халкының да килешми хәле булмады. Мәхәллә халкының да элгәре тирә-күршесе муллалар мәҗлесенә Зарифны күрше итеп кенә чакырса да, авылда Сорур остазбикәнең роле зурайган саен, аның аяк баскан җире ныгайды. Никяхларның низагсыз укылуы, туйның матур үтүе Хәйдәр хәзрәтнең кулында булганга, ул Сорур остазбикәнең ихтыярында булганга, Зарифның күңелене калдырырга остазбикә бер дә разый булмаганга, мужиклар, теләр-теләмәс булса да, Зарифны туйдан калдырмаска мәҗбүр булдылар. Бара-тора шул куркынычлар булмаса да, бөтен мәхәллә халкы, муллаларның артына утырып Зарифның мәҗлескә йөрүенә өйрәнеп беткәнгә, үзләреннән-үзләре дә чакыра башладылар.

Зарифның шул роле аны да тәмам үзгәртте. Ул хәзер хезмәтчелектән генә түгел, мужиклыктан чыга язды. Дөресте генә, ул, әллә нинди мәдрәсәдә укып мулла була алмый калган кеше кеби, ярты мужик, ярты мулла булып китте. Шундый кешегә мәчеткә йөрмәү тугры килмәгәнгә, ул, йорт карауны һаман ташламаса да, өч-дүрт намазга керә башлады. Җеназа-фәлән эшләрдән бер дә калмый башлады.

Шулай итеп, Зариф хезмәтчедән ярты муллага күчкәндә, Сорур остазбикә үзенең кыз-остазбикә булып тору мәсьәләсене очлап барганда, Хәйдәр хәзрәт тә табышсыз калмады: Сорур остазбикә, элгәреге бушка үткәргән гомерләренең казасыны кылган кеби, һәр елны берсе артлы берсе матур балалар тудырып, хәзрәткә мәхдүм, мәхдүмәләрне багышлый бирде. Дүрт-биш елдан соң шул матур җанлы балалар безнең шул иттифак мөсәлләсенең тормышыны бизәкли башладыклары кеби, ун-унбиш ел үткәч, шуларның ирләре, мирас тарикынча, аталарының михрабыны биләргә, кызлары аналарының остазбикәлек дәрәҗәсене алырга хәзерләнә башладылар. Зариф, Сорур, Хәйдәр хәзрәтнең тормыш мәсьәләләре күбәйде, зурайды. Шул мәсьәләләр, бергә үткәргән, артта калган үткән гомерләр аларны тагы бер-берсенә ныграк бәйләде. Аларның һәммәсе дә икешәр-икешәр генә тормышны уйлый да алмау дәрәҗәсенә килде.

Ике ирле остазбикә тазарганнан-тазарды; мужиклыктан мулла сыманлыкка таба зур адым атлаган Зариф вәкарьләнгәннән-вәкарьләнде; Хәйдәр хәзрәт тә өй эшләреннән дә, җәмәгать мәсьәләләреннән дә тыныч булганга, бер яктан, мәхәллә өстенә ятып китте, икенче яктан, тарикатькә кереп, зикре тәһлил берлә тормышының тулмаган тарафларыны тутырды. Мәхдүмнәр үсеп мәдрәсәгә китте; мәхдүмәләр, үсеп җитеп, остазбикәлеккә әзерләнеп җитте.

Бер хатынга ике ир, бер балага ике ата багышлаган тормышка бер кияүгә ике баба, бер кодага ике кода багышларга гына калды.

1910

«Гөлбакча»лы әтием

Ләйсән Кариева

(Шагыйрь, мөгаллим һәм фронтовик Әнәс Кариның тормыш юлы һәм иҗатына бер караш)

Әнәс Кари һәм хатыны Рәшидә Кариева, уртада балалары Ләйсән һәм Алмаз. Арча районы, Яңа Кырлай авылы. 1953 ел

Шагыйрь Әнәс Кари кыска гына 34 еллык гомерендә татар шигърияте тарихында үз йөзен, урынын таба алды һәм, язган әсәрләре белән халыкка тиешле сүзен әйтеп, танылып өлгерде. Аның мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына багышлап язылган «Балаларга бүләк», «Гөлбакча», «Күңелле ел», «Дуслык», «Тамчы тамганда», «Хуш килдегез, кошлар» исемле җыентыклары укучылар соравы буенча кабат-кабат басылды. Әмма әдәбият белгечләре Ә.Кариның иҗаты хакында матбугатта аз язды. Аның зур проблемалар күтәргән «Хаклы җырлар», «Сыналган мәхәббәт» поэмалары кебек күләмле әсәрләре, өлкәннәр өчен язылган лирик һәм сатирик шигырьләре хакында әдәби тәнкыйть тарафыннан җитди сүз әйтелмәде.

Әтием 1920 елның 11 июнендә Азнакай районының Уразай авылында туа. Берничә буын бабам мулла булган, Урта Азиядә гыйлем алган. Әтием дә шәрыкнең мәшһүр акыл ияләре, шагыйрьләренең әсәрләрен балачактан укып үскән. Әти-әнисе, абыйлары Әбрар, Мидхәт һәм Әхәт, сеңлесе Мәдинә белән бергә мөнәҗәтләр, борынгы татар җырларын башкарырга яраткан. Үзе дә, илһамланып, шигырь яза башлаган, кайчагында рәсем ясау белән дә мавыккан. 1935 елдан район, республика газеталары һәм «Пионер каләме» журналыннан башлап, «Совет әдәбияты»на кадәр аның беренче иҗат тәҗрибәләрен теләп басалар. Тик тормышта барысы да шома гына бармый. 1930 еллардагы хуҗалыкларны

күмәкләштерү сәясәте җайга салынган тормышны җимерә. Гаиләне «кулак» дип игълан итәләр, зур йортны, мал-туарны тартып алалар, бабамны сөргенгә җибәрәләр.

Әтинең дә Казанда югары белем алу мөмкинлеге чикләнә. Урта белем алу белән 1936 елда туганнары янына — Үзбәкстан ССРның Үргәнеч каласына урнаша, укытучылар институтына укырга керә. 1939 елда аны «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. 1941 елга чаклы ул шул институтта үзбәкләргә үзбәк әдәбияты укыта. Бай китапханәләрдә шәрык китапларын, төрки-татар тарихына караган борынгы кулъязмаларны өйрәнә.

Шәрык дөньясы белән танышу, педагогик белем алу, укытучы һәм тәрбияче булу шагыйрьнең иҗат кыйбласына зур йогынты ясый. 1941 елда язылган «Хаклы җырлар» поэмасында XV гасырда яшәп иҗат иткән шагыйрь, гуманист, дәүләт һәм җәмгать эшлеклесе Галишер Нәвои образы аша тоталитар системаның чын йөзе ачыла. Әгәр дә әсәргә салынган асыл мәгънәгә мөхәррир һәм цензорлар үз заманында төшенсәләр, шөбһә юк, әтинең бу поэмасын басмаган булырлар иде.

Сарай әһелләре Нәвоиның гаделлек нигезендә илне сәяси үзгәртеп кору турындагы алдынгы фикерен кабул итми һәм аны Астрабад төбәгенә идарәче



Әнәс Кариның автопортреты. Үргәнеч. 1937 ел

Әнисе Зәйнәп Габделгани кызы. Әнәс Кари рәсеме. Үргәнеч. 1937 ел

«Чәй короле» Габдрахман Ишморатовның Арча районы Лесхоз бистәсендә салган дача йортын Кариевлар гаиләсе өчен фатир итеп биргәннәр. Әнәс Кари рәсеме. 1946 ел

Әнәс Кари хатыны Рәшидә, кызы Ләйсән һәм улы Алмаз белән Яңа Кырлайда. 1951 ел

итеп сөрәләр. «Хаклы җырлар» поэмасында да шул вакыйга тасвир ителә. Әтием урта гасыр гуманисты образы аша эзоп теле белән тормышта үзе кичергәннәрне кинаяләп сөйләп биргән. Совет илендә узган гасырның 30-50 нче елларында күпләрнең язмышы кыл өстендә торган, аларның иҗатта кинаядән башка әмәле булмаган. Шуның өчен дә 21 яшьлек Әнәс Кари башбаштак хөкемдар Сталин идарә иткән чорга үзенең бәясен кинаяләп бирә.

Кушталанып, илне алдың кулыңа,
Ләкин кердең хаксыз
золым юлына.
Пәрдәң җепләре дә илнең җаныннан,
Буяулары исә халык каныннан...

Поэманың төп каһарманы Галишер Нәвои гадел ил турында хыялланган.

Һәм ул уйлый харәбәгә калган
Зур Хорасан иле урынында,
Фәрһад гизгән гүзәл сихри ил күк
Гөлбакча ил төзү турында...

Борынгы шәрык шагыйрьләреннән үк килгән гадел җәмгыять турындагы хыял, төрки-ислам әдәбиятындагы социаль утопия — гүзәл гөлбакча образы Әнәс Карига иҗади дәрт биреп торган. «Гөлләр иле», «Гөлстан», «Гөлбакча» төшенчәләре, борынгы шәрык әдәбияты классиклары Сәгъди, Сараи, Низами, Фирдәүсиләр хыялланган гадел җәмгыять әтием иҗатында да төп проблема булып кала. Белгәнегезчә, балалар өчен язылган шигырь җыентыкларының да берсе «Гөлбакча» дип атала.

Әнәс Кари 1942 елда рядовой солдат булып фронтка китә. Орёл юнәлешендәге сугышларда каты яралана, яңадан укытучылык эшенә тотына, Үргәнеч педагогия институтында укыта башлый, әдәби иҗатын дәвам итә. Аның сугыш кырында күргән-кичергәннәре «Сыналган мәхәббәт» поэмасында тасвирлана. Төрки халыкларның эпос, дастан традицияләреннән килгән сюжетка нигезләнгән әлеге әсәрдә, иле өчен утка кергән совет сугышчысының батырлыгы, авыр яралануы тасвирлана. Поэма сюжеты аша ил башлары — Ашиннар нәселе турындагы легенда җанлана кебек. Борынгы риваятьтә, дошманнар һөҗүменнән соң җир йөзеннән кырылып бетү алдында калган төрки кабиләнең, металлдан корал эшләп, мәгарәләрдә ишәеп, яңадан дошманнарын җиңүе тасвирланган. Әсәрнең төп каһарманы да, борынгы легендага ишарәләп, Тимер исемен йөртә. Поэмада Тимернең, төрки батыр кебек үк символик гарипләнүе: бер аяксыз, кулсыз калып, күзләре сукыраюы тасвирлана. Шулай булуга да кара-

Әнәс Кари (икенче рәттә, сулдан дүртенче) Арча педагогия училищесы укучылары белән. 1945 ел

мастан, Ашин ыруы батырының рухы көчле булып, нәселен калдырган кебек, Тимер дә үлемне җиңә. Төркиләр мондый батырларның сыннарын йозак рәвешле итеп ясый торган булалар. Музейларда аларны «Маклашеев җайдаклары» дип йөртәләр. Шул рәвешле, поэмада борынгы төрки һәм Бөек Ватан сугышы батырлары янәшә тасвирлана. Мондый әдәби табышмакның җеп очын әти зирәк әдәбият белгечләренә калдырган, күрәсең.

Автор, дастан традицияләренә тугры булып, бөек саф мәхәббәткә дан җырлый. Әсәрдә мәхәббәт тормыш куйган сынауларны да җиңә, дөньядагы бар явызлык ваклана, төсен югалта. Авыру-сызланулар бөек мәхәббәт каршында артка чигенә. «Сыналган мәхәббәт» поэмасы борынгы дастан каһарманнары хакында сөйләп биргән кебек, шагыйрьнең замандашлары характеры да Совет иле шартларында ачыла. Тимер белән Сылу, миллионлаган яшьләр кебек, урта мәктәптә укый, имтиханнар бирә, бәхеткә шатланып яшиләр.

Эш һәм уку кочагында алар
Берсен-берсе шундый сөйделәр, —
Дастаннарда җырланмасалар да,
Җырланырга лаек иделәр.

Поэмада турыдан-туры әйтелмәсә дә, Ашин нәселе кебек, татар халкы да сугыштан соң яңадан күтәрелеш кичерде. Бу тоталитар режим куркытуларына нигезләнгән тормышка яраклашу түгел, ә бәлки мәхәббәткә нигезләнгән, намус иркендәге юлны, авыр һәм кыен сукмакны сайлау иде. Сугышта гарипләнгән егетне кыз үзенә кабул итә, аны тормыш юлдашы итә. Болары исә күпләгән егет һәм кызның сугыштан соңгы язмышы иде. Поэма зур гомумиләштерү көченә ия. Хәер, мондый авырлыклар, батырлык үрнәкләре, төрки-татарларга гына хас түгел, ә бәлки кешелекнең борынгы заманнан бирле килгән тормыш кануны.

Сугыштан соң Татарстан ВКП(б) өлкә комитеты төрле төбәкләргә таралган белгечләрне махсус җыйганда, 1945 елда әтине һәм аның бертуган абыйсы, югары белемле математика укытучысы Әхәт Кариевны юллама белән Арча педагогия училищесына җибәрә. Әтием монда да зыялы җирлеккә тап була, коллектив сәләтле педагоглардан тора. Әтием училищеда әдәби түгәрәк оештырып җибәрә. 1946 елда бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 60 ел тулу уңаеннан Кырлай һәм якынтирә авылларда үз укучылары белән әдәби кичәләр уздыра. Ач яшьләрне ашату өчен колхозлардан азмы-күпме азык-төлек юнәтә. Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек җырга-моңга сәләтлеләргә аеруча игътибарлы була.

Бу елларда әтием тоталитар режимның эзәрлекләвенә янә дучар була. Мөхәммәт Мәһдиев «Ачы тәҗрибә» китабында: *«Без «Кыскача курс»тан имтихан биргәндә училище өстендә «халыклар атасы»ның кылычы нык уйнап алды. Училищега очраклы килеп эләккән тупас, тәрбиясез бер укытучы, НКВД органнарына донос җибәргән, дигән хәбәр таралды. Җәй эчендә өч ирне юк иттеләр. Бу бит инде 1947 нче елның җәе. Тыныч тормыш җәе. Кемнәрне алдылар соң? Педагогика укытучысы, чын зыялы остаз, керәшен Константин Афанасьевич Ибаевны. Имеш, элек кадет булган. Рус теле, әдәбияты укытучысы, карт журналист, тәнкыйтьче, дәреслекләр авторы Хәлим Фәттәхович Искәндәревне. Имеш, мулла малае икән, Галимҗан Ибраһимов белән дус булган. Физика укытучысы, фронтта утны-суны кичкән Әхәт Кариевны. Монысы шагыйрь Әнәс Кариевның абыйсы, Әнәс Кариев исә безгә татар әдәбияты укыта иде. Әхәт абый, имеш, әсирлектә булган».* Шулай итеп, «халык дошманы»ның туганы булган әтине дә Теләче (хәзер Питрәч) районы Янсуар авылына җибәрәләр. Әтием монда да балалар һәм авыл яшьләре өчен әдәби-иҗат түгәрәкләре оештыра, сәләтле укучылары белән армый-талмый эшли. Укыту-методик темаларга язган мәкаләләрен республика матбугатында бастыра. Ә җәй айларында Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтындагы курсларга җыелган мөгаллимнәргә лекция укый, Мәскәүдә уздырылган фәнни-практик конференцияләрдә катнаша. Янсуар авылында яшәгәндә хакимият органнары эти-әнигә юк-бар белән бәйләнми. Моның сәбәбе — әтинең фронтташ дусты Эчке эшләр бүлегендә эшләве һәм аны еш кына яклап торуында.

Әтием белән әнием Рәшидә җәйге каникулда әниемнең туган авылы Яңа Кырлайга еш кайта иде. Г.Тукайның балалык һәм яшьлек дусты Әһли (Әһлиулла) бабамның шагыйрь турындагы истәлекләре китапларга да кертелгән. Әбием Камилә дә авыру шагыйрь хакында кызыклы истәлекләр сөйләргә ярата иде. «Тукай» романы өчен материал туплап йөрүче Әхмәт Фәйзи дә берничә ай Яңа Кырлайда яшәгән, эти-әнием, әбием белән аралашкан. Республиканың танылган артистлары, рәссамнар, музыкантлар, Кырлайдагы Тукайның замандашлары, шагыйрьләргә илһам бирергә сәләтле авыл халкы — барысы да әтиемнең иҗади тирәлеген тәшкил итте.

Сугыш яралары һәм репрессия борчуларыннан алҗыган әтием 1954 елның 4 апрелендә көтмәгәндә дөнья куя, Саурыш авылында җирләнә.

Әнәс Кариның әдәби мирасы кызыклы һәм күпкырлы. Беренче чиратта, аның поэмалары үзенчәлекле, көчле хисләргә, проблемаларга корылган. Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына багышланган сюжетлы шигырьләре исә хезмәткә мәхәббәт тәрбияли. Бу әсәрләр гадел җәмгыять турындагы идеяләр ярылып ятуы белән отышлы. Яшьләргә багышланган бер төркем лирик шигырьләре тормышны данлап, яшәү матурлыгын мактый. Шәрык поэзиясенә хас булган шигырьләре исә нечкә нәзакәтлелеге, лирик геройның вакытлы гүзәллеккә гашыйк булуы белән һәр укучыны җәлеп итә. Мондый тасвири шигырьләр фарсы, япон яки кытай шагыйрьләренең матурлыкка сoклануын хәтерләтә. Гомумән, Әнәс Кари әсәрләренең һәркайсы әдәбият белгечләренең игътибарына мохтаҗ.

Редакциядән. *Бу елның март аенда «Безнең мирас» журналы редакциясе Азнакай шәһәрендә Әнәс Кариның тууына 95 ел тулу уңаеннан конференция оештырды. Конференциягә тәкъдим ителгән мәкаләләр һәм фоторепортаж белән www.beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.* ■

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ: «ЕГЕТ БУЛЫЙК ӘЛЕ БЕР...»

Әгъзам Фәйзрахманов



Гомеренең соңгы елларында Мөхәммәт ага Мәһдиев миңа шактый еш шылтырата иде. «Кичә синең газетада (журналда) басылган мәкаләңне укып чыктым. Әйбәт проблема күтәргәнсең», – дип башлый иде ул, гадәттә, сүзен. Аннары үзенә хас тыйнаклык белән, мине һич тә үпкәләтмәскә тырышып, өстәп куяр иде: «Карале, якташ, бу теманы киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк. Проблеманы хәл итү юлларын тагын да ачыклый төшкәндә яхшы булыр».

Халык тарафыннан инде танылган язучы булса да, ул бер вакытта да масаймас, иҗаты, ирешкән уңышлары белән мактанмас, әңгәмәдәшен үзе белән бер дәрәҗәдә куеп сөйләшер иде. Мөгаен, бу аның үзенә таләпчәнлегеннән, эчке культурасыннан, тормышның бөтен нечкәлекләрен аңлап эш итүеннән килгәндер.

Безнең Арча төбәгендә башкаларга иң кирәк вакытта ярдәм кулын сузучыны «юньле кеше» диләр. Якыннан белгән, аралашып яшәгән һәркем Мөхәммәт абыйны искә алганда да сүзен «юньле кеше иде», дип башлый. Бу фикерне өлешчә булса да раслау өчен аның тарафыннан имзаланган бер документка күз салыйк. Хәер, «имзаланган» сүзе бу очракта бигүк дөрес тә булмас. Минемчә, әлеге хат гаделлек таләп итеп, әрнеп, чын күңелдән каләмдәше — үзе кебек үк язучының хезмәтенә лаеклы бәя бирү теләгеннән язылган. Миңа ул бу мәктүпне «бәлки, берәр язмаңда куллана алырсың», дип биргән иде. Еллар үтә торды, әлеге хат кәгазьләр арасында ята бирде... Һәм, ниһаять, архивымны актарганда кабат күзгә чалынды. Эчтәлеге бүген дә актуальлеген югалтмаганлыктан, аның белән танышу «Безнең мирас» укучылары өчен кызыклы булыр, дип уйлыйм.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенә ачык хат

6 февральдә булачак идарә утырышында Г.Тукай исемендәге премиягә кандидат күрсәтүгә карата.

1. Мин 1984 ел премиясенә кандидат итеп язучы Ә.Еникине тәкъдим итәм.

2. Башка идарә членнарыннан, әгәр аларның берәрсенең кандидатурасын параллель рәвештә күрсәтсәләр, самоотвод биреп Ә.Еники кандидатурасын ялгыз калдыруларын үтенәм.

3. Бездә үз кандидатурасы күрсәтелгәнче һәм үзе премия алгач Ә.Еникине яклаучы күп булды, әмма «Юк, быел мин баш тартам, Еники кандидатурасын тәкъдим итәм», дип әйтүче булмады. Егет булыйк әле бер.

4. Г.Ахунов иптәшкә: «Горький премиясенә Мәһдиевне тәкъдим итәбез» дигән исем астында идарә утырышына тагын бер комедия куймавыгызны көтеп калам. Идарә утырышларында җитди булырга кирәк, комедиянең урыны — сәхнә.

М.Мәһдиев

Мәскәү, февраль, 1984





Кайтаваз

«Безнең мирас» журналының быелгы 10 нчы санында минем «Муса Җәлилнең «Седльце шигырьләре» дигән мәкаләм басылып чыкты. Анда каһарман-шагыйрьгә нисбәт ителгән алты шигырьнең авторын ачыклау, турыдан-туры аның стиленә карамаса да, аларны Муса Җәлил шигырьләре дип танырга ныклы нигез булуы, шулай да, һәммәсен тел-стиль ягыннан яңача анализларга кирәклеге турында әйтелде.

«Седльце шигырьләре» эзеннән...

Хәнәфи Бәдигый

Шул уңайдан миңа әлеге әсәрләр белән кабат кызыксынырга, эзләнергә туры килде. Нәтиҗәдә өстәмә мәгълүматлар, ачыкланырга тиешле яңа сораулар туды. Башта ук шунысын әйтик: бу мәгълүматлар һәм сораулар да соңгысы булмас, яңалары барлыкка килер. Ә хәзергә билгелеләрен бәян итик.

10 нчы санда басылган мәкалә Гобәйдулла Салиховның 1954 елда үз кулы белән язган тормыш юлын төп версия итеп алып, шундагы фактларга нигезләнеп язылды. Ул 1970 елда юл һәлакәтендә фаҗигале төстә вафат була, шигырьләр һәм истәлекләр 2007 елда Салиховлар яшәгән йортны сүткәндә, чормада күн букчада табыла. Билгеле, әлеге язулар исән чагында табылган булса, бик күп сораулар ачыкланыр иде. Бу язмада без аның сүзләренә генә таянмыйча, башка чыганакларга да мөрәҗәгать итәрбез.

Беренче сорау шуннан гыйбарәт: Муса Җәлил Седльце лагеренда булганмы, юкмы? Әйдәгез, беркадәр артка, тарихка чигеник. Мәгълүм ки, «Идел-Урал» легионын төзү 1942 елның 21 августында башлана. Едлинога якын җирдә урнашкан Седльце лагере әлеге вакыйгаларга кадәр үк әсирлеккә эләккән төрки халыкларны җыю пункты һәм, шул ук вакытта, легионнарның фашизмга каршы яшерен көрәшен оештыру үзәге дә була. Бу үзәкне җитәкләүчеләрнең берсе — Гайнан Кормаш.

1942 елның 6 сентябрендә «Идел-Урал» легионына байрак тапшырыла һәм ул аның төзелгән вакыты булып исәпләнә. Әсир татарлар, нигездә, Седльце лагерена туплана. (Бу турыда алдагы язмада сүз булган иде.) Шуннан аларны өйрәтү-әзерләү өчен башта Едлинога, бераздан Демблинга җибәрәләр.

Седльце лагере оешу вакыты анда Муса Җәлилнең дә булу мөмкинлеген күрсәтә, ягъни, Гобәйдулла Салихов язып калдырган версия чынбарлыкка туры килергә мөмкин. Гәрчә турыдын-туры раслаучы фактлар хәзергә табылмаса да, моны тулаем кире кагарга ярамый.

Шунысын да әйтим: үтә яшерен алым белән рәсми булмаган чыганаклардан алынган мәгълүматларга караганда, авыр яралы Муса Җәлил Седльце лагеренда әсирлектә булган, шигырьләр язган. Ләкин анда аның Гайнан Кормаш яки Абдулла Алишны очратуы турында (ә аларның бередә иза чигүе рәсми чыганакларда теркәлгән) хәбәр юк.

Эш шунда ки, Муса Җәлилгә нисбәт ителгән шигырьләрнең берсе — «Почта юлын һәр көн саен тап-

Рафаэль Мостафин А.Алиш исемендәге Пионерлар сараенда чыгыш ясый. Каһарман-язучының юбилей көннәре. 1983 ел

Муса Җәлил. Казандагы бер йортка төшерелгән сурәт. 2015 ел



Муса Җәлилгә нисбәт ителгән «Дустыма» шигыре

тыйм...» дип башланганы Абдулла Алиш шигыре булып санала! Ул сайланма әсәрләрнең беренче томында, «Әсирлектә иҗат ителгән шигырьләре» бүлегендә урнашкан (анда егерме тугыз шигырь һәм «Очрашу» дигән бер поэма бар), шуларның җиде-сигезен әсирлектән Газыйм Кадыйров исемле кеше алып кайткан. Алай гына да түгел, иң хикмәтлесе шунда: Седльце лагеренда Абдулла Алиш аны,

тагын берничә шигыре белән бергә, Кадыйровка: «Исән калсаң, тиешле кешеләргә тапшырырсың», — дип, үзе күчереп биргән. Әлеге мәгълүматлар Рафаэль Мостафинның «Җәлилчеләр» китабында да бар.

Искә төшерик: шундый ук юллар белән башланган, тик «Дустыма» дип исемләнгән бу шигырьне Гобәйдулла Салихов «1942 елның октябрендә Муса Җәлилдән күчереп алдым» дип яза.

Башваткычны, шахмат уенындагы пат, цейтнотны хәтерләткән бу мәсьәләне ничек чишәргә? «Дөреслек төрле, хакыйкать бер генә» дигән постулат нигезендә җавап нинди булырга тиеш? Монда, ирек куйсаң, фикерләр чуалышып бетәрлек! Әмма бу сорауга дөрес җавап табарга мөмкин.

Моның чишелеше, минемчә, түбәндәгечә.

Авыр яралы Муса Җәлил Седльце лагерена Абдулла Алишка кадәр, алданрак китерелгән. Аның шигырьләрен әсирләр күчереп алган, аларның кайберләре Абдулла Алиш кулына да килеп кергән, күрәсең. Яисә ул аларны ишеткән, әмма кемнеке булуларын белмәгән (чөнки әсирләрнең күбесе шигырь язган), үзе дә шул темага иҗат иткән, ишеткәннәрен яки укыганнарын үзенчә эшкәрткән.

Алишның ул шигыре 10 строфадан тора.

Муса Җәлилгә нисбәт ителгән һәм «Дустыма» дип аталган шигырь җиде строфадан тора. Ул болай башлана:

Почта юлын таптап һәр көн саен
Хатлар көтәм синнән, акыллым.
Аерылышкач авыр, күңел сыкрый,
Кайларда син, җаным, алтыным?

Абдулла Алишта ул бераз башкачарак:

Почта юлын һәр көн саен таптыйм,
Хатлар көтәм синнән, акыллым!
Аерылышу белән йөрәк сыкрый,
Кайда соң син, җаным-алтыным?

Муса Җәлил шигырендә өченче строфа мондый:

Ник югалдың инде, сөйгән дустым,
Тормыш таңы сызылып атканда?
Әткәй-әнкәй, диеп иркә күздән
Улларыбыз күзгә бакканда.

Алишта:

Кайда гына шулай югалдың син,
Ашый алмый ризык-ашыңны?
Канлы окопларның итәгендә
Салдың мәллә газиз башыңны?

Бишенче строфадагы уртаклыкка игътибар итик. Җәлилдә:

Ник кайтмыйсың бүген, сөекле кош,
Мәхәббәтләр әллә сүндеме?
Батыр белән әллә ярсу йөрәк
Тын алудан мәңге бүлдеме?

Алишта:

Син кайтмыйсың, өзелеп сагынсам да,
Мәхәббәтең әллә сүндеме?
Батыр күңел белән ярсу йөрәк
Тын алудан мәңге бүлдеме?

Җәлилнең алтынчы строфасы:

Авылларга кайткан иптәшләрең
Һичберсе сине күрмәгән.
Сугышларда булган чакларыңда
Синең белән бергә йөрмәгән.

Алишта ул икенче строфа:

Яраланып кайтты иптәшләрең,
Тик берсе дә сине күрмәгән.
Ут эчендә булган чакларыңда
Синең белән бергә йөрмәгән.

Алда искә алынган китабында Рафаэль Мостафин болай дип яза: *«Алиш шигырьләре Муса Җәлилнең шул чорда язган шигырьләре белән гаҗәеп дәрәҗәдә аваздаш»*. Ул вакытта, хәзергедәй янәшә куеп чагыштыру мөмкин булмаса да: «Стилистик анализ да ул шигырьнең Алишныкы икәнен раслый», — дип дөрес әйткән.

Моннан шундый нәтиҗә килеп чыга: бу ике шигырь ике шагыйрьне-

ке: ягъни, «Почта юлын һәр көн саен таптыйм...» дип башланганы Абдулла Алишныкы, «Дустыма» дип аталганы — Муса Җәлилнеке. Туган илгә исән-сау әйләнеп кайткан булсалар, бер үк темага уздырышка шигырь язуларын көлә-көлә искә алып сөйләрләр иде, мөгаен. Төрле авторларның бер үк темага багышлап әсәрләр (шигырь, көй һ.б.) иҗат итүе — табигый күренеш.

Шул рәвешчә, Гобәйдулла Салиховның Муса Җәлилдән «Дустыма» шигырен күчереп алуы да, Абдулла Алишның Газыйм Кадыйровка «Почта юлын һәр көн саен таптыйм...» дип башланган шигырен үз кулы белән язып бирүе дә дөреслеккә туры килә.

Мондый охшашлык, уртаклык Муса Җәлилнең «Туган ил сулары» (дүртенче строфа) һәм Абдулла Алишның «Идел буе» (тугызынчы строфа) шигырьләрендә дә күзәтелә.

Җәлилдә беренче строфа:
Саф көмештәй синең су буенда
Балык тотып, уйнап үстем мин.
Тауларыңда кышын чана шудым,
Җәй көннәре синдә йөздем мин.

Алишта:
Идел, синең гүзәл буйларыңда
Үрдәк атып, уйнап үстем мин.
Тауларыңда кышын чана шудым,
Җәй көнендә синдә йөздем мин.

Җәлилдә икенче строфа:
Атка атланып синең кырларыңда
Тырмаладым чәчү кырларын.
Таң атканда сине яңгыратып,
Җырладым мин яшьлек җырларын.

Алишта җиденче строфа:
Атка атланып, синең яр буенда
Тырмаладым чәчү кырларын.
Таң атканда, сине яңгыратып,
Җырладым мин яшьлек җырларын.

Җәлилдә өченче строфа:
Егет булып җиткәч беренче кат
Мәхәббәтне синдә сиздем мин.
Синең суларыңны эчеп үскән
Кара кашлы кызны сөйдем мин.

Алишта сигезенче строфа:
Егет булып, синең яр буеңда
Беренче кат сөю сиздем мин.
Суың эчеп үскән зифа буйлы
Алсу йөзле кызны сөйдем мин.

Җәлилдә дүртенче строфа:
Синең гүзәл, матур тугаеңда
Иркәләнеп атта чаптым мин.
Читкә китсәм, йөрәк чыдамады —
Сине сагынып кире кайттым мин.

Алишта алтынчы строфа:
Карлы кышта, исем туйларында
Сине буйлап атта чаптым мин.
Читкә китсәм, йөрәк чыдамады,
Сине сагынып кире кайттым мин.

Җәлилнең «Седльце шигырьләре»нең калган дүртесендә («Картлык», «Сөйгән дустыма», «Дустым хисе», «Озатып калучы») Абдулла Алиш, җәлилчеләр яисә антифашистлар язган һәм безгә мәгълүм булган шигырьләрендә әлеге ике шигырьдәге кебек охшашлык, аваздашлык юк.

Абдулла Алиш шигырьләре тупланган (үз кулы белән гарәп шрифтында язган) бер дәфтәрнең Язучылар берлегендә юкка чыгуы турында сүз булган иде. Андагы шигырьләр белән охшашлык булу-булмау турында хәзергә сүз йөртеп булмый, билгеле.

Кыскача нәтиҗә ясап әйткәндә, Гобәйдулла Салихов тарафыннан күчереп алынган алты шигырьне, дөрестән дә, Муса Җәлил иҗаты — аның «Седльце шигырьләре» дип әйтә алабыз. Шул ук вакытта, каһарман-шагыйрьнең әлегә билгесез булып кала биргән дәфтәрләрен, шигырьләрен эзләү киләчәктә дә дәвам итәр, дип ышанабыз. ■

Гаярь егет

Альберт Хәсәнов

Фәнис Яруллин якташлары белән. Уңнан беренче – Ринат Галиев. Баулы, 2003 ел

Әдәбиятта да, гадәти тормыштагы кебек, үзеңнең яшьтәшләрең белән кызыксынасың. Кем алар? Кайсы яклардан? Кайсы өлкәдә каләм сыныйлар? 1964 елда китап киштәләрендә моңа кадәр таныш булмаган авторның «Мин тормышны яратам» дигән беренче шигырьләр җыентыгы күренде. Авторы Фәнис Яруллин. Кем? Нинди егет икән? Бу вакытта «Социалистик Татарстан» газетасында минем дә ике-өч хикәям басылды. Аннары «Совет әдәбияты» журналында (хәзерге «Казан утлары», ике санда рәттән «Гомер иткән нигез» һәм «Яшь наратлар» исемле хикәяләрем күренде. Әлеге шигырьләр җыентыгының авторы 1938 елның 7 февралендә туган. Ә мин — 1937 елның 1 декабрендә. Яшь аермабыз ике ай гына, яшьтәшләр дисәк тә була. Шулай җиңел генә танышып киттек. Яңа дустым, коллегам армиядә хезмәт иткәндә турниктан егылып төшеп, билен, умыртка сөяген сындырган. Урын өстендә ята, кузгалырлык та түгел. Фәнискә саз ләме белән дәвалый торган Бәкер курортына путёвка биргәннәр. Күп авыруларга бу курортның файдасы бик тия икән. Яшь шагыйребез дә биредә дәваланып карарга булган. Казаннан Лениногорскига килгәндә Бәкер курорты безнең юл өстендә кала. Ара шактый гына. Фәнис гел ятып килә, юлда арый да торгандыр…

Башта безгә килеп төштеләр. Чәй эчкәч, бераз ял итеп алгач кына Бәкергә юлларын дәвам иттеләр.

Моннан соң да ул Бәкергә күп тапкырлар килде. Без — язучылардан Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов һәм мин — аның янына Бәкергә барып йөрдек. Фәнис чиреннән генә түгел, ялгызлыктан да интегә. Без килсәк, шатлана, сөенә.

Бәкергә килгән саен, аның бастырган китаплары ишәя. Узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында аның «Май төне» (1966), «Бакчалар

бәскә төренә» (1967), «Минем елмаю» (1968), «Ачсаң күңел тәрәзәләрен» (1969), «Алмалар пешкән чакта» (1970), «Аерылмас хуҗалар» (1975), «Яшел утрау хуҗалары» (1976) җыентыклары чыкты.

Авыруы бик җитди булуга карамастан, Баулы районының Кызылъяр егете һәрчак шат күңелле, сөйләменә юмор кушып сөйли. Безне дә шат күңел белән, бик теләп каршы ала, языласы сюжетлары белән уртаклаша.

Бер очрашуыбыз аеруча истә калган. «Татнефть» берләшмәсенең ул чактагы башлыгы Ринат Галиев Фәниснең бер китабын («Яралы язмышлар») татар, рус һәм инглиз телләрендә чыгарды. Бизәлеше искиткеч, Европа дәрәҗәсендә. Ринат Гыймаделислам улы Галиев кебек әдәпле, тыйнак, искиткеч тактлы, кешеләр яратучы җитәкчене минем үз гомеремдә күргәнем булмады. Ул искиткеч гади кеше иде. Аны шулай дип характерларга минем хакым бар төсле. Газетада үз хәбәрче булып эшләү дәверендә мин аның белән, даирәсе белән күп конференцияләрдә, җыелышларда, мәҗлесләрдә булдым.

Фәниснең өч телдә чыккан китабын җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү кичәсен Баулы мәдәният йортында уздырдылар. Кунаклар Әлмәттән, Бөгелмәдән, хәтта Казаннан да бар. «Татнефть» генераль директоры Ринат Галиев тә үзенең унлап «полковнигы» белән килгән.

Очрашу бик күңелле узды. Ринат Гыймаделислам улы Фәнис Яруллинның иҗатын да, аның үзен дә, иптәшләрчә бик ярата иде. Ике арада үзара мөнәсәбәтләре дә соклангыч гади һәм берсен-берсе алар ярты сүздән аңлый иде булса кирәк.

Генераль директор үзе белән ашчыларын да алып килгән. Мәдәният сараеның фойесына кыйммәтле, затлы ризыклардан, бик мулдан мәҗлес оештырдылар.

Табын хуҗасы гади генә итеп һәм баштагы киеренкелекне бетереп:

— Хөрмәтле баулылар! Легендар якташыгыз Фәнис Яруллин сезнең барыгызны да кунак өстәленә чакыра. Күңелле итеп, бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк әле. Рәхим итегез, тартынып тормагыз!» — диде. Барыбыз да кунак өстәле тирәли утырыштык.

Байтак кына утырдык, күңелле гәп кордык. Фәнисне исә озак утырып тору ардыра.

— Егетләр, бераз гына вакытка һавага чыгарга иде, — диде ул. Без аны кулга гына күтәреп, күрше бүлмәгә алып чыктык, диванга салдык.

Фәниснең ахири дусты Марс Шабай да килгән иде. Ул да безнең белән. Гадәтебезчә, әдәбият мәсьәләләре турында сөйләшәбез. Фәнис кинәттән генә Марс Шабайдан тотырып бер стакан «Юбилейная»ны чыгаруын сорады. Без хәтта сагаеп калдык. Юбилярыбыз ике кулын баш өстенә куеп, диванда ятып тора. Бермәлгә каушап калган шагыйрь Шабай да:

— Нәрсәгә ул сиңа?! — диде.

— Сезгә генә рәхәтләнеп кәеф корырга димени? Ә Фәнискә ярамыймы? Минем бит билем, умырткам гына үлгән. Ә монда, күкрәгемдә арыслан йөрәге тибә!

Марс Шабай шунда ук өстәлдән бер стакан «Юбилейная»ны алып килде. Фәнис аны йөзен дә чытмый, тамчысын да калдырмыйча, голт-голт итеп йотып та куйды. Күрсәләр, Иделдә авыр баржа өстерәүче теге заман бурлаклары да сокланып тел шартлатыр иде, валлаһи! Безнең дә исебез китте. Тик Марс Шабай гына, канәгатьсезлек белдереп, нидер әйтеп куйды.

Фәнис шунда, диванда яткан килеш:

— Күп мыр-мыр килсәң... Үрелеп кенә яңак төбеңә берне кундырып алырмын, — диде. — Ахирием, дип тормам!

Тик Марс кына:

— Шундый ул. Бер холыксызланса, дулаган аттан хуҗе була, — диде. — Пряме аптырагански...

— Елга бер генә холыксызланам бит мин, — дип Фәнис бөтен нурлы йөзен янә дә нурландырып җибәрде һәм дусты Марс Шабайны муеныннан кочаклап алды... ■

«Шәп кешеләр белән очрашу – үзе бер бәхет»

(Көндәлектән өзекләр)

Фәнис Яруллин

Бик күп вакыйгалар
Керми әсәрләргә –
Көндәлекләр булып
Ята дәфтәрләрдә...

Фәнис Яруллин

1986 ел, 13 февраль

Кичә Хәдичә апа Җәлилова килде. Бик ачык, кеше белән тиз аралаша һәм рәхәтләнеп көлә торган, юморга бай хатын икән. Аңа карап, Муса Җәлилне күз алдына китерергә тырышып утырдым. Ул да шундый бик тере күзле, ачык һәм ягымлы кеше булгандыр, мөгаен. Күп кенә сораулар бирермен, дип уйлаган идем. Марс Шабай күбрәк башка нәрсәләр турында сөйләп утырды да шәхси сорауларга вакыт әз калды. Җәлилнең 80 еллыгын уздырырга дип чакырганнар. Әминәне бик яратып бетерми, ахры, Мусаны көтү (сугыштан кайтуын көтү хакында сүз бара) турында сүз чыккач: «Аның кебек көткәнче, көтмәгәнең артыграк», — дип куйды. М.Шабаевка, «О моем брате» дигән китапны начар тышлык белән чыгардыгыз, диде. Шабай, мин болай да үз рискыма гына чыгардым, планга да кермәгән иде, рецензия дә начар язылган иде, диде. Бу ике арадагы сөйләшүгә караганда, Хәдичә апаның туры сүзле икәнлеге күренә. Җәлил дә, бәлки, шундый булгандыр. Бездә ике сәгать утырды. Самолёттан килеп төшүгә үк: «Мине иң беренче Фәнис Яруллиннарга алып барыгыз», — дип әйтеп куйган. Минем шулай эшләмәгән куллар белән язу яза алуыма бик шакკатты. Р.Мостафинга үпкәсе зур икән. Мусаның балачагын бик начар язган инде, ди. Ул аңардан Гаврош ясаган, ди. Бер бүлмәле фатирда яши икән. Хәдичә апаның ире 23 яшендә сугышта үлгән. Үзе дә сугышта катнашкан. Хәзер берүзе яши. Аның белән танышлык моннан бер-ике ел элек хат аша башланган иде. Ул минем «Төшә дә исемә» дигән шигырьне укыган. Дөресрәге, Оренбургта бер Мәйшәкәр исемле хатын минем «Танышлар арасында» дигән китапны аңа алып барган. Ул китап аларга бик ошаган. «Җәлил премиясенә иң лаеклы кеше — син», — дип, миңа хат язып салган иде. Шуннан язышкалап тордык.

19 март

Кичә Марс Шабай килде. Минем иҗат кичәсендә ул чыгыш ясаячак. Нәрсәләр сөйлим икән синең турында, ди. Үзең ни сөйләргә теләсәң — шуны сөйләрсең, дидем...

Марс: «Иҗат кичәңне уздырырга нигә риза булдың инде, үзеңне сакларга кирәк», — ди. Үземне саклыйм дип, үземне гел кочаклап кына утырырга

Казанда узган ярминкә вакытында. Рәсемдә (сулдан уңга): Нур Әхмәдиев, Ринат Галиев, Фәнис Яруллин, Нурсөя Яруллина, Рәкыйп Гаффар. 1996 ел

микәнни?! Халык алдына да бер чыгасы килә бит. Әле юбилейларга әллә барып җитеп була, әллә юк. Утыруы бик авыр булыр, әлбәттә. Ләкин, куркып торсаң, бер эш тә эшләп булмый. Үземне сакласам, миңа язмаскадыр да, бәлки. Бервакыт М.Мәһдиев тә: «Син разный кулъязмалар укып күзеңне бетермә», — дигән иде. Ә миңа төрле кеше китерә, отказать итә алмыйм…

23 март

Иҗат кичәм бик яхшы узды. Беткәннән соң мине котлаучылар барысы да, бик яхшы булды, диде. Икенче көнне телефоннан шылтыратып әйтүчеләр дә шуны кабатлады. Университеттагы укытучым Флёра Сафиуллина: «Бер генә кичәнең дә моның кадәр табигый булганын хәтерләмим. Җавапларың бик остроумный, тапкыр чыкты һәм кыска булуы белән ошады», — диде…

21 апрель

Кичә бакчага барып кайттык. Көн бик җылы түгел иде. Шулай да көн буе урамда яттым…

Мөхәммәт абыйларның (Мәһдиев) алмагачларына саескан оялаган. Уты-

ра инде. Баласын чыгара алыр микән. Мөхәммәт абыйлар үзләре килгәч, куркып качмаса. Без бакчада йөргәнгә дә бик чырылдады. Соңыннан гына күнегә башлады. Мөхәммәт абыйга шылтыратып, сөенчесен алдым, кайту белән…

1988 ел, 28 октябрь

…бер кызыклы хәл: Зөлфәткә комсомол премиясен премияләр комитеты бирмәгән иде. Яшь шагыйрьләр Шәяхмәтовка *(комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Дамир Шәяхмәтов турында сүз бара. — **Ред.**)* бәреп кереп, даулап алганнар. «Сез Зөлфәтнең нинди әсәрен укыганыгыз бар? Нишләп бирмәдегез?» — дип тавыш кубарганнар. Менә демократиянең йогынтысы кешеләрне кыюлата башлады. Элекке вакыт булса, обком яныннан бүрек салмаган килеш үтәргә дә куркырлар иде…

1994 ел, 5 август

Кичә Әлмәттән — «Татнефть»тән шылтыраттылар. 9 августта безгә киләләр. Телевидение дә була. «Ихлас» дигән тема астында, кайбер зур шәхесләр турында тапшырулар ясыйлар. Мәсәлән, Әмирхан Еники, Гомәр Бәшировлар турында «Ихлас»та бирделәр. Күрәсең, Ринат Галиев турында да шундый тапшыру эшләргә булганнардыр. Ринат Галиев — минем сайланма әсәрләрне чыгару өчен тырышкан һәм бөтен авырлыгын күтәргән кеше. Шуңа күрә миннән дә берничә сүз әйттерергә телиләрдер.

Ринат Галиев кебек кешеләр турында яхшы сүз әйтү — бик фарыз һәм саваплы эш. Андыйлар күп түгел бездә. Дәүләт башында шундый кешеләр утырса, безнең ил әллә кайчан иң алдынгылар рәтенә басар иде инде. Дәүләт башында утыручылар бүгенге көн белән яшиләр. Аларга һәрнәрсә бүген табыш китерсен. Ә Ринат Галиевләр, культураны, сәнгатьне үстерми торып, экономикада да, сәнгатьтә дә алга китеп булмаслыгын яхшы аңлыйлар.

Төптәнрәк уйлап карасаң, авыр промышленностьтамы, башка тармактамы — нинди генә уңышларга ирешмик, ул урысныкы гына була, гәрчә төп уйлап табучылары татар булса да. Без бары тик әдәбиятыбызны, сәнгатебезне, музыкабызны дөнья югарылыгына күтәрә алсак кына, чикләрне үтеп чыгып, татарлыгыбызны күрсәтә алабыз. Монда инде авторлыкны танымый булдыра алмыйлар. Татар хәтта космик корабльнең иң яңа моделен уйлап тапса да, әгәр ул корабльдә космоска урыс утырып оча икән — бу Россиянең дөньяга танылуы була. Татар исемен анда ялгыш та атамаячаклар. Безнең республика җитәкчеләре моны аңламыйдыр, дип уйламыйм. Ләкин, Мәскәү йодрыгыннан куркып, мәдәнияткә, сәнгатькә акчаның йодрыктан сытылып чыкканын гына бирәләр. Димәк, Галиевнең ярдәме — шәхсән минем өчен генә түгел, бөтен халыкка ярдәм. Безнең китапларыбыз бит халык өчен языла. Язылган әсәрләр халыкка никадәр тизрәк барып җитсә, тәрбияви роле дә шуның кадәр күбрәк була.

10 август

Кичә бик күңелле көн булды. Ринат Галиевләр килде. Ришат Әбүбәкеров, Ринат Галиевнең хатыны Гасимә ханым һәм «Татнефть»нең геологик разведкасыннан бу оешманың управляющие Нәкыйп Сәлахович Гатиятуллин һәм шул георазведкадан Баязитов Рәфикъ Кәбирович дигән кеше бар иде… Телевидениедән режиссёр Флера исемле ханым, алып баручы Роберт Миңнуллин, калганнары операторлар, ут яктыртучылар…

Мин, хуҗа кеше буларак, болай дип сүз башладым: *«…Менә бу минем кулымдагы китап (мин китапны күрсәтәм) — «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат әфәнде Галиевнең шәхси ты-*

рышлыгы һәм «Татнефть»нең матди ярдәме белән чыкты. Шушындый авыр заманда да Ринат Галиев культурабызны, сәнгатебезне үстерергә мөмкинлекләр таба. Без аның театрларга да, үзешчән композиторларга да, әдәбият әһелләренә дә ярдәм итүен беләбез. Ринат әфәнде, минемчә, безнең чорның иң зыялы кешеләреннән берсе. Зыялылыкны мин укымышлылыкка гына кайтарып калдырмыйм. Зыялы кеше — иң беренче мәрхәмәтле кеше. Аның икенче сыйфаты — алга карап яши белү. Менә бу әдәбият һәм сәнгать турында кайгыртулар шуны раслый да инде. Күп кенә эшмәкәрләр табышны бүген үк алырга тели. Ә Ринат кебек кешеләр, кешенең рухын баетмый, культурасын үстерми торып, икътисадта да, сәясәттә дә алга китеп булмаганны аңлыйлар. Зыялылыкның өченче сыйфаты — милләт турында кайгырту»...

1995 ел, 13 октябрь

12се көнне «Татнефть»тән Ринат Галиевләр килеп төште. Ярдәмчесе Ришат Әбүбәкеров, мондагы вәкилләре Рәфыйк Кәбирович, «Ватаным Татарстан»нан Илсөяр Хәйруллина белән Асия Юнысова. Бик күп күчтәнәчләр алып килгәннәр иде... Бик матур утырдык. Шунда Ринат Галиев безнең районда яңа мәктәп ачылуы, шул мәктәптә минем китапларның тезелеп торуы, укучыларның минем шигырьләрне сөйләүләрен әйтте. «Мин үзем дә синең шигырьләрне бик яратам. Менә берсен газетадан кисеп алып, куен кесәсендәге дәфтәргә салып куйдым әле, мин аны ятлаячакмын», — дип, газета кисәген алып күрсәтте. Анда минем «Горурлык» дигән шигырь иде. «Юлларда йөргәндә, самолётларда очканда ятлыйм мин аны», — диде. Шунда Асия Юнысова: «Сезнең кебек көчле эш кешеләренә дә шигъри допинг кирәкмени, Ринат Гыймаделисламович?» — дип сорады. Ринат Галиев: «Фәниснең шигырьләре миңа һәрвакыт көч бирә», — диде. Болай иркенләп озак утырганнары юк иде әле. Махсус шуның өчен җыелышып килгәннәр. Ринат Галиев монда сессиядә. Шуннан ярдәмчесе Ришатка шылтыраткан. «Күптән Фәнис янына барган юк, әйдә бүген шуны эшлик әле», — дигән. Тегесе Әлмәттән, Ринат Галиевнең сессиядән чыгуына килеп җиткән.

1996 ел, 22 март

Узган атнада күңелле хәлләр шактый булып алды. 16 мартта нефтьчеләрнең Казанда ярминкәсе булган иде, мине дә чакырдылар. Килеп алып киттеләр. Галиев бер өстәлгә табын әзерләтте. Президент та безнең тирәгә сугылып үтте. Кемдер безне фотога төшерде. Ул ярминкәдә төшкән фотоларны миңа да китерделәр.

1997 ел, 5 март

Бүген Әлмәткә — «Татнефть»кә шылтыратырга тора идем, үзләре шылтыратты. «Рухи яңарыш фонды» оештыралар икән, шуның презентациясенә мине дә чакыралар. Килеп, китереп куюны, кунакханәгә урнаштыруны оештырырбыз, диләр. Минем йөрәк кузгалып куйды. Шәп кешеләр белән очрашу — үзе бер бәхет бит...

14 март

11-13 мартларда Әлмәттә булдык. Искиткеч әйбәт булды. Килеп алдылар, китереп куйдылар...

12се көнне «Рухият» фондының ачылу тантанасы булды. Алты сәгать йөреп кайттык. Нур Әхмәдиев белән мин бу фондның беренче лауреатлары булдык. Дипломнар тапшырдылар...

Концерт тәнәфесендә һәм концерттан соң ашап-эчәргә бик мул табыннар әзерләгәннәр иде. Галиев гел минем янда булды. Кайберәүләр миңа көнләшеп тә караганнардыр инде. Әлмәткә килеп төшүгә, барыр җирегез булса, дип безгә махсус машина беркетеп куйдылар...

2000 ел, 21 июль

18е көнне көне буе Ринат Галиев шылтыраткан, безгә тоташа алмаган. Кич белән үзем шылтыраткан идем, өйдә булмады. Икенче көнне иртүк үзе шылтыратты. «Бер мероприятие бар иде, сине шунда алып бармакчы идем», — ди. Аннары аларның башка мәшәкатьләре туган: Кызыльяр белән Октябрьск арасында ике машина бәрелешкән. Шундагы бер егет бик авыр хәлдә икән. Шуның өчен үзебезнең хөкүмәт органнарына элемтәгә чыгып, вертолёт сораган. Ачынып-ачынып, миңа шылтырата: «11 класс кына бетергән малай, Октябрьск хастаханәсендә реанимация бүлегендә ята. Башкортстанда медицина аппаратлары безнекенә караганда көчсез, ничек тә Казанга озатасы иде», — ди.

Урындагы хастаханәләр иске икәнлеген ул яхшы белә, шуңа күрә Казаннан вертолёт чакырткан һәм, авариягә эләккән бу егетне Казанга алып китми торып, үз эше белән китмәгән. Ул егет аңа беркем дә түгел югыйсә... Бу Галиев кеше турында кайгыртмый яши алмый, ахры...

2009 ел, 15 сентябрь

Әлмәт башлыгы Ришат Әбүбәкеров үзенең кызы Резидә белән килгән иде. Кызы финанс-экономика институтын бетергән. Әлегә әйбәт эшкә урнашмаган. Ришат үзе экономика буенча докторлык диссертациясе яклады. Белемле дә, кешелекле дә, кыскасы, әйбәт кеше. Зур урыннарда утырып та кеше булып калучылар сирәк бит. «Татнефть»нең элеккеге генераль директоры Ринат Галиев, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев, безнең районда ун ел хакимият башлыгы булып эшләп киткән һәм хәзер Министрлар Кабинетында экология бүлеге начальнигы Нурислам Хәбипов — шундыйлардан.

2011 ел, 28 февраль

Кичә «ТАТМЕДИА» генераль директорының беренче урынбасары Фәрит Илдусович (Шаһиәхмәтов. — ред.) белән нәшриятта чыкмый ята торган китабым турында сөйләштек. Ул: «Менә 3 март көнне безнең утырыш була. Шунда сезнең мәсьәләне дә карарбыз. Үзем шылтыратып, нәтиҗәсен әйтермен», — диде.

3 март

Кичә Татарстан китап нәшриятының китап кибетендә быел, ягъни 2011 елны чыгарга тиешле китаплар исемлеген раслау комиссиясенең утырышы булган. Ниһаять, минем 25 табаклы шигырь китабын, чыгарырга, дигәннәр. Утырышта Разил Вәлиев, Дамир Шакиров, «ТАТМЕДИА»дан Фәрит Илдусович һәм тагын кайбер шагыйрьләр, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов катнашкан. Миңа каршы төшүче булмаган... Инде китапны исән-сау күрергә язсын. Бу — минем соңгы шигырь китабым булыр. Прозалар бар әле барын. Ләкин шигырь бөтенләй башка бит ул.

Каләм очындагы шигъри утым
Янып, сүнәм-сүнәм, диеп тора —
Кабызырга яшь кызлар да килми,
Читтән генә карап көлеп тора.

Шигърияттән алган очкын белән
Кабыздым мин күпме учакларны.
Хәтер төпләрендә күмер көйри —
Искә төшерсәм дә ул чакларны.

Җил искәндә күмер кызарса да,
Җил туктауга — сүнә күмерләр.
Януыннан бер туктаса әгәр,
Кабат кабынмыйлар гомерләр...

(Фәнис Яруллинның «Хәтер төпләрендә утлы күмер» дигән китабыннан (2013) алынды.) ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

КАМАЛ ГАЛИӘСГАР (Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов, (1879-1933) – драматург, прозаик, шагыйрь, җәмәгать һәм театр эшлеклесе, нашир, каррикатурист. Хезмәт Батыры (1923), «Татарстанның халык драматургы» (1926) кебек мактаулы исемнәр иясе. **Г.К.** – Т.ның дусты, хезмәттәше һәм фикердәше. Ул аның белән 1907 елда таныша, аңарчы әсәрләрен укып барган һәм югары бәяләгән була. Т. да **Г.К**.ны талантлы һәм зыялы саный, 1911 елның 1 гыйнварында С.Сүнчәләйгә язган хатында, канәгатьлек хисе белән: «Болгар» номерында «Галиәсгар Камал, Г.Ибраһимов вә бәгъзан Фатих Әмирхан вә башка интеллигентлар белән катышам», – дип яза. **Г.К.** 1908-1909 елларда Г.Тукай белән бергә редакциясе драматургның фатирында булган революцион-демократик эчтәлекле «Яшен» исемле көлке журналы чыгара. **Г.К.** «Йолдыз»да эшләгәндә Т. әлеге газетага актив яза; яшьләр бергәләп «Шәрык» клубына йөри. **Г.К.**, Т. вафатыннан соң, исемен халык күңелендә ныгыту йөзеннән, бик күп эшләр башкара. 1933 елда «Совет әдәбияты» журналының 6 нчы санында дусты турында җылы хисле истәлек бастыра; әсәрләренә аның иҗатыннан тема, идея-мотивлар ала («Өйләнәм – ник өйләндем», «Бер рәсемгә», «Белә алмыйм» һ.б.), аннан пародия алымнарына өйрәнә, шагыйрьнең поэтик сурәтләү чараларын куллана. Тукай да үз вакытында шигырьләрендә аның язганнарына ишарәләп үтә торган була... **Г.К.** белән Т. икесе дә халыкның аң-мәгърифәт һәм башка яклардан алга китешен кайгыртып яза, иҗтимагый-социаль мәсьәләләрдә демиократик позицияләрдә тора, иҗатлары гомуми эчтәлек, шул исәптән идея эчтәлеге ягыннан да бер-берсенә шактый охшаш (чагыштыр: «Яңа Кисекбаш» – «Безнең шәһәрнең серләре»; «Базар» – «Ысуле кадимче»). Т. **Г.К.** иҗатына бик югары бәя бирә: «...*Татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәкһүл (белемсез, караңгы) почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтүгә каләменең көченнән килгәненә хайрәт итәрәк (гаҗәпләнеп.), аны – Галиәсгар әфәндене – «татар Островские» бинам Мөкәррәмә вә мөстәхикы белән тәгъзим итеп (дигән хөрмәтле һәм тиешле исем белән олылап), сүземне бетерәм».*

Р.Ф.Харрасова

Әсәр: Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлек // Тукай турында истәлекләр. К. 1976. Б.62-67; Тукай Г. Галиәсгар әфәнде Камалның X еллык юбилейсе // Галиәсгар Камал турында истәлекләр. К. 1979. Б.94-99; Тукай Г. Галиәсгар әфәнде Камалның X еллык юбилейсе // Габдулла Тукай. Әсәрләр. 5 томда. Т.4. К. 1985. Б.135-140.

Әдәб.: Габдрахман Камал II. Галиәсгар Камал (Биографиясенә эскизлар). Галиәсгар Камал турында истәлекләр. К. 1979. Б.3-16; Гайнуллин М.Х. Галиәсгар Камал (1879 – 1933). К. 1978. – 40 б.; Галиәсгар Камал: әдип һәм заман: Язучының 125 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы / Татарстан ФА Г.Ибраһимов исем. ТӘһСИ. Казан. 2005. 156 б.; Мәһдиев М.С. Г.Камал – журналист // Әдәбият һәм чынбарлык. К. 1987. 68-80 б., һ.б.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

НАГАЙБӘКЛӘР, НУГАЙБӘКЛӘР Керәшен татарларның нигездә элекке байлар (бәкләр) дигән кабиләләрдән оешкан төркеме. Нәсаралык кабул иткәч, татар атамасы урынына *нагайбәк* исемен алалар. Хәзерге вакытта Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районының Кассель, Фершампенуаз, Остроленко, Париж, Астафьевка авылларында тупланып яшиләр. Чиләбе өлкәсенең Чибәркүл районы Варлам, Попово, Болотово, Краснокаменка, Ключевская авылларында да бер төркем нагайбәкләр төпләнеп утырган.

1867 елда нагайбәкләр 12 мең, 1926 елда 11,2 мең исәпләнгән, 1939 елга кадәр мөстәкыйль халык дип саналып йөргән. 2002 елгы җанисәп Россия Федерациясендә барлыгы 9611 кешенең үзләрен аерым *нагайбәк/нугайбәк* милләтеннән дип санаганлыгын күрсәтте. Алар инде аз санлы халыкларның федераль исемлегенә кертелгән.

1842 елга кадәр Чиләбе нагайбәкләре Уфа губернасының Бәләбәй өязендә яшәгән.

Россия Фәннәр Академиясе мөхбир әгъзасы Пётр Рычков нагайбәкләрне башкорт дип санаган. Күренекле тюрколог Николай Катанов та үзенең 1897 елның июнь-август айларында Уфа

Париж авылының нагайбәк-казаклары. XX гасыр башы

губернасының Бәләбәй һәм Минзәлә өязләрендәге сәяхәте турында язган хисапнамәсендә Бакалы керәшеннәренең чукындырылган башкортлар булуына шикләнмәгәнлеген әйтә. Урыс казакларының тарихын өйрәнүче Фёдор Стариков исә нагайбәкләрнең килеп чыгышын Казан егылганнан соң чукындырылган һәм Бәләбәй, Минзәлә якларына күчереп утыртылган Арча татарлары белән бәйли. Тарихчы Павел Небольсин нагайбәкләрне чукындырылган мишәрләр дип исәпли. Үзе дә нагайбәк керәшеннәреннән чыккан Екатерина Бектеева нагайбәкләрнең башлангыч тарихын турыдан-туры нугайларга бәйләргә тырыша.

Соңгы фикер мәгълүм дәрәҗәдә тел фактлары белән дә раслана. *«Билгеле*

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынан басылып килә.

булганча, Казан арты-Дөбъяз, Казан арты-Питрәч төбәге (бигрәк тә Шәле, Күн авыллары) сөйләшләрендә нугай теле белән уртак үзенчәлекләр сакланган», — дип яза Фәрит Йосыпов. Академик Марсель Әхмәтҗанов Казан артындагы Балтач, Карадуган авылларының тарихын нугай-кыпчаклар белән бәйләнештә карый. Тарихчы Дамир Исхаков нагайбәк керәшеннәренең Казан арты, Мишә буе керәшеннәре белән уртаклыкларын күрсәтә. Фәрит Йосыпов фикеренчә, нагайбәкләрнең килеп чыгышын Арча татарлары белән бәйләү нугай-кыпчак гипотезасына каршы килми.

Гомумән, Көнчыгыш Кама аръягында «Уфа яңа керәшеннәре» исеме белән нагайбәкләр 1729 елдан билгеле. Алар «казак хезмәте»ндә булып, ирләре казак формасы киеп йөргәннәр. Ә культуралары башлыча керәшен татарларныкына охшаш, дияргә була.

Нагайбәкләрдә нәсара исемнәре борынгы төрки тел төзелешенә һәм яңгырашына яраклаштырып әйтелә (мәсәлән, Ибый — Иван, Гәрей — Григорий, Татый — Татьяна, Учый — Осип, Макрый — Макар, Карпый — Карп, Сабый — Савелий, Улей — Ульяна, Барук — Варвара, Мәтүк — Матрёна, Пасук — Прасковья, Памук — Фома, Гуруш — Аграфена, Укуш — Гликерия, Уруш — Ирина).

Мөселман татарлардан аермалы буларак, нагайбәкләрдә күмәк (хор белән) җырлау бар, бусы инде православие дине йогынтысыннан килә.

Тагын шуны әйтеп китсәк урынлы булыр — Нагайбәк сүзе татарда исем булып та йөргән: мәсәлән, Нагайбәк Әсәнов исемле ясаклы татарлар старшинасының (Татарстанның Азнакай районы Чалпы авылыннан) Пугачёв фетнәсендә катнашканлыгы билгеле.

НАРДУГАН ***(кышкы нардуган)*** *тар.* Бу сүзне нард (шакмак атып уйнау һәм күрәзәлек итү) һәм фал сүзләреннән оешкан, дип карыйлар (фарсыча — нард-у-фал). Төрек сөйләшләрендә — *мартуфал, мартавал, манту-вар.* Кыскасы, «нардуган» сүзе тәүге формасыннан шактый ераклашкан һәм нардуган көннәрендә җырлана торган «нардуганым нар булсын» сүзләренең мәгънәсен ачыклау кыен. Кышкы нардуган *(сәүмәт)* бәйрәме 25 декабрьдә башланып бер атна (кайбер төбәкләрдә уникe көн) дәвам иткән. Мәгълүм булганча, иң суык кырык көнлек вакытны (25 декабрь-5 февраль) халык *кышкы чиллә* дип йөртә. Кышкы нардуганның башы менә шушы кышкы чиллә башына туры килгән һәм нардуган уеннарында *Чиллә бабай* — хәзерге Кыш бабай катнаша торган булган. *Чиллә бабай яки Нардуган бабай* кышкы суыкларны җибәрә, дип уйлаганнар. Нардуган урыслардагы *святкига* туры килә. Нардуган бәйрәмендә кыз-кыркын уникешәрле төркемнәргә бүленеп, яңа ел кичәләре оештырган, кичәләрдә тамашалы уеннар уйнаган һәм «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре…» дип башланган җырлар ярдәмендә яңа елда нинләр булачагын юрап караган. Күрәсең, мондый башлам хас булган җырларның күплеге нардуган кичәләрендә багу-юрау йоласының электә киң таралган булуы турында сөйли торгандыр. *«Кышкы нардуган Казан дәүләтендә ярминкә вакытында бәйрәм ителгән һәм ярминкәгә килгән бүтән халык әһелләре аша күршеләргә таралган»,* — дип яза Рифкать Әхмәтҗанов. Җәйге Нардуган вакытында чәчәкләргә карап юраганнар. Шушы ук автор: «Нардуган тәүдә җәйге чиллә башында (25 июнь-5 июль) уздырылган һәм *аяу көннәре, аяу атнасы* дип тә аталган», дип яза. Бусы урысларның *русалия, троицын* бәйрәменә туры килә. Тора-бара, тормыш шартлары начарлангач, Җәйге Нардуган онытылган.

Ислам һәм җирле диннәр нардуган йоласын кире каккан һәм ул халыкта еш кына *шайтан туе* дип тә аталган (ә *җен* яки *пәри туе* бөтенләй башка нәрсә — кечкенә өермә). Нардуганны белдергән *чипичья, сәүмәт* (гарәпчәдән), *истәрмә* (этимологиясе ачык түгел, мәгънәсе *тын тыңлау, тынга йөрү* — багучылык төре) сүзләре дә мәгълүм. ■

ЙОЗАКЛАР

(ТР Милли музее фондларыннан)

Кешеләр элек йорт ишекләрен эчке яктан гына бикләгән. Димәк, йортның ишекләре өйдә кеше булганда гына ябык булган. Соңрак ишекне тышкы яктан да бикли торган элмә, ә аннары уеп куелган йозаклар барлыкка килә.

Болгар чоры ядкярләре арасында бронза коючылар ясаган барс, ат, эт һ.б. җанвар кыяфәтендәге йозаклар бар.

Гүзәлия Җәләлева *әзерләде.*



«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның декабрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Түнтәр мәдрәсәсенә хөкем

Түнтәрдә мәрхүм хәзрәтләр нигезендәге мәдрәсәдә Могыйнетдин дигән мөгаллим күп еллардан бирле балаларны тәгълим кыладыр. 1912 нче елда Нәҗип мәхдүмнең указы алынгач та, һаман шунда мөгаллимлек кылып торганда, 1914 нче елда авылның бер кеше исеменнән мөгаллимне рөхсәтсез укыта, дип прокурорга кәгазь бирелгән. Бу кәгазь ошбу 1915 нче елның июнендә Сарапул окружной судында каралып, мөгаллим гаепле табылып, мәдрәсә ябылырга хөкем ителде. Мөгаллим бу хөкемнән риза булмый Судебная палатага кәгазь бирде. Шушы эш бу елның 9 нчы декабрендә Казан Судебная палатасында янәдән дикъкать берлә тикшерелеп, Алланың кодрәте, хакимнәрнең гадаләте сәясендә мөгаллим гаепсез табылып, мәдрәсә сәламәт калды. Дәгъва вәкиле Садретдин әфәнде Максуди җәнаплары булуы мәсьәләнең хакимнәр каршында бик ачык куелуына сәбәп булды.

Кояш. — 1915. — №868. — 11 дек.

Шәрык кичәсе

Өченче көн Новый клуб залында Казан университетында укучы мөселман студентлар файдасына «Шәрык»кичәсе ясалды. Залга кергәнче шәрык ысулында тезелгән бизәкләр, киосклар, шул ук тарызда тезелгән буфет-өстәл күзгә чалына. Буфет-өстәл янында, киосклларда, миһманнарны [кунакларны] кабул урыннарында булган калфаклы туташлар, ханымнар, кәләпүшле әфәнделәр монда булачак кичәнең татарлар кичәсе икәнен ачык күрсәтеп торалар.

Залда миһманнар байтак күренә. Күбрәге шәһәрнең хәлле вә зыялы сыйныфыннан. Кичәнең программасы тулы гына төзелгән. 1 нче бүлектә «Каенеш»комедиясе ихтияр кылынган [сайлап алынган]. Бәдигелҗамал (Болгарская), Габделкәрим (Кариев), Ибраһим (Үзбәк Тинчурин), Зәйнәп (Болгарская) рольләре гаять уңышлы үтте вә Гөлҗамал да (Таждарова) бу уенда тиешле аһәңне җиренә җиткерде.

2 нче бүлек — 1) Фатыйма туташ Гомәрова катнашы белән укучы туташ вә егетләр тарафыннан башкарылган күмәк җыр. Аерым җырлаган Фатыйма туташ Гомәрова үз тавышының көчле, эшләнгән, югарыдан — түбәнгә, йомшактан катыга вә киресенчәгә күчүләре нәфис икәнлеген исбат кылды; 2) Студент Агас бәк кавказ көйләрен мандолинада гаять нәфис башкарды. Моның белән бергә рояльдә аккомпанемент уйнаган туташ тарафыннан да симфониягә ригая күргәзелде; 3) Казакъ студентлары тарафыннан җырланган казакъ җырларында көйләрнең дә музыкальныйлары (иң матурлары) ихтияр кылынган, җырлаучылар да бик моңлы җырладылар; 4) «Безне урынсыз яманлыйлар» исемле Тукай шигырен декламировать итәр өчен гадәттән тыш сәләт кирәк. Тукай шигырьләре ул чагында Тукай теләгән

* Даталар иске стиль белән бирелә.

мәгънәне биреп бетерә алмыйлар. Тукай шигырьләренең бер хасләте дә, алар Тукай үзе көйләгәнчә, «Бакырган», «Тәкый гаҗәп», «Мөхәммәдия», «Кисекбаш» көйләренә салып көйләгәндә генә ләззәт бирә алалар; 5) Габбас әфәнде берничә урында рояльне яхшы ук каты кыйнады. Миһманнар аны бүтәннәрдән күбрәк алкышлады; 6) Скрипкада студент тарафыннан моңлы гына итеп озын көйләр уйналды; 7) Струнный оркестрда уйналган попуррида (көйләр җыентыгы) басларга (калын тавыш) нисбәтән мелодия (нечкә тавышлар) артык булса да, мелодия уйнаучыларның тәнасебкә ригая кылулары [бер-беренә туры китерүләре] сәбәпле, көйләр гаять моңлы чыкты.

3 нче бүлек — 1) Студентлар тарафыннан башкарылган «Чабында төн» (башкортлар тормышыннан бер ләүхә) — матур манзара; 2) «Җанар падишаһлыгында» — экияттән алынган бик матур манзара...

4 нче бүлектә туташ вә студентлар тарафыннан тасвир ителгән «Кавказ туе»кичәнең шәркыйлегенә бәйрәм (рухын) арттырды.

Гомумән, сәхнә миһманнарны теләгәннән артык мәмнүн итте, хәтердә матур эз калдырды.

Кичәдә мактаулы яктан дикъкатькә алырлык бер хәл сизелде. Моннан берничә еллар гына элек, татарча театр эшләре яңарак башланган чакларда, хөкүмәт мәктәпләрендә укучылар арасында «зыялы кешегә татарча сөйләшү гарьлек» дигән бер аң хөкем сөргән дәвердә, мөселман студентлар файдасына татарча спектакль вә кичәләр ясалганда уйнаучылар арасында ярым-йорты татарча сөйләшә белә торган бер генә студент бар иде. Әмма бу көн исә студентларның вә укучыларның һәммәсе мәдрәсә тәмам иткән шәкертләр дәрәҗәсендә җитешле итеп татарча укыйлар вә сөйлиләр һәм саннары да күп.

Кичәнең варидәте [кереме] мең ярым сум чамасыннан булган.

Кояш. — 1915. — №878. — 23 дек.

Ярдәм сорау

Әҗем мәсҗеде мәхәлләсендәге мөселман кызлар мәктәбе мөгаллимәсе Габделгаффарова, шәһәр управасына гариза биреп, шул мәктәпкә бушлай утын бирү белән генә булса да ярдәм итүен сораган. Гариза иясе, утын кыйммәтчелеге сәбәпле, мәктәпнең ярым-йорты гына җылытылганлыгын, анда укый торган кызларга туңып утырырга туры килгәнлеген һәм хәзерге көндә бу мәктәптә һәр көн килеп укучыларның саны 50дән дә ким түгел икәнен белдергән.

Кояш. — 1915. — №882. — 29 дек.

Яңа ширкәт

Ишетүебезгә күрә, мөселман байлары Казан янында известь-алебастр, цемент хәзерләтү өчен бер ширкәт төзергә уйлаганнар вә бу эш хәзерге көндә мәйданга чыгарга якынлашкан икән. Әлегә кадәр Казанда мөселманнардан беркадәр сәрмая [акча] белән генә известь һәм алебастр хәзерләү белән шөгыльләнүчеләр, кечкенә заводлар бар иде. Бу ширкәт шушы кечкенә заводларны да бергә оештырып, зур сәрмая туплап, болар өстенә цемент хәзерләү эшен дә арттырачак икән.

Кояш. — 1915. — №884. — 31 дек.

Көлке куа килә...

Рабит Батулла
ТАКТАШ ПЕСИЕ

Һади Такташ бер пьесасында шундый аңлатма (автор сүзе) язып куйган була: сәхнә күренешендә, диванга утырып, койрыгын кыйблага каратып, бер песи битен, колак артларын юа.

Артистлар песине сызып ташларга куша. Такташ песине пьесадан алып ташларга теше-тырнагы белән каршы тора. Шулай озак кына тарткалашканнан соң, режиссёр әйтә:

— Һади, кирәк чакта диванга утырып битен юа торган песи алып килә алсаң, песине сәхнәгә чыгарабыз! — ди.

Такташ бераз уйланып тора да шаркылдап көлә башлый һәм песине пьесадан сызып ташлый.

Нури Арслан
ИКЕ ЭПИГРАММА

Сәрвәр Әдһәмовага

Горькийларны саф татарча
сөйләттерде,
«Абай»ның думбырасын көйләп
бирде, —
Сәрвәр апа шундый безнең!
Иренмичә
Яшьләрне дә тәрҗемәгә өйрәт инде.



И.Хантимеров шаржлары

Сәрвәр Әдһәмова

Шамил Маннапов
КАЙСЫ БӨЕГРӘК?

Драматург Шәриф Хөсәенов үзенең туган көнендә якын күргән каләмдәшләрен кунакка чакыра. Югары кимәлдәге тостлар әйтеп, матур гына утыра болар.

Мәҗлеснең кызган бер вакытында Шәриф Хөсәенов бүлмәдән югалып тора. Шул арада аның урынына түбәтәйле бер абзый утыра. Моны күреп, мәҗлесне алып баручы — тамада Аяз Гыйләҗев әйтә тегеңә:

— Абзый кеше, ул урын бөек драматургныкы. Ничек җөрьәт итеп утырдыгыз анда? — дип, күчеп утырырга өнди.

— Утырырга хакым булганга утырам, и вчү! — ди абзый.

— Сез кем соң ул кадәр? — дип, янә бәйләнә Аяз Гыйләҗев.

Кәләпүшле абзый үзенең кемлеген танырга мәҗбүр:

— Сез бөек дип мактаган драматургның әнисен кочкан кеше мин! —ди.

Баксаң, ул Шәриф Хөсәеновның әтисе икән!

Шәүкәт Галиев
ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВКА

Х.Әхмәтҗанов шаржы

Шәүкәт Галиев

(«Ак чәчәкләр» романы басылып чыгу уңаеннан)

Бирәм, диде, роман бирде,
Әпсәләм ул алдамый;
Әле бусы — чәчәкләре,
Җимешләре алда! — ди.

Хөҗҗәт Гыйльфан
ТӨТЕН САМАВЫРДАН ДА ЧЫГА

«Яшь ленинчы» редакциясе. Шагыйрь Госман Садәнең эш бүлмәсендә җыелышып утырган яшь шагыйрьләргә бер үзешчән композитор болай ди:

— Җыр текстлары язгысыз әле, егетләр. Сезнең бит төтен чыгарып эшләр вакытыгыз!

Дәшми-тынмый гына язып утырган Мөдәррис Әгъләмов сикереп тора да:

— Төтен ул самавырдан да чыга! — ди һәм, башын кыңгыр салып, бүлмәдән чыгып китә.

Карахмәт (Әхмәт Исхак)
ШАГЫЙРЬ ҺӘМ УКУЧЫ

— Чал төште чигәгә, —
Дип зарланды шагыйрь, —
Сезнең өчен көн-төн
Шигырьләр тукып...
— Ә минем чәч, — диде
Бер укучы шунда, —
Агарды бөтенләй
Шуларны укып!

Тмин (Туфан Миңнуллин)
БЕЗНЕҢ АВЫЛДА

(Язучыларның «Тынгысыз каләм»дигән дивар газетасыннан)

Безнең авылда берәү: дөньяның якасыннан эләктердем, дип сөенеп җилкенгән икән, үз күлмәгенең якасын умырып алган.

***

Безненең авылның чыпчыкларыннан да, бик теләсәң, елына бер кашык сөт савып алып була.

***

Безнең авыл тавыклары салган һәр күкәйдән икешәр чеби чыга.

***

Безнең авыл абзыеның алдына кәбестә ашы куеп:

— Әйдә, аштан уз. Ачыктым, эчемдә бүреләр улый, дип әйткән идең, — дигәннәр.

— Бүреләр эчегән кәбестә шулпасы эчмиләр шул, — дигән абзый.

***

Безнең авыл кызлары кабыгы әрчелгән йомырка кебек ак тәнле.

***

Безнең авыл кешеләре гырлаганда да татарча итеп гырлыйлар.

Салих Батталга бәйле мәзәкләр

Әбрар Кәримуллин
«КОММУНИСТ»НЫҢ ӘҖӘЛЕ

Заманында ҮК ЭКП (б)ның татар-башкорт бүлеге каршында «Эшче» газетасы чыгып килгән. Аннан соң ул «Коммунист» исеме белән чыгуын дәвам иткән. Бераздан соң бу газетаны бөтенләй ябалар.

Шушы хәлләрдән соң Салих Баттал әйтеп куя, имеш:

— «Эшче»... «Коммунист» булып үлде!

Туфан Миңнуллин
АТМЫЙ ТОРГАН ОЛЫ ТУП

Гомәр Бәширов язучылар башлыгы булып торганда күп яза алмый, «Намус» романыннан соң әсәрләре матбугатта күренми. Бу турыда әдипнең үзенә дә әйткәлиләр һәм бер җыелышта ул болай сүз башлый:

— Иптәшләр, язучылар алар туплар кебек. Эре калибрлы туплар, гаубица һәм вак туплар... Язучылар шулай төрле була...

Шулчак Салих Баттал урыннан сүз кыстыра:

— Дөньяда иң зур туп — царь-пушка, ләкин бер тапкыр да атып караганы юк!

(Рабит Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан)

Салих Баттал
САКАЛЛЫ ҖӘЛИЛ

1934 елның 23 октябрендә очучы Салих Баттал Муса Җәлилгә аэродромнан шылтырата:

— Кил, кинога билет алдым, — ди.

— Нинди картина? — дип сорый Җәлил.

— Яшәртү турында. Фәнни картина.

— Һи, алайса картлар гына карарлык икән! — ди Муса.

— Шуның өчен сиңа шылтыратам да, — ди Баттал. — «Сакалым сабынлы мунчала кебек» дип шигырь язгансың ич...

(С.Батталның «Сайланма әсәрләр» китабыннан, 1974)

Атилла Расих
«СЕЗГӘ — ФАТИР, МИҢА ХАТЫН КИРӘК!»

Салих Баттал, берникадәр ялгыз яшәгәннән соң, бик ягымлы Мәдинә ханымга өйләнде. Ул ханым да ялгызак, вакытында җырчы, хористка булып хезмәт иткән артистка. Белүемчә, байтак кына еллар Төркмәнстанда да яшәгән.

Шагыйрьнең бу ханымга өйләнүе дә үзенчәлекле, нәкъ Батталча килеп чыккан. Көннәрдән беркөнне, үзенә торак урыны эзләп, Мәдинә ханым Салих абый фатирының ишеген кага. Салих абыйның бу чибәр хатынга шунда ук күзе төшә. Ул, беренче сөйләшүдә үк, карап-карап тора да: «Сезгә — фатир, ә миңа хатын кирәк! Әйдәгез, без, ирле-хатынлы булып, шушы бүлмәдә яшик!» — ди.

Мәдинә ханым икеләнеп тормый: «Яхшы, алайса, шулай яшик», — ди. Шулай итеп, алар «алдым-бирдем»не бик ансат һәм бик тиз башкара.

(«Салих Баттал турында истәлекләр» китабыннан, 2011)

Мирасворд

Беренче татар пьесасы авторы

Урта гасыр төрки дәүләтләрдә идарәче бәк титулы

Хайваннарның язын коела торган йон катламы

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы



Нота

Әдәби әсәр, китап бүлеге

Күктәге бушлык, ачыклык (иск.)

Зәкят малының күләме

«... Мәргән» дастаны

Металлны куеп чүки торган тимер аслык

Гарәп хәрефе

Мәдинә Маликова романы

Шаһит, таныш (иск.)

Такташ, Атласи

Беренче татар театр труппасы

Тукыма бизәге, чүпләм

...-том

Татар балалар шагыйре

Геза ... (мажар пианисты)

Куныч-сыз җиңел аяк киеме

Ил башлыгы (иск.)

Ярым ефәк чуар тукыма

«... кичә генә яз иде» (Аманулла)

... Намдаков (бурят сынчысы)

Бөркетнең бер төре

Гел, һәрвакыт

Лаос акчасы

Борынгы грек сынчысы

Грек хәрефе

Туку станында буй җепне күтәрү-төшерү өчен махсус кыса

Алтын Урда ханы

XIX йөз рус рәссамы

Бөек ... юлы

XV-XVI йөздә Казан ханлыгында ирекле хәрбиләр катлавы

Совет йөк автомобиле

... Гумилев

Гаяз Исхакый повесте

Кыйммәтле мехлы җәнлек

Чабагач таягы

Скандинавия мифологиясендәге Алла

Ашлык өеме

Сиртмәле ...

Мәче башлы ябалак (диал.)

Дәвер, заман

... юлны якын итеп

***Рәис Габдулла** төзеде.*

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Чүкеч», Фаил, лазем, Әнәс, ыру, аркалык, Макар, әкә, җәя, егерме, ПЕН, Ашыт, «Ил», зәррә, Иктин, тахта, кын, арт, лигнит, «Мулла», Бигиев, инша, Зыя.

Өстән аска: Ика, фауна, җепкыр, Әрмән, ТНТ, Ильская, бүз, ак, Нәҗми, лаеш, угия, «Ыргыз», эллин, чолык, тәте, Илеш, ар, Ра, гавам, кызу, Әмирхан, келәт, чүмәлә, «Ант».

2015 ЕЛГА «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Гамьле булыйк — №1. — Б.3.

ТАРИХИ МИРАС

«Инде алмаган ни калды?» (Милли фаҗигабезне яктыртучы фарсы чыганагы) — №1. — Б.4-7; №2. — Б.10-15.

Алмаз Мөхәммәдиев. «Хак хөкменә коллар риза булу кирәк...» — №11. — Б.6-13; — №12. — Б.6-11.

Әнвәр Шәрипов. Бәйрәкә мәдрәсәсе турында яңа чыганаклар. — №12. — Б.12-17.

Әхмәтзәки Вәлиди. Төрек вә татар тарихы. — №9. — Б.15-20; №11. — Б.19-21.

Бакый Зыятдинов. Нәсел шәҗәрәләре. — №5. — Б.20-23.

Болгарда — ак кунакханә. — №5. — Б.38-39.

Габделкаюм Баһмани. Милли вә мөһим мәсьәлә. — №8. — Б.37-40; №9. — Б.21-25.

Гамир Гарифуллин. Бурсыклы (Ворскла) суы буендагы сугыш. — №10. — Б.6-10; Грюнвальд аланында татар җайдаклары. — №11. — Б.14-18.

Җәүдәт Миңнуллин. Кем ул Закир Галиев? — №12. — Б.24-26.

Зариф Бәшири. Мишәрләр (ахыры). — №1. — Б.8-12.

Зәйнәп Кәримия. Мәрҗанинең йорт тормышындагы кайбер гадәтләре. — №4. — Б.44-47.

Зәки Зәйнуллин. Изге койма кыйссасы. — №12. — Б.32-38.

Илдус Заһидуллин. Ш.Мәрҗани мирасында татарларның милли һәм дини тормыш-көнкүреше. — №4. — Б.35-38.

Ирек Һадиев. Гыйлем хәзинәсе, хәтер сакчысы... — №1. — Б.13-17.

Ләлә Мортазина, Илнур Газизуллин. Яңа Смәил мулласы. — №8. — Б.27-36.

Ленар Гобәйдуллин. «Чыңгыз баласы» газетасы. — №2. — Б.21-26;

«Шиһабетдинемез бер иде...» — №4. — Б.39-43; «Себер тракты тарихы» музее. — №6. — Б.34-37; «Игенче» журналы. — №7. — Б.13-17; «Берек» газетасы. — №10. — Б.11-14.

Людмила Белоусова. Чаллы-Чибәркүл арасы, Урал кичеп барасы. — №3. — Б.38-42.

Мөнир Әһлиев. Йөрәк түрендәге Йөрек. — №7. — Б.4-12.

Мөхәммәт Мәһдиев. Авылыбыз тарихыннан бер кисәк. — №12. — Б.27-31.

Наил Таиров, Илһам Таиров. Йосыф туган көн. — №5. — Б.24-25.

Наил Таиров. Зөһрә Акчуринаның әнисе Фатыйманың кабер ташы. — №11. — Б.22-23.

Николай Петров-Текин. Керәшен евангелистлары. — №3. — Б.25-32.

Нурсөя Шәйдуллина. Болгар. Тарихи белешмә. — №8. — Б.24-26; Болгар. Җамигъ мәчете. — №9. — Б.4-5; Болгар. Олы манара. — №10. — Б.4-5; Болгар. Көнчыгыш төрбә. — №11. — Б.4-5; Болгар. Төньяк төрбә. — №12. — Б.4-5.

Рабит Батулла. Кемнәр соң без — татарлар? — №2. — Б.27-32; №3. — Б.18-24; №4. — Б.28-34; №5. — Б.12-19.

Раиф Мәрданов. Кем ул Морад мулла? — №2. — Б.16-20; №3. — Б.33-37; «Плин төшкән кешеләрнең эшләре бик хараптыр...» — №12. — Б.18-23.

Рәмзи Вәлиев. Милли дәүләтчелек туганда... — №5. — Б.34-37; №6. — Б.30-33.

Үткәннән кайткан китап. — №10. — Б.15.

Фәйзелхак Ислаев. Каһарман Батырша: тәрҗемәи хәленә һәм восстаниегә яңа караш. — №9. — Б.6-14.

Фәнзаман Баттал. Бөтен өмет яшьләрдә. — №12. — Б.40-45.

Фәүзия Бәйрәмова. Чыңгыз Айтматовны биргән Мәчкәрә. — №5. — Б.26-33; №6. — Б.24-29.

Фирдәвес Гарипова. Татар халкының сармат бабалары. — №11. — Б.24-29.

ТАБИГЫЙ МИРАС

Газинур Морат. Бәкер күзе. — №7. — Б.109.

Гәрәй Рәхим. Шөгер ягы — Кара Алтын иле. — №7. — Б.98-108; №8. — Б.94-99.

Зөбәрҗәт күле. — №2. — Б.33.

Кызыл Байрак авылы. — №11. — Б.104-105.

Николай Петров. Иделнең борынгы үзәнлеге. — №8. — Б.100-103.

Татар имәне. — №4. — Б.116.

ПЕДАГОГИК МИРАС

Диләрә Гыйманова. Иң гүзәл гайрәт... — №10. — Б.30-33.

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән сүз — раст сүз. — №1. — Б.18-24; №2. — Б.34-39.

К.Бикколый, Г.Госмани. Әхлак. — №1. — Б.25-27; №6. — Б.44-47; №12. — Б.62-64.

Кәбир Туйкин. Тәрбия эшендә мөһим бер мәсьәлә. — №12. — Б.66-67.

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре. — №9. — Б.33; №11. — Б.57; №12. — Б.65.

ҖИҢҮ — 70!

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе. — №1. — Б.49; №2. — Б.61.

Александр Филиппов. Җиңү алып килгән татар генералы. — №3. — Б.53-59; №4. — Б.58-64.

Әлфия Шамова. Дәһшәтле еллар хатлары. — №1. — Б.40-45.

Әрибә Айтуганова. Югалмасын җирдә эзләре... — №5. — Б.59-63; №6. — Б.48-52.

Зөлфәт Хәйруллин. Әмирханнар нәселеннән. — №5. — Б.64-65.

Камил Кәримов. Язылмаган кыйсса. — №3. — Б.60-61.

Морад Дусай. Жуков шоферы. — №4. — Б.71-73.

Муса Җәлил хатлары. — №5. — Б.55-58.

Нәзирә Фәттахова, Ләйсән Харрасова. «Тәвәккәлләп бер хат языйм...» — №5. — Б.52-54.

Равил Рахмани. Фронтовик-шагыйрь. — №7. — Б.40-41.

Равил Сәйфетдинов. «Гөлсем өйгә кайтадыр». — №1. — Б.46-48.

Рәдиф Сәгъди. Фронтовик артистлар. — №4. — Б.65-70; Сәет белән Бикә. — №11. — Б.94-95.

Рәис Зарипов. Кара генерал. — №1. — Б.28-39; №2. — Б.48-57; №3. — Б.44-52.

Фәнзаман Баттал. Кадерлеләр һәм кадерсезләр. — №6. — Б.53-63; №7. — Б.34-39.

Фоат Галимуллин. Әткәм сурәте. — №2. — Б.58-60.

Шаһинур Мостафин. Албай төбәгенең биш батыры. — №3. — Б.62-65.

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Алмаз Хәмзин. Сибгат ага җырлый… — №8. — Б.47.

ӘДӘБИ МИРАС

Авылым сагышы. — №10. — Б.64-65.
Алия Мөбарәкшина. Тукай шигърияте — Төркиядә. — №1. — Б.72-75.
Алмаз Хәмзин. Хушлашырга ашыкты… — №11. — Б.88-90.
Альберт Хәсәнов. Гаярь егет. — №12. — Б.96-97.
Әгъзам Фәйзрахманов. Мөхәммәт Мәһдиев: «Егет булыйк әле бер…» — №12. — Б.90-91.
Әнвәр Шәрипов. Фазыл Туйкин шигырьләре һәм халык җырлары. — №2. — Б.72-77; Утыз Имәни оныгы — «Кечек Болгари». — №9. — Б.64-70.
Әнгам Атнабаев шигырьләре. — №3. — Б.82-83.
Вафа Бәхтияров. Тукай турында истәлекләр. — №4. — Б.88-93; №5. — Б.78-84; №6. — Б.82-88; №7. — Б.63-66.
Габдулла Тукай. Ачы тәҗрибә авазы. — №1. — Б.70-71; №2. — Б.82-83; №3. — Б.77; №4. — Б.87; №7. — Б.59-60; №8. — Б.53-54.
Гаяз Исхакый. Мәдрәсә җимеше. — №12. — Б.78-84.
Гаяз Исхакый. Солдат (ахыры). — №1. — Б.58-62.
Гобәйдулла Салихов. Тормыш юлым. — №9. — Б.71-79.
Зариф Мөэминов. Солдат йөрәге. — №7. — Б.74-88; №8. — Б.68-89; №9. — Б.80-98; Сәнәкчеләр. — №11. — Б.68-73.
Зөфәр Рәмиев. Тукай энциклопедиясе. — №1. — Б.76-77; №2. — Б.95; №3. — Б.88-89; №4. — Б.100; №5. — Б.85; №6. — Б.81. №7. — Б.61-62; №8. — Б.55; №10. — Б.61.
Йосыф Баласагуни. Кутадгу билик (Котайткыч белем). — №№1-12.
Кадыйр Сибгатуллин шигырьләре. — №10. — Б.78-79.
Кайгысыз падишаһ һәм кайгылы вәзир турында хикәят. — №9. — Б.54-62.
Кирпеч ясаучы Шапур һәм Хуҗа Мозаффар хикәяте. — №3. — Б.72-76; №4. — Б.79-84.
Кыйссаи Таһир илә Зөһрә. — №9. — Б.51-53; №10. — Б.41-49; №11. — Б.64-67.
Ләбиб Лерон. Мөдәмил Әхмәтовның язма мирасы. — №11. — Б.87.
Ләйлә Гарипова. Урау юллар узып сезгә кайтам… — №7. — Б.67-71.
Ләйсән Кариева. «Гөлбакча»лы әтием. — №12. — Б.88-90.
Ләлә Мортазина. «Тукай мондый түгел иде…» — №4. — Б.85-86.
Лирон Хәмидуллин. Бәрәкәтле Оренбург туфрагы. — №10. — Б.50-60; №11. — Б.74-81.
Марат Закир. Мәгърур нарат кебек… — №10. — Б.68-70.
Марат Кәбиров. Атнабай канаты астында. — №2. — Б.84-88; №3. — Б.78-81.
Марсель Әхмәтҗанов. «Миңа тигән зәһәр җилләр…» — №2. — Б.68-71; «Киңәшсез сүз башлама…» — №5. — Б.73-77; №6. — Б.77-80.
Марсель Галиев. Алтынга бакыр ябышмый. — №11. — Б.82-86.
Мөдәррис Вәлиев. Кайт әле монда, Ватанга!.. — №12. — Б.72-78.
Мөхәммәт Шәйхи шигырьләре. — №1. — Б.68-69.
Нәкыйп Каштанов. Фәтхи Бурнаш яктылыгы. — №2. — Б.89-94.
Нурихан Фәттах. Салих абый Сәйдәшев белән очрашу. — №11. — Б.92-93.
Рауль Мирхәйдәров. Мин белгән Муса Гали. — №7. — Б.89-97.
Рәзин Нуруллин. Акка кара төшсә, югалмый… — №8. — Б.56-61;
Рифә Рахман. «Җанда ул безнең, йөрәктә, бәгырьдә…» — №2. — Б.78-81.
Рифә Харрасова. Тукай энциклопедиясе. — №9. — Б.63; №11. — Б.91; №12. — Б.103.
Рифә Харрасова. Фатих Кәрими сәяхәтнамәләрендә публицистик катлам. — №8. — Б.62-67.
Роза Хәмидуллина. Яшәү сере. — №10. — Б.76-77.
Рүзәл Мөхәммәтша. Бер сүздән тора дөнья… — №3. — Б.84-87;
Сиринә Мөхәммәтҗанова. «Тукай клубы»: тарих һәм заман. — №10. — Б.66-67.
Тәлгат Галиуллин. Үз халкының баласы иде… — №4. — Б.94-99.
Тукайга якынаю (Түгәрәк өстәл). — №7. — Б.51-58.
Факил Сафин. Киткәннәрнең юлыураулы… — №1. — Б.63-67; Бер гасырдан соң… — №7. — Б.72-73.
Фәнис Яруллин. «Шәп кешеләр белән очрашу — үзе бер бәхет». — №12. — Б.98-102.

Фәридә Гайфуллина. Якты эз калдырган шәхес. — №10. — Б.62-63.

Фоат Галимуллин. Илһам канатларында. — №6. — Б.89-97.

Хәнәфи Бәдигый. Кайтаваз. «Седльце шигырьләре» эзеннән… — №12. — Б.92-95.

Хәнәфи Бәдигый. Муса Җәлилнең «Седльце» шигырьләре. — №10. — Б.71-75.

Эльмира Шәрифуллина. Каюм Насыйриның асыл теләге. — №10. — Б.80-83.

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

«Кыйссаи Йосыф»ны нәшер итү кыйссасы. — №1. — Б.78-82.

Һавадагы торна. — №2. — Б.96-99.

Каләмдәшләр игътибарын тоеп… — №5. — Б.86-91.

СӘНГАТИ МИРАС

Аида Алмазова. Күңел ташкыны. — №3. — Б.90-94.

Айдар Фәйзрахманов. «Яшәү барыбер кызык». — №1. — Б.89-91.

Камил Саттаров. Моң иясе. — №11. — Б.96-99.

Ләбиб Лерон. Кемнәр идек, кемнәр булдык… — №4. — Б.102-105.

Наилә Гәрәева. Фуат ага ядкяре. — №5. — Б.92-97.

Рүзәл Мөхәммәтша. Сәйдәшнең беренче мәхәббәте. — №5. — Б.98-103.

Рухия Ахунҗанова. Ил кызы. — №1. — Б.84-88.

Үзебезнең Илһам. — №2. — Б.100-101.

Фатыймаи-Зөһрә истәлеге. «Сөйлә, Гөлгенәм…» — №5. — Б.104-111.

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

Дания Гайнетдинова. Кояшлы рәссам. — №4. — Б.106-109; Илһам — күңел канаты. — №9. — Б.104-107.

ХӘТЕР САНДЫГЫ

Әгъзам Фәйзрахманов. Сүз һәм сурәт. — №8. — Б.108-109.

Әхтәм Зарипов. Сүз һәм сурәт. — №7. — Б.42-45.

Гүзәлия Җәләлева. Сырлы бәләк. — №7. — Б.115; Музыкаль коллекция. — №8. — Б.41; Фарфор эшләнмәләр. — №9. — Б.102-103; Курай. — №10. — Б.100-101; Шамаил. — №11. — Б.108-109; Йозаклар. — №12. — Б.108-109.

Мәсгут Имашев. Сүз һәм сурәт. — №11. — Б.58-59.

Рафаэль Ильясов. Сүз һәм сурәт. — №5. — Б.66-67.

Рафаэль Сәхәби. Сүз һәм сурәт. — №6. — Б.70-71.

Рәдиф Гаташ. Сүз һәм сурәт. — №2. — Б.43; Сүз һәм сурәт. — №10. — Б.34-35.

Рәдиф Сәгъди. Сүз һәм сурәт. — №1. — Б.50-51.

Руфия Мөхетдинова. Хәситә. — №1. — Б.83; Беләзегем, йөзегем… — №2. — Б.107; Калфак. — №3. — Б.95; Татар түбәтәйләре. — №4. — Б.101; Алъяпкыч. — №5. — Б.116; Коръән савытлары. — №6. — Б.110-111.

Сания Ислаева. Сүз һәм сурәт. — №12. — Б.60-61.

ХӘТЕР САГЫНДА

Әмир Камалов, Ислам Әхмәтҗанов. «Буа эше». — №3. — Б.96-102.

Касыйм Хәмзин. Такташ һәм аның гаиләсе. — №1. — Б.102-107.

Ләбиб Лерон. Йорт җанлы Туфан. — №10. — Б.102-103.

Марат Закир. Туган як һәм әдип кадере. — №1. — Б.95-97.

Фазыл Искәндәр. Мавзолей. — №1. — Б.92-94.

Хәбибрахман Рәфыйков. Пароходта ике сәяхәт. — №6. — Б.64-69.

Эльмира Шәрифуллина. Тирән тамырлы Туйкиннар. — №1. — Б.98-100.

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

Адлер Тимергалин. Миллият сүзлеге. — №№1-12.

Әскәр Гатин. Җаекмы, Йайыкмы? — №8. — Б.114.

Бер «ләкин»… — №8. — Б.110.

Наилә Вилданова. Безнең мирас — затлы бүләк! — №9. — Б.99-101.

Нәкый Исәнбәт. «Ташны баш белән ярып үз юлын алдылар…» — №8. — Б.104-105.

Рөстәм Акъегет. Теле барның — иле бар! — №3. — Б.106-111.

100 ЕЛ ЭЛЕК…

Ленар Гобәйдуллин. «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 ел. — №№1-12.

ШАЯН МИРАС

«Тыңгысыз каләм» битләреннән — №2. — Б.116-118; №3. — Б.116-118;

Авылым мәзәкләре яки Көлке куа килә… — №10. — Б.116-118.

Алмаз Хәмзин. Сабан туеның шаян мизгелләре. — №6. — Б.112.

Көлке көлә килә… — №4. — Б.117-118; №8. — Б.116-118; №9. — Б.114-115; №11. — Б.116-118.

Марсель Галиев. Кыш бабай интервью ала. — №1. — Б.116-118.

Нәби Дәүли. Хәйрулла паёгы. — №5. — Б.118-119.

Ширияздан Сарымсаков. Җүләр балык. — №7. — Б.118.

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

Әнгам Атнабаев. Шагыйрьләр. — №11. — Б.3.

Әдхәт Синугыл. Без бар! — №9. — Б.3.

Гамил Афзал. Йөрәгемдә йөртәм сине. — №4. — Б.3.

Гәрәй Рәхим. Болгар бабаларга ачык хат. — №3. — Б.3.

Рәшит Әхмәтҗанов. Яшәргә! — №10. — Б.3.

Ризаэддин Фәхреддин — №7. — Б.3.

Саҗидә Сөләйманова. Ач, шигърият, серләреңне. — №6. — Б.3.

Сәгыйть Рәмиев. Алла. — №2. — Б.3.

Туфан Миңнуллин. Татар уены. — №8. — Б.3.

Фатих Кәрим. «Соңгы тапкыр карыйм Иделгә…». — №5. — Б.3.

Харрас Әюп. Тел күрсәтә… — №12. — Б.3.

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

Әлфия Йосыпова. Кытайда татар мәктәпләре. — №4. — Б.16-20.

Гөлчирә Ханнанова. «Нинди батыр бала!» — №4. — Б.24-25.

Кытай татарлары: мәдәният, тарих һәм хәзерге заман (Түгәрәк өстәл). — №4. — Б.4-15.

Марат Закир. Ата-баба васыяте. — №4. — Б.21-23.

Себастьян Цвиклински. Германиядә татар телендәге беренче басма текст. — №8. — Б.42-46.

Хатип Халиди. Габдулла әфәнде Тукай. — №4. — Б.26-27.

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Айрат Сибагатуллин: «Мин республикада мәдәниятнең киләчәгенә зур ышаныч белән карыйм…» (**Ләбиб Лерон** әңгәмәсе). — №2. — Б.4-9.

Минтимер Шәймиев: «Яшәү мәгънәсе». (**Ләбиб Лерон** әңгәмәсе). — №3. — Б.4-17.

Гөлчәчәк Нәҗипова: «Татар әдәбияты музее булырга тиеш!» (**Ленар Гобәйдуллин** әңгәмәсе). — №5. — Б.4-11.

ТАТАР ГАМЕ

«Дуслык» һәм «Сандугач»! — №10. — Б.22-23.

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсының йомгаклары. — №11. — Б.56.

«Халык рухы сүнмәсен!» (Түгәрәк өстәл). — №8. — Б.4-17.

Заһир Шәйхелисламов. «Усал эт төсле тик чәйнәш…» — №4. — Б.48-51.

Илдар Кыямов. Арт капкадан кергәндә… — №11. — Б.44-50.

Илдар Низамов. Тәлгат Миңлебаев ядкярләре. — №12. — Б.46-54.

Күл-Черкендә — Урманче музее. — №10. — Б.29.

Миләүшә Хәбетдинова. Милли рух «Атлантида»сы. — №6. — Б.19-21.

Миннәхмәт Кашапов. Казакъстанга сәфәрләрем. — №10. — Б.24-28.

Мөнирә Сәгыйдуллина. Искермәгән Искер. — №10. — Б.16-21.

Муллалар илендә. — №11. — Б.54-55.

Наилә Вилданова. Хәтер-хатирә. — №11. — Б.51-52.

Рәис Зарипов. Алтынга тузан кунмый. — №7. — Б.30-33.

Рәфыйк Шәрәфиев. Биләр һәм лашманнар ядкяре. — №9. — Б.26-29.

Рәшит Минһаҗ. Искер — изге җир. — №6. — Б.4-11.

Ринат Фәхретдинов. Гамбәр мулла. — №11. — Б.38-43.

Рифә Рахман. Пәри — башка, җен — башка… — №6. — Б.12-18.

Сабаларга илтә юлларым… — №9. — Б.30-32.

Сөмбел Таишева. Казанга Гаспринский скверы кирәк! — №11. — Б.30-33.

Таҗи Гыйззәт исемендәге тәүге премия. — №11. — Б.53.

Тел белгән — ил гизгән (**Рәдиф Җамалетдинов** белән **Рәдиф Сәгъди** әңгәмәсе). — №12. — Б.53-55.

Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел. — №8. — Б.18-19.

Фәйзелхак Ислаев. Мин утырткан агачлар шаулап үсә... — №12. — Б.56-59.

Флёра Дәминова. Рафаэль Мостафин: «Әниемә минем исем ошамаган». — №11. — Б.35-37.

ДИНИ МИРАС

Айдар Гайнетдинов. Таркаулык. — №7. — Б.18-25.

Айзирәк Гәрәева. Өйләргә нур биргән дога. — №9. — Б.38-45.

Рәдиф Сәгъди. Дин һәм шәхес. — №9. — Б.34-37.

Ризаэддин Фәхреддин. Көтебе ситтә вә мөәллифләре. — №2. — Б.40-43; №6. — Б.40-43.

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

Ләйлә Минһаҗева. Батырлыкның йөзе нинди? — №2. — Б.44-46.

Ильмира Камаева. Кардәшлеккә чикләр юк! — №2. — Б.47.

Рафаэль Мөхәмәтдинов. Төрки дөнья һәм дөньяга караш. — №4. — Б.52-57; №5. — Б.40-43.

Сөмбел Таишева. Күңелгә якын Төркия... — №5. — Б.44-51.

Киңәшле эш таркалмас! — №6. — Б.38-39.

«Милли театр үлсә, тел дә бетә» (**Илфир Якупов** белән **Рәдиф Сәгъди** әңгәмәсе). — №8. — Б.90-93.

2015 ЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

Панаев бакчасы. — №6. — Б.22-23.

Рәмзия Габделхакова. Яшел Тау итәгендә. — №7. — Б.26-29.

СПОРТ

Атлас Гафиятов. Казан янә үзен күрсәтте. — №9. — Б.116-118.

Татарлар бар җирдә — батырлар бар! — №2. — Б.112-115.

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Атлас Гафиятов. Нәни гигант Галимҗан. — №8. — Б.111-113.

Нәсим Акмал. Яңгырап торган мирас калдырды... — №6. — Б.98-105.

ЯҢА КИТАП

Ләбүдә Дәүләтшина. Кукмара төбәге тарихы — яңа китапта. — №6. — Б.115-117.

Яңа китаплар. — №1. — Б.101.

ТАТАР ҖЫРЫ

Георгий Ибушев. И җыр гынам, җырым... — №11. — Б.110-113.

Максат Гомәров. Иң бәһале мирас! — №7. — Б.110-111.

Марс Макаров. Каян килә татарга моң?! — №9. — Б.108-109.

Рафаэль Сәхәби. «Мин кемгә эндәшим?...» — №10. — Б.104-105.

Сәйдә Зыялы. Җырланмаган җыр. — №10. — Б.106-113.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

«Мәһдиевнең шәп язучы булачагына шикләнмим...» — №10. — Б.92-97.

Зимфира Гыйльметдинова. Әни тавышы. — №10. — Б.84-90.

Илһам сәйраны. — №10. — Б.91

Рашат Низами. Ач сереңне, илаһият!.. — №11. — Б.100-103.

Мирасворд — №№1-12.

«Безнең мирас» елъязмасы. — №№1-12.

ЕРАККА КИТЕП КАРА...

Рөстәм Килдебәков — №1.
Илдар Зарипов — №2.
Илья Максимов — №3.
Камил Муллашев №4.
Шамил Нигъмәтуллин — №5.
Рифкать Якупов — №6.
Радик Минһаҗев — №7.
Бакый Урманче — №8.
Равил Айдаров — №9. ;
Фиринат Халиков — №10.;
Абрек Абзгильдин № 11.
Зөфәр Гыймаев №12.

«Безнең мирас»

елъязмасы /декабрь

● 860 ел элек (1155)

Тимучин (Чыңгызхан) (1155-1227) дөньяга килә. Бу хакта күренекле дәүләт эшлеклесе, табиб вә галим Рәшидеддиннең (Рәшидеддин Фазлуллаһ ибн Әбелхәер Али Хәмәдини (1247-1318) «Елъязмалар тупланмасы»нда хәбәр ителә.

● 120 ел элек (1895)

25 декабрьдә танылган актёр Ситдыйк Айдаров (1895-1938) дөньяга килә.

● 115 ел элек (1900)

3 декабрьдә күренекле композитор Салих Сәйдәшев (1900-1954), 9 декабрьдә күренекле шагыйрь Хәсән Туфан (1900-1981) дөньяга килә.

● 110 ел элек (1905)

11 декабрьдә Петербург каласында татар телендә «Өлфәт» исемле газета нәшер ителә башлый. Мөхәррире — Рәшид Ибраһим.

● 95 ел элек (1920)

5 декабрьдә «Сабанчы» газетасының 1 нче саны дөнья күрә.

● 85 ел элек (1930)

16 декабрьдә Татар дәүләт академия театрында Һади Такташның «Камил» исемле пьесасының премьерасы була. Әсәрне сәхнәгә режиссёр Хәким Сәлимҗанов куя.

● 65 ел элек (1950)

Низами Ганҗәвинең (1141-1209) «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы (татарчага Мәхмүд Максуд тәрҗемәсе) Татарстан китап нәшриятында китап булып басылып чыга.

● 45 ел элек (1970)

Алматы шәһәрендә татар шагыйрьләренең «Татар җырлары» исемле җыентыгы казакъча дөнья күрә.

● 35 ел элек (1980)

17 декабрьдә Мәскәүдә ТАССРның әдәбият һәм сәнгать көннәрен ачу тантанасы була.

● 25 ел элек (1990)

11 декабрьдә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында «Татар-мишәр фольклоры» дип аталган фәнни җыен һәм III Бөтенсоюз халык иҗаты фестивале була. Бәйрәмдә шагыйрьләр Рөстәм Мингалим һәм Ркаил Зәйдулла чыгыш ясый. ■

Зөфәр Гыймаев

Зөфәр Фоат улы Гыймаев 1951 елның 9 гыйнварында Үзбәкстанның Наманган шәһәрендә туа.

Казан сәнгать училищесын (1970), Ленинградтагы И.Е.Репин исемендәге рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтын (1976) тәмамлый.

Зөфәр Гыймаев — 1980 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (2012), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2005), «Гаяз Исхакый» (1993), «К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшев» (1993), «Туфан Миңнуллин» (1995) һ.б. портретлар, «Өмбе авылында көз» (1982) һ.б. пейзажлар авторы.

Бүген бәйрәм. 2008.
Киндер, майлы буяу

Хәсән Туфан. 2001.
Киндер, майлы буяу

«Күки авылында кич». 1978.
Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА:

«ГОБӘЙДУЛЛА *(САЛИХОВ – РЕД.)* АБЗЫЙНЫҢ БУ ШИГЫРЬЛӘРНЕ СЕДЛЬЦЕ КОНЦЛАГЕРЕННАН КҮЧЕРЕП АЛЫП КАЙТУЫ ҺИЧНИНДИ ШИК-ШӨБҺӘ УЯТМЫЙ. ЛӘКИН ҖӘЛИЛНЕКЕМЕ СОҢ АЛАР?»
АЗАТ СӨНКИШЕВ. «ҖӘЛИЛНЕКЕМЕ СОҢ АЛАР?»

«АШАРГА ИКМӘК ЮК, ХАЙВАННАРГА АЗЫК ЮК, КӨЗ САЧЕП КАЛДЫРЫРГА ОРЛЫК ЮК. ГӘРЧӘ ХӨКҮМӘТ ТАРАФЫННАН ОРЛЫК БИРЕЛСӘ ДӘ, ТӘМАМ ҖИТӘРЛЕК БИРЕЛМИ. ШУЛ СӘБӘПТӘН КҮП КЕШЕ СЫЕРЫН ЯКИ АРТЫГРАК КАРАЛТЫСЫН САТЫП, ОРЛЫК АЛЫП САЧМАКТАЛАР ИДЕ».
КАСЫЙМ БИККОЛОВ. «САБИРҖАН АГАЙ»

«ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ГОСМАНЛЫ ТӨРЕК ЯЗМА ТЕЛЕНЕҢ ГАДИЛӘШҮЕН, ЯГЪНИ ГАДИ ХАЛЫК ТА АҢЛАРЛЫК ДӘРӘҖӘДӘ БУЛУЫН ЯКЛЫЙ. ТАГЫН ШУНЫСЫ ӘҺӘМИЯТЛЕ: ЯЗУЧЫ БУ ТӘКЪДИМЕН ГОСМАНЛЫ ТӨРЕКЛӘРЕНЕҢ ЯЗМА ТЕЛЕН ГАДИЛӘШТЕРҮНЕ ӘДӘБИ БЕР АГЫМ ИТКӘН «ЯҢА ТЕЛ» («YENI LISAN») ХӘРӘКӘТЕ ТАРАФДАРЛАРЫННАН ИКЕ ЕЛ АЛДАН ӘЙТӘ».
ФӘРҺАТ ТАМИР. «ТӨРЕК ТЕЛЕН ГАДИЛӘШТЕРҮ ХӘРӘКӘТЕ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ»

«ҮРГӘНЕЧ КАЛАСЫ ӨСТЕНДӘ ТӨНГЕ КАРАҢГЫЛЫКНЫ ЯРЫП, БЕРНИЧӘ УРЫННАН ТӨТЕН ҺӘМ ЯЛКЫН БАГАНАЛАРЫ КАЛЫКТЫ...»
ӘЗҺӘР МӨХӘММӘДИЕВ. «ЧЫҢГЫЗ ХАН ХӘЙЛӘСЕ»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172